PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№9 (309) – СЕНТЯБРЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Кризисмы? Инкыйразмы?

«Татарстан» сөйли

Алтын Урда цивилизациясе



16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Ксения Сёмина,
Фаяз Хужин
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
орденды белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-2210

Басарга кул куелды: 21.09.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76

Коммерция директоры урынбасары:
Александр Березовский

Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ӘЙДӘГЕЗ, ЯНЫЙК!

Көзен халыкта төшенкелеккә бирелү һәм урыны-урыны белән бөтенләй дә хәсрәткә чуму гадәте бар. Имештер, табигать белән бергә безнең күңелләр дә саргая һәм сула. Чынлап та, табигать кануннарын без уйлап чыгармаган, һәм аларны җимерү дә безнең вазыйфага керми, без нибары – аның өлеше генә. Шулай булгач, ярар, саргаеп алыйк инде… Әмма «Татарстан» үз өстенә икенче бер вазыйфаны алды – көзге сагышларны куып тарату. Шуңа әзер торыгыз: кулыгызга яңа номер килеп керүгә, барлык моң-зарларыгыз да очып юкка чыгачак. Бу алым 1920 елдан үз көченә керә. Чөнки эшебез шундый: ел фасылларына, табигый катаклизмнарга карамыйча, укучыбыз өчен, армый-талмый, тарих төпкелләреннән һәм заман йөзлегеннән кызыклы тарихлар эзләп табу. Ул тарихлар көзге сагышны куып җибәреп кенә калмыйча, туган Татарстаныбыз өчен «бер горурлык хисе» белән янарга да мөмкинлек бирәчәк. Бүген нәкъ менә шундый көн – горурлык һәм ватанпәрвәрлек белән яну. Әйдәгез, яныйк!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

тм татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Сергей Царёв. «Уходящий Зеленодольск».

СЕНТЯБРЬ. ЯШЕЛ ҮЗӘН

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Сәләтлеләрне эзлибез.
Акыллыбашлар ник Татарстаннан китә

10. Кризисмы? Инкыйразмы?
Тел кая илтә

14. Кев резонансы.
Дөнья күләмендәге галим булу өчен нишләргә

16. Гаилә кыйммәтләре.
Балалар безне нәрсәгә өйрәтә

16. Телемедицина.
Фантастика кайда тормышка аша

12. Чиновниклар мәктәбе.
Проектлар белән ничек уңышлы идарә итәргә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

28. «Тыңлагыз, тыңлагыз! Казан сөйли...»
«Татарстан» радиосына ничә яшь

32. Камиллеккә биш адым.
Борынгы Алабугага заманчалыкны ничек өстәргә

36. Редакция кухнясы.
Кунакларны ни белән сыйлыйбыз

44. Ике дөнья серләре.
Шаманнар рухлар белән ничек аралаша

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

52. Тарих сәхифәләре.
Алтын Урда цивилизациясе

56. Шәһәр бистәләре.
Җиләкле бистәсендә ник җиләк үсми

60. Кәрим Тинчурин.
«Дусларым, сагынып кайттым...»

64. Татар киносы.
Марат Бәшәров хыялларын ничек тормышка ашыра

70. Лидия Әхмәтова.
«Джаз татарча да була ала»

72. Шәһәр мохите.
Татарстан калаларын кемнәр бизи

78. Казанда италияленең маҗаралары.
Джанни Родари бездә ни эзләгән

88. Татарстан риваятьләре.
Пугачёв хәзинәләре кайда яшерелгән

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

30.08

Ольга Васильева, РФ мәгариф министры, – гомумроссия ата-аналар җыелышында:

– Безнең ил – мәдәниятләр синтезын чагылдырган күпмилләтле ил, шуңа күрә, миңа калса, үзара миһербанлык, янәшәдә яшәүчеләрнең мәдәниятен, көнкүреш дәрәҗәсендә телен белү кирәк. Минемчә, син Башкортостан яисә Татарстан территориясендә туып, гомер итеп, көнкүреш дәрәҗәсендә телен белмисең икән, бу бик үк дөрес түгел. Ә татар теле бик бай.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

25.08

Наил Мәһдиев, Яр Чаллы мэры, – «Реальное время» онлайн-конференциясендә:

– Яр Чаллы һәрвакыт моношәһәр булып калачак. Чөнки КАМАЗ – ул язмыш, ә язмышны сайламыйлар. Шәһәр һәм КАМАЗ – бер организм. Эш башкада – шәһәр сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә автогигантның өлеше нинди дәрәҗәдә өстенлек итәчәк. Безнең бурыч – әлеге бәйлелекне яңа җитештерүләр ачу хисабына киметү.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

04.09

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Болгар ислам академиясен ачу тантанасында:

– Академияне ачу – республика һәм гомумән безнең зур Россия өчен тарихи вакыйга. Бу бөтен мөселман дөньясы өчен дә әһәмиятле вакыйга. Күп гасырлар дәвамында Болгар – күренекле дин галимнәре, дин белгечләренең тупланган урыны. Аның үзәгендә ислам академиясен ачып, без аның элеккеге бөеклеген торгызабыз.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Акыллыбашлар **НИК** Татарстаннан китә

Тел **КАЯ** илтә

Кев Салиховның фәнни кызыксынулары **НИДӘ**

Балалар безне **НӘРСӘГӘ** өйрәтә

Фантастика **КАЙДА** тормышка аша

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫБАШЛАРНЫ ЮГАЛТАБЫЗ ҺӘМ... **ТАБАБЫЗ**

Татарстан мәгариф хезмәткәрләренең августта уза торган чираттагы киңәшмәсендә, пленар утырышта, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җирле югары уку йортларын абитуриентлар белән элемтәләрне ныгытырга өндәде. Сәләтле яшьләр төбәктә калып, кеше капиталын баетсын өчен кирәк моны эшләү, дип басым ясады.

«Татарстан» журналы мәктәпне тәмамлаучылар «әйләнешен» нәрсә китереп чыгаруы белән кызыксынды.

Автор:
Ксения Сёмина

БЕЗ ИҢ-ИҢНӘРНЕ ҖЫЯБЫЗ

Илебезнең иң яхшы уку йортларына имтиханнарсыз гына укырга кергән абитуриентлар (бөтенроссия һәм халыкара олимпиадалар җиңүчеләре, призлы урын яулаучылар. – Ред. иск.) исемлегендә, кайсы гына вузны алма, Татарстанныкылар җитәрлек. Ә Татарстан вузларының исемлегендә, киресенчә, Россиянең төрле төбәкләреннән килүчеләр күп. Читтән «килешү» буенча килгән абитуриентлар үзебезнекеләрне кысрыкламыймы?

– Беренче курска кабул ителгән бөтенроссия олимпиадасы җиңүчеләренең икесе генә – Татарстаннан. Дүрт абитуриент – Башкортостаннан һәм берәр кеше – Ростов өлкәсеннән, Мордовиядән һәм Чувашиядән. Шуның белән бергә, 21 йөз бал җыючының 16сы – Татарстанныкы, берәр кеше Ульяновск өлкәсе, Калмыкия, Башкортостаннан, Ямал-Ненец автоном округыннан һәм Чиләбе өлкәсеннән бар, – дип сөйли Казан дәүләт медицина университетының белем бирү эшчәнлеге буенча проректоры Ләйсән Мөхәррәмова. – Без чыгырылыш сыйныф укучыларын безнең вузга кертергә теләге булган барлык төбәкләр белән дә тыгыз элемтәдә торабыз. Ләкин без һич кенә дә читтән килгән абитуриентларны аерып куймыйбыз, аларга нинди дә булса өстенлекләр бирмибез. Безнең максат бер генә – бездә иң-иңнәр укысын.

Ләйсән Мөхәррәмова билгеләп узганча, вузның спецификасы да шунда: ул үзенә «целевик»ларны зур күләмдә кабул итә. Быел гына да, мисал өчен, 425 бюджет урынына вузны гамәлгә куючы – РФ Сәламәтлекне саклау министрлыгы боерыгы буенча 281«целевик» килгән. КДМУга «аерым бер хокук» квотасы буенча 40 абитуриент кабул ителгән – болар олимпиада җиңүчеләре һәм ташламаларга ия булучылар. Гомуми конкурс шартларында кабул итүчеләргә нибары 101 урын калган, дигән сүз бу.

– Кайбер бик яхшы Казан мәктәпләрендә безгә укырга керү мөмкин түгел, дип исәплиләр. Быел кабул ителгән гаризаларның саны 6 меңнән артып китте, бәлки, болай дип исәпләргә дә хаклары бардыр кешеләрнең, – ди Ләйсән Мөхәррәмова. – Әмма бу махсус, ясалма рәвештә тудырылган ажиотаж нәтиҗәсендә килеп чыкмый. Бу, беренчедән, Казан медицина мәктәбенең абруен күрсәтсә, икенчедән, вузны популярлаштыру буенча күп еллар дәвамында алып барылган эшчәнлекнең җимешләре булып тора. Чит илләрдән студентлар җәлеп итү (быел безгә беренче тапкыр Һиндстаннан 15 йөз балл җыйган абитуриент укырга керде) эшчәнлеге нәтиҗәсендә, безнең хакта, димәк ки, республикадагы югары белем бирү оешмаларының потенциалы турында Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә беләләр.

ҮЗЕҢНЕКЕЛӘР ӨЧЕН ҮГИ БУЛСАҢ...

«Йөз балл җыючылар белән очраштык, алар бездә – 117 кеше. Шуларның яртысы гына республикада кала, калганнары – китеп бара. 50 процент – бу бик зур сан. Безнең вузларның абитуриентлар белән тиешле дәрәҗәдә эш алып бармаулары турында сөйли әлеге күрсәткеч. Абитуриентларны үзебездә көчләп калдырып булмый, әмма аларны кызыксындырып була – кызыклы шартлар, үсеш мөмкинлекләре тәкъдим итеп. Без акыллы яшьләр өчен көрәшергә тиешбез...» – дип мөрәҗәгать итте республика вузлары ректорларына Рөстәм Миңнеханов.

Республика югары уку йортлары Татарстандагы иң яхшы абитуриентларны үзләренә җәлеп итәр өчен нәрсә эшли ала соң?

– Бездә абитуриентларны вузга әзерләү буенча күпьеллык традицияләре булган укыту системасы эшли. Казанның 139нчы, 116нчы һәм 179нчы мәктәпләрендә, шулай ук Түбән Камада һәм Яр Чаллыда «медицина сыйныфларыбыз» бар. Моннан тыш, Тәбәкара консультация-диагностика үзәгендә һәм БРКХндә, шу-

PRESSA.RU

Полина Журавлёва

Туган шәһәре:	Новокузнецк, Кемерево өлкәсе
Уку йорты:	КФУ
Әзерлек юнәлеше:	халыкара мөнәсәбәтләр
Баллары:	372

– Миңа һәрвакыт чит телләр ошый иде. Шуңа һөнәр сайлаганда артык озак уйламадым, тәрҗемәче булам яки шуңа якын берәр һөнәрне үзләштерәм, дидем. Югары сыйныфларда рус теле («Высшая проба» бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасы) һәм инглиз теле буенча олимпиадаларда катнаштым. «Высшая проба» олимпиадасында призлы урын алу нәтиҗәсендә әлеге предмет буенча БДИда да 100 балл бирелде. Бу миңа, үз чиратында, бюджет нигезендәге конкурста катнашырга мөмкинлек бирде. Инглиз теле буенча олимпиада шулай ук күпмедер балл өстәде. Рус теле буенча олимпиадаларның нәтиҗәләре буенча мин имтихансыз Казан һәм Томск университетларына укырга керә ала идем. Өстәмә уңышларым өчен балларны да исәпкә алганда, КФУда мин дүрт предмет буенча 377 балл җыйдым. Һәм мин КФУны сайларга булдым. Сәбәпләр берничә. Беренчедән, мин Себердән килдем, үзәккәрәк килеп урнашасы теләге көчле иде. Эре Европа шәһәрендә яшисе килү теләге. Икенчедән, Казанда бәяләр Мәскәү белән Санкт-Петербургтагы кебек югары түгел. Өченчедән, Универсиада авылында тулай тораклар яхшы. Дүртенчедән, университет ил күләмендә шактый зур абруйга ия, танышларым арасында да күбесе аны мактады, киңәш итте. Һәм, ниһаять, Казан, Мәскәү белән Санкт-Петербургтан аермалы буларак, минем туган шәһәремә якынрак урнашкан, бу да мөһим. Киләчәктә нинди шәһәрне сайлавым, мөгаен, эш һәм карьера ясау буенча иң зур мөмкинлекләрне кайсысы тәкъдим итә, шуңа бәйле булачак, дип уйлыйм. Чит илләргә чыгасы килә, билгеле, анда эшлисе. Сәяхәт итәсе. Мин боларга ирешер өчен, бар көчемне дә куячакмын.

Рәсүл Хәкимуллин

Туган шәһәре:	Яр Чаллы, Татарстан Республикасы
Уку йорты:	МДУ
Әзерлек юнәлеше:	математика
Баллары:	280

– Махсуслашкан физика-математика мәктәбендә укыганда, мин мәктәп укучылары өчен уздырылган бөтенроссия олимпиадасында катнаштым. Һәм тагын бик күпләрдә. Бу катнашулар белән җиңүләрем имтихансыз гына укырга керү мөмкинлеге бирде. Документларымны шунда ук МДУга тапшырдым – биредәге мехмат ил күләмендә иң көчлеләрдән исәпләнә. Мин әлегә үземнең киләчәктәге һөнәри юнәлешемне бик томанлы гына күзаллыйм, мөгаен, ул математика белән бәйле булыр. Аның гамәли бер тармагы белән.

лай ук Түбән Кама ҮРХндә волонтерлыкка әзерләү программабыз эшли, ул егетләр һәм кызлар укырга керергә ныклап әзерләнгәнче үк үз сәләтләренә, теләкләренә анык бәя бирә алсыннар өчен каралган, – дип аңлата Ләйсән Мөхәррәмова. – Шуңа да карамастан, әлеге мораль һәм интеллектуаль яктан укырга керергә әзерләр арасыннан да без даими рәвештә иң яхшыларны «югалтып» торабыз, шул исәптән – йөз балл җыючыларны да. Бу очракта алар И.М. Сеченов исемендәге Беренче Мәскәү дәүләт медицина университетына өстенлек бирәләр.

Ул арада вузларның иң-иңнәрне үзләренеке итү буенча көрәше дәвам итә. Ысулларның берсе – үз олимпиадаларын оештыру һәм уздыру. Әлеге ысул БДИ тапшыруга керешкәнче үк булачак «алтын» беренче курсларны сайлап алу мөмкинлеге бирә.

– Мәктәп укучылары арасында «Ломоносов» олимпиадасының бүләкләү тантанасында яныма МДУ вәкиле килде дә җиңүем белән тәбрикләде. Җәмгыять белеме буенча БДИны 75 баллдан да кимрәккә тапшырмаган очракта мине юридик факультетка имтихансыз гына алырга әзер булуларын да белдерде. Бу миңа бик зур тәэсир ясады, – дип сөйли Казан шәһәренең 35нче лицееն тәмамлаган Инга Фәсахова.

Әйдәп баручы вузлар әнә шулай эш итә. Университетларга талантларны җәлеп итү – әлеге миссиянең бер өлеше генә түгел, ә билгеле бер система шартларында тиешле дәрәҗәдә эшли алуларының нигезе дә.

– Беренчедән, Мәгариф министрлыгы югары уку йортлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглый, һәм шул вакытта БДИ буенча беренче курс студентларының уртача баллы университетны бәяләү күрсәткечләренең берсе булып тора. Икенчедән, БДИ буенча уртача балл университеттагы бюджетка кабул итүнең контроль саннары бүленешен хәл итүдә

үз ролен уйный, ә бу инде, үз чиратында, уку йортының керемендә дә чагыла. Күпчелек вузлар өчен бу – төп чыганак, – ди «Югары икътисад мәктәбе» Милли-тикшеренү университетының Мәгариф институтындагы «Университетлар үсеше» лабораториясе аналитигы Даниил Козлов. – Ниһаять, университет – ул, нәрсә генә дисәң дә, фәнни тикшеренүләр башкару һәм укыту оешмасы, аның өчен көчле абитуриентлар – мөһим чыганак. Чөнки андыйлар нәкъ менә фәнни эшчәнлеккә дә әзерлеклерәк була, студентлар олимпиадаларында катнашырга да мөмкиннәр... Алар, асылда, кеше потенциалына йөз тота – вуз урнашкан төбәкнең социаль-икътисадый үсеше дә шуңа корылган.

ХӨКЕМДАРЛАР – КЕМ?!

Шулай да, башка шәһәрләргә укырга керергә китеп барган Татарстан абитуриентлары урынына икенче шәһәр һәм төбәкләрдән килүчеләрнең булуында плюслар да җитәрлек. Әйтик, «Югары икътисад мәктәбе» Милли-тикшеренү университетының Мәгариф институтындагы «Университетлар үсеше» лабораториясе тикшеренүләре күрсәткәнчә, абитуриентлар арасында нибары 20 төбәк кенә ихтыяҗ тудыручы булып исәпләнә ала икән. Болар – Мәскәү, Санкт-Петербург, Томск һәм Новосибирск өлкәләре, Татарстан Республикасы.

Бу субъектларга булган кызыксыну түбәндәге факторлар белән аңлатыла ала. Беренчедән, болар барысы да – тарихи яктан көчле университетлар. Икенчедән, бу төбәкләрнең барысында да социаль-икътисадый вазгыять тотрыклы. Өченчедән, анда квалификацияле

Софья Косых

Туган шәһәре:	Березники, Пермь крае
Уку йорты:	КФУ
Әзерлек юнәлеше:	чит ил филологиясе
Баллары:	276

– Мин гуманитар юнәлешле сыйныфта укыдым. Олимпиадалар да булды, әмма укырга кергәндә мин аларның файдасын күрмәдем. Алардан бигрәк, алтын медаль белән кызыл аттестат булышкандыр, алар өчен миңа 5 балл бирделәр. Документларымны ике вузга тапшырдым – КФУга һәм СПбДУга. Нәтиҗәдә, КФУ минем өчен идеаль вариант булып чыкты. Уку йортында яхшы белем бирәләр, мөмкинлекләр дә җитәрлек. Миңа калса, вузда чит ил студентларының күп булуы да – менә дигән күрсәткеч. Кешеләр бит ерак илләрдән башкалага дип килми, ә сыйфатлы белем алырга һәм уңай шартларда яшәргә килә. Мин күптәннән олы шәһәргә омтыла идем, Казан миңа кеше мыжлап торган Мәскәү белән төньяктарак урнашкан Санкт-Петербургтан күркәмрәк тоелды. Киләчәктә нинди һөнәр сайлавым – анысы турында әле бүген үк әйтә алмыйм. Миңа чит телләр үзләштерү бик ошый, мөгаен, тормышымны да шулар белән бәйләрмен. Ким дигәндә, тагын ике тел өйрәнергә ниятләп торам. Бәлки, тәрҗемәче булып китәрмен.

Валентина Гусева

Туган шәһәре:	Чабаксар, Чувашия Республикасы
Уку йорты:	КФУ
Әзерлек юнәлеше:	юриспруденция
Баллары:	262

– Мин социаль-икътисадый юнәлешле сыйныфта укыдым. Хокук һәм җәмгыять белеме буенча вузлар үткәргән күпсанлы олимпиадаларда, шулай ук бөтенроссия олимпиадаларында катнаштым («Ломоносов» мәктәп укучылары олимпиадасы, Мәскәү дәүләт юридик университеты олимпиадасы, СПбДУ, КФУ олимпиадалары). Нәкъ менә олимпиадалар укырга кергәндә ярдәм итте миңа, ә БДИ нәтиҗәләре икенче планга күчте. Документларны башта ук КФУга бирдем, юридик факультетка. Үз төбәгем һәм башка төбәк вузларыннан да тәкъдимнәр булды, әмма мин КФУны сайладым. Беренчедән, мондагы юридик факультет көчле исәпләнә, икенчедән, Казан белән Чабаксар арасы ерак түгел, өченчедән, биредә яшәү Мәскәүдәгедән арзанлырак. Яшәр өчен шәһәр сайлаганда аның нинди шартлар белән мөмкинлекләр тәкъдим итүенә дә игътибар иттем, билгеле. Инфраструктурасы да, янәшәдә булган газиз кешеләр дә – әһәмиятле.

PRESSA.RU

Энҗе Әхмәтҗанова

Туган шәһәре:	Казан, Татарстан Республикасы
Уку йорты:	РУДН
Әзерлек юнәлеше:	философия
Баллары:	266

– БДИ нәтиҗәләре буенча мин КФУ һәм Россия Халыклар дуслыгы университетына бюджетка керүчеләр арасына эләгә идем, ә аттестатлар рейтингы буенча – СПбДУга. Мин РУДНны сайладым. Укырга кергәндә, миңа шәхси казанышларым өчен 5 балл өстәделәр, һәм мин 271 балл белән «Философия» белгечлегенә үттем. Бонус рәвешендә икенче югары белем – «Һөнәри багланышлар өлкәсендә тәрҗемәче» белгечлеген дә үзләштерәчәкмен. Киләчәктә һөнәри эшчәнлегемне телләр өлкәсе белән бәйләргә ниятлим. Ә яшәү урынын сайлау, ничек кенә сәер яңгырамасын, климат шартларына һәм һөнәремнең кайда ихтыяҗ тудыруына бәйле булачак.

Инга Фәсахова

Туган шәһәре:	Казан, Татарстан Республикасы
Уку йорты:	МДУ
Әзерлек юнәлеше:	юриспруденция
Баллары:	228

– Югары сыйныфларда укыганда, юрист булам дип ниятләгән идем. Минем илебездәге хокук системасын камилләштерүгә үземнән өлеш кертәсем килә. Хокук буенча «Ломоносов», «Фемида» олимпиадаларында катнаштым, шулай ук – мәктәп укучылары өчен Кутафин олимпиадасында. БДИ тапшыргачы ук миңа МДУ белән Төмән дәүләт университетыннан хатлар килде. Алар миңа җәмгыять белеменнән БДИны 75 баллдан да ким булмаган нәтиҗәгә тапшырган очракта имтихансыз керә алуымны хәбәр итте. Мин МДУны сайладым. КФУга да документларымны биргән идем, әмма имтиханнарсыз укырга керү килешү бүлегенә генә мөмкин иде. МДУны сайлавымның тагын бер сәбәбе – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов әйткәнчә: «МДУ һәрчак топ-вуз санала иде. Бүген МДУ – илебездәге уку-укыту һәм фәнне үстерү өлкәсендәге уникаль үзәк. Әлеге уку йорты биргән белем – киләчәктә һөнәри осталыгыңны кулланып, уңышлы карьера ясау юнәлешендәге гарантия ул». Ышанам, мин биредә алган белемнәр Татарстанда да кирәкле булыр. Чөнки киләчәгемне мин ватандашларымның хокукларын саклау эшенә багышларга телим.

“ – Эшкә урнашканда билгеле бер вуз дипломын нибары 1,5% вакансия генә таләп итә, еш кына бу эш бирүче тарафыннан белем сыйфаты яхшы дип саналган «популяр» вузларныкы.

кадрларга ихтыяҗ бар. Шул ук вакытта Татарстан, тикшеренүләр күрсәткәнчә, Мәскәү, Санкт-Петербург, Свердловск өлкәсе белән беррәттән, чыгарылыш сыйныф укучыларына булган ихтыяҗ һәм вуздан соңгы миграция буенча караганда, биш төркемнең беренче урынында торучы «магнит төбәкләр»дән дә исәпләнә. Ягъни әлеге төбәкләр абитуриентларны үзләренә «тартып китерәләр», соңыннан кадрлар биредә эшләп тә кала. Шул ук вакытта Татарстан вузларының 22440 чыгарылыш студентыннан 6210 белгече 2016 елда төбәкне калдырып киткән. Чагыштыру өчен: вуз тәмамлаучылар арасында иң зур миграция Адыгея Республикасында (1737/992). Ә Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсен 158133 белгечнең 47328е калдырып киткән.

Абитуриентлар «миграциясен» тудыручы сәбәпләрнең иң беренче урындагысы – үз төбәгендә тәкъдим ителгәнгә караганда хезмәт хакы югарырак, ә эше дәрәҗәлерәк урынга урнашырга омтылу. Әмма ул урын чынлап та солтанлы, затлы урын булып чыга микән соң?

– Эшкә урнашканда билгеле бер вуз дипломын нибары 1,5% вакансия генә таләп итә, еш кына бу эш бирүче тарафыннан белем сыйфаты яхшы дип саналган «популяр» вузларныкы. Әйтик, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Новосибирск, Воронеж университетлары, Томск политехника университеты, Көньяк федераль университет (Ростов-на-Дону), һ.б. Һәм, әлбәттә, үз төбәкләрендәге вузлар белән эш бирүчеләр яхшырак таныш, – дип ассызыклый Урал, Себер һәм Идел буе федераль округлары буенча HeadHunter матбугат хезмәте җитәкчесе Елена Таращук.

Шуның белән бергә, белгеч сүзләренә караганда, күптән эшләүчеләре белән чагыштырганда, эшкә беренче мәртәбә урнашучы белгечләр күченеп йөрүләргә йөз тотмый. Татарстанда, мисал өчен, эш эзләүче кандидатларның гомуми саныннан 25% ы гына башка шәһәргә күчәргә риза, ә эшкә беренче мәртәбә урнашучылар арасында бу сан нибары 17%ны тәшкил итә.

Деловой проездной

Специально для тех пассажиров, которые регулярно совершают полеты на рейсах авиакомпании, мы предлагаем удобный тарифный продукт «Деловой проездной». Это «единый» билет класса Эконом и класса Бизнес на несколько полетов «туда и обратно» на выбранном маршруте. Стоимость «Делового Проездного» зависит от количества приобретаемых полетов «туда и обратно», класса обслуживания и направления. Первый полет Вы бронируете на конкретную дату и рейс, а остальные полеты остаются открытыми и Вы можете забронировать их на любой удобный для Вас рейс**, позвонив в контактный центр ПАО «Аэрофлот», а также обратившись в офис собственной продажи ПАО «Аэрофлот» или в агентство, оформившее Деловой Проездной, не позднее, чем за 1 час до запланированного времени вылета рейса.***

ЛУЧШАЯ АВИАКОМПАНИЯ ЕВРОПЫ В 2017 ГОДУ

THE WORLD`S 4-STAR AIRLINE
Авиакомпания «4 звезды» Скайтракс

САМЫЙ СИЛЬНЫЙ РОССИЙСКИЙ БРЕНД
Согласно рейтингу Бренд Финанс 2017

8 (800) 444-5555
www.aeroflot.ru

* Количество направлений и стоимость перелетов могут быть изменены. Уточняйте информацию в контактном центре Аэрофлота, а также в офисах продаж и у агентов. ** При наличии мест по Вашему тарифу. *** За исключением первой даты вылета, которая фиксируется при оформлении Делового проездного.

PRESSA.RU

КРИЗИСМЫ? ИНКЫЙРАЗМЫ?

Яңа уку елы башланган көннәрдә интернет челтәрендә хәбәр таралды: хәзер мәктәптә балаларга татар телен укыту мәҗбүри түгел икән. Моның өчен мәктәп администрациясенә хат язу да җитә... Ә нә Башкортостанда ана телләрен башкорт балалары гына өйрәнә. Ә калган милләт укучылары – теләк буенча.

Автор:
Руфия Фазылова

Бу фикергә каршы татар җәмәгатьчелеге күтәрелеп чыкты. Интернет челтәрендә бәхәс көннән-көн кыза. Татар телен яклап чыккан аерым төркемнәр барлыкка килде. Күпләр тарихта булган вакыйгаларны искә ала. Без дә әлеге четерекле темадан читтә кала алмадык. Авырткан җиребез, һич кенә дә күз йомарга ярамый, дөресрәге, мөмкин дә түгел!

«ӘЙДӘГЕЗ, ДУС ЯШИК...»

Әйе, тел, милләт проблемасы һәр гасырда булган. Бер танышым әйтә: «Ярар, татарларны чукындырганнар да әле. Ләкин барыбер милләт буларак исән калганбыз». Шулай, монысы хак. Тик ул заманда татар авыллары гөрләп яшәгән, ә димәк, тел дә сакланган. Бүген исә авыллар бетеп бара, шәһәрдә ана телеңне саклау, ай-һай, авыр. Интернеттан туктаусыз татар теленә каршы негатив фикер агыла. Миңа да ватсаптагы ата-аналар төркеменә хәбәр килде: балалар татар теле урынына күбрәк рус, инглиз телләрен өйрәнсен иделәр. Янәсе, атнасына алты сәгать татар теле бик күп ул. Әнә, телгә булган кеше ана телебезне факультатив укысын, имеш.

Дәүләт теле факультатив була аламы? Беренче чиратта, бу Конституциягә каршы килү. Икенчедән, сан буенча татарлар күбрәк яшәгән аерым бер республикада, һичшиксез, үз телебезне өйрәнергә тиешбездер. Рус телле булган ватандашларыбыз шуны аңламый булса кирәк. Татарлар – тыйнак халык, толерантлык безнең канга сеңгән. Мин кайчакта үзебезне «Леопольд» мультфильмындагы песигә охшатам. Нәрсә әйтсәләр дә, елмаеп, болай ди ул: «Әйдәгез, дус яшик». Шулай да иң гаҗәпләндергәне, бәгырьгә тигәне: татар ата-аналарының балаларына үз телләрен өйрәтергә каршы булуы. Гафу итегез, ахмаклык дигән сүздән башкасы телгә килми!

Шөкер, татар ата-аналары, Бөтендөнья татар яшьләре форумы ана телебезгә каршы барган «һөҗүмгә» җавап бирде. Интернетта, социаль челтәрләрдә туган телебез өчен җан атучыларның әллә ничә төркеме барлыкка килде. Алар дәүләт җитәкчеләренә татар телен саклап калу турында мөрәҗәгатьләр, рәсми хатлар яза-

Фото: Александр Ефремов

лар, киң җәмәгатьчелеккә көн саен хәбәрләр җибәрәләр. Мисал өчен шундый хәбәрләрнең берсе: «Татарстан – ана телебезне саклап калу өчен кечкенә генә өмет биргән зур булмаган һәм бердәнбер территория. Һәм, мөгаен, якын араларда безне бу мөмкинлектән дә мәхрүм итәчәкләр. Республика мәктәпләрендә татар телен укытуны факультатив итеп калдырырга җыеналар. Ничек уйлыйсыз: гадәти мәктәп укучысы өстәмә фәнне укыргамы, укымаскамы дигәндә кайсысын сайлар? Әлбәттә, тормышын җиңеләйтү өчен баш тартачак. Андый мөмкинлек бирсәң, укучы татар телен генә түгел, математика, рус теле, рус әдәбияты, химия, тарих һ.б фәннәр белән дә шундый ук карарны кабул итәчәк. Татар телен мәктәпләрдә мәҗбүри укыту – туган телебез якын киләчәктә юкка чыкмас дигән зур булмаган бер мөмкинлек ул».

Кызы Казанның яһүд теле дә укытыла торган 12 нче мәктәбендә укый торган Анна исемле танышым татар телен мәктәпләрдә өйрәтүгә каршы булуының икенче сәбәбен атады:

– Кызым атнага икешәр сәгать дүрт тел укый: русча, татарча, яһүдчә, инглизчә, – ди Анна. – Мине иң гаҗәпләндергәне: ул яһүд, инглиз телләрен белә, ә татарча бернәрсә аңламый. Югыйсә, кызыбыз яһүдчә, инглизчә дә көндәлек тормышта әллә ни аралашмый. Ә татар телен көн саен ишетә. Миңа калса, монда сәбәп бер генә: татар телен укыту методикасы дөрес түгел. Ул бик катлаулы. Нәтиҗәдә балалар дәрестә берни аңламый утыра. Өйгә бирелгән бөтен эш – русча текстларны татарчага тәрҗемә итү. Җан чыга шуларны кешегә эшләтеп…

Татар телен белмәгән ватандашларыбыз балаларын татар теленә өйрәтүгә каршы булуларында гел бер «аргумент» китерә. Янәсе, рус теленнән быелгы БДИ нәтиҗәләре 2016 елга караганда түбәнрәк икән. Чынлап та, нәтиҗәләр түбәнрәк... 0,43 процентка! 2016 елда Татарстанда рус теленнән уртача балл 73 балл булса, быел бу сан – 72,57. Ә хәзер бер мисалга тукталыйк. Икенче башкала саналган Санкт-Петербургта рус теле буенча уртача БДИ нәтиҗәсе: 71,09 балл, Саратов өлкәсендә 70,29 балл. Анда балаларның берсе дә татарча укымый, ни өчен Татарстан укучылары кадәр дә балл җыя алмаганнар соң? Ут күршеләребез булган Башкортостанда рус теленнән БДИ нәтиҗәләре – 68,60 балл, Мордовиядә – 65,90 балл. Ә инде Россия буенча уртача нәтиҗәләр – 67,8 балл. Күргәнебезчә, ике тел тигез күләмдә өйрәнелә торган Татарстан балалары рус теленнән Россия буенча уртача баллдан югарырак нәтиҗәләргә ирешә. Димәк, татар теле комачауламый булып чыга.

Татар теле курсларына килүчеләр методик әсбапларны фотога төшерә.

«НИ ӨЧЕН ӨЙРӘТМӘДЕГЕЗ?!»

Ике кыз үстерүче ана буларак, бала туган телен иң беренче чиратта гаиләдә өйрәнергә тиеш, дип саныйм. Алайса күп вакыт ата-аналар, балаларының ана телләрен белмәүне балалар бакчасына, мәктәпкә сылтый. Мисал өчен, безнең балалар бакчасында ике тәрбиячебез дә рус милләтеннән. Гомумән, төркемнәрендә дә татарча сөйләшкән кеше юк. Шуңа карамастан, алты яшьлек кызларыбыз туган телләрендә бер дигән итеп сөйләшә. Тукайның кем булганын, кайда туган, яшәгәнен, озын-озын шигырьләрен яттан сөйлиләр. Һәр бәйрәмдә балалар бакчасында бары тик татарча чыгыш ясадылар. (Тәрбиячеләр каршы килмәде, киресенчә, хупладылар гына). Кыскасы, ана теленә мәхәббәт аларга кечкенәдән сеңә дип уйлыйм. Әлбәттә, без төрле, гаиләләр дә төрле. Кемдер бу мәсьәләләргә бөтенләй битараф. Алар өчен баласы яхшы мәктәптә укыса, түгәрәкләргә йөрсә, заманча киенсә, шул җиткән. Нәкъ менә шушы очракларда татар теленең дәрәҗәсе, мәктәпләрдә фән буларак укытылуы кирәк тә. Шулай булмаса, ана телебез аерым даирәдәге кешеләр өчен генә калачак.

«Татар гаиләсе» фонды директоры Миләүшә Гайфуллинаның гаиләсендә барысы да табиблар: тормыш иптәше, улы-килене, кызы-кияве. Ул үзе дә югары категорияле табиб. Ана телен өйрәтү турында аның үз карашы бар:

– Безнең гаиләдә язылмаган канун бар: оныклар белән бары тик туган телебездә аралашабыз, – дип сөйләде Миләүшә апа. – «Дәү әнием» дигән сүздән дә матуррак сүз бармы икән? Мине иң тетрәндергәне: әби-бабайның вата-җимерә оныгы белән русча сөйләшүе. Бу бик кызганыч күренеш. Моны наданлык дип саныйм, ни ул рус телен белми, ни татар теленә карата хөрмәте юк. Гомер-гомергә әби-бабай оныкларны тәрбияләгән, үз телендә әкият, мөнәҗәтләр сөйләгән.

PRESSA.RU

Курсларга меңгә якын кеше язылган.

һәм һичшиксез ул бүген дә шулай булырга тиеш. Югыйсә ул балалар үскәч әти-әнисеннән, әби-бабасыннан: «Ни өчен мине туган телемдә сөйләшергә өйрәтмәдегез?» – дип сораячак.

Без өч бертуган, тагын ике энем бар. Әни тәрбиясеме, барыбыз да гел татар телендә сөйләшәбез. Бездән күреп – балалар да. Моңа әллә ни тырышлык куясы юк: барысы да үз мисалында. Энемнең кызы биш телне камил белә, калганнары да, ким дигәндә, өч тел үзләштерде. Ләкин туганнар җыелган җирдә ана телендә генә аралашабыз.

Миләүшә Гайфуллина бездә тел, милләт проблемасы алай ук кискен тора дип санамый:

– Төшенкелеккә бирелмәс идем. Россиядә милләт саны буенча татарлар икенче урында тора. Безнең тел, гореф-гадәтләре берничек тә юкка чыга алмый. Тел проблемасы Тукай заманында ук булган. Ләкин күреп торабыз: милләтебез бетмәгән, киресенчә, бүген безнең халыкны чит илләрдә дә танийлар, беләләр. Хәзерге чорны бер кризис дип кенә уйлыйк, бөеклеккә күтәрелер алдыннан бер сулыш алу булсын.

«ОЯТ... БЕЗ БИТ ТАТАРСТАНДА ЯШИБЕЗ!»

Бер төркем ата-аналар: «Татар теле нигә кирәк?» – дип лаф органда, ана телебезне өйрәнергә теләүчеләр дә шактый икән. Алай гына да түгел, ел буе чират көтәләр. Сүзем – КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында уза торган татар теле курслары турында. Ул җиденче ел оештырыла. Иң соңгылары – курсларга елдан-ел кеше күбрәк языла, ди. Мин дә, татар телен өйрәнергә теләүчеләр янына барып, алар белән аралашып кайттым.

Эдуард һәм Светлана Сәгыйтовлар.

Биш йөзләп кеше җыелган аудиторияне күзәтәм: күбесе яшь, урта буын вәкилләре. Бу – аларның уртак оештыру җыелышлары иде. Ә 18 сентябрьдән, төркемнәргә бүленеп, укулары башлана.

Аудиториягә җитәкләшеп кергән алтмыш яшьтәге ир белән хатынга күзем төште. Барып сүз каттым.

– Фамилиябез Сәгыйтовлар, мин Эдуард булам, хатыным – Светлана, – дип таныштырдылар үзләре белән. Икесе дә югары белемле. Светлана ханым үзе дә КФУда укыта икән.

– Ни өчендер гаиләдә татар теленә бик игътибар бирмәдек, – диде Светлана Сәгыйтова. – Олыгаяолыгая, татар теле, татарларның гореф-гадәтләренә карата кызыксынуым арта. Татар теле курслары турындагы игъланга күзем төште дә иремә кайтып әйттем. Ул да бу хакта интернеттан укыган. Озак

уйлап тормадык, килергә булдык. Вакыты җайлы, дәресләр кичке алтыда башлана.

– Ә миңа, үз телемне белмәгәч, балалар, оныклар алдында оят, – диде Эдуард әфәнде. – Оныклар, өй эше эшләгәндә, миннән ярдәм сорый, ә мин белмим. Дөрес, аерым сүзләрне аңлыйм, әйтә дә алам. Ләкин тулы җөмләләр белән сөйләшә алмыйм. Беркөн кечкенә оныгым: «Бабай, син бит татар. Ничек инде туган телеңне белмисең?» – дип шелтәләде.

Курсларга язылган меңгә якын кешенең фамилияләрен карап чыктым, яртысыннан артыгы – татар. Рус, башка милләт фамилияләре дә күп. Болар, нигездә, студентлар, магистрантлар. Хәер, төрлесе бар. Мәсәлән, ике бала анасы Елена Федорова белән аралашып алдым.

– Балаларыма татар теленнән өй эшләрендә булышасым килә, югыйсә берни белмим, – диде ул. – Татар милләтеннән булган дусларым, күршеләрем дә бар. Алар сөйләшкәндә, берни аңламыйча басып тору матур түгел. Ни дисәң дә, Татарстанда яшибез бит. Күршеңнен телен белмәү дөрес түгел.

Елена мәктәпләрдә укытыла торган татар теле программасының авырлыгыннан зарланды.

– Улым белән кызым балалар бакчасында көн саен татарча яңа сүз өйрәнеп кайталар иде, мәктәптә шул белгәннәрен дә оныттылар. Мәктәпләрдә ни өчендер сөйләшергә өйрәтмиләр, уку белән язуга күбрәк игътибар бирәләр. Аңламыйм!

Курсларга килгән кешеләр арасында татарның танылган шәхесләре (режиссер, мулла, рус телендә язучы журналистлар) да бар иде. «Татар телен камилләштерәсебез килә», – диде алар.

Соңыннан курсларның кураторы – гомуми тел белеме һәм төркология кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты Кадрия ханым Фәтхуллова белән аралаштык.

– Татар телен өйрәнергә теләүчеләр ел дәвамында kpfu.ru/tatkurs.html сайтында электрон теркәлү үттеләр, – дип сөйләде ул. – Шунда ук анкеталарын тутырдылар. Укучыларны төрле дәрәҗәләргә бүлеп укытабыз: А1, А2 – нигездә монда татар телен бөтенләй белмәүчеләр һәм бераз белүчеләр туплана. Алар күпчелекне тәшкил итә, шуңа да А1, А2 дәрәҗәдәгеләр алты төркем була. В1, В2 төркемнәрендәгеләр татар телен белә, ләкин иркен сөйләшә алмый, лексик-грамматик белемнәре дә җитеп бетми. Өч ай укыганнан соң, сөйләм эшчәнлегенең төрләре: тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу буенча тест тапшыралар һәм аларга КФУның сертификатлары бирелә. Курсларның төп эчтәлеге коммуникатив юнәлеш нигезендә эшләнгән. Һәр укытучы төп өч максатны күздә тотып эш итә: татар телен өйрәнүчеләрнең сөйләм, лингвистик һәм этно-мәдәни осталыкларын үстерү. Татар халкының бөек шәхесләре турында сөйлибез, аның тарихы һәм бүгенге казанышлары турында фикер алышабыз. Кыскасы, курсларга йөргән кешеләр кимендә татарча гади җөмләләрне һәм текстларны аңларга, сораулар бирергә һәм җавап кайтарырга, диалоглар һәм монологлар төзеп сөйләргә, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдаланырга өйрәнә. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте белән таныша. Теләгән кешеләр курсларга икенче елга да килә ала.

...Әлеге тема бик нечкә. Аны әлләничә яклап өйрәнергә, язарга була, чөнки проблемалар җитәрлек. Мәсәлән күп ата-аналардан: «Мәктәпләрдә татар телен укыту методикасы дөрес түгел», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Шуңа да бу теманы киләсе санда да дәвам итәргә булдык. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы башлангыч сыйныфлар өчен яңа методика эшләгән: татар телен балаларга чит телләр үрнәгендә өйрәтәләр. Аерым мәктәпләр, тәҗрибә рәвешендә бу дәреслекләрдән укый башлаган инде.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, ата-аналарның татар телен мәктәпләрдә өйрәтүдән баш тартырга чакырган ата-аналарга язмача аңлатма бирде:

– Татар телен укыту закон нигезендә башкарыла һәм аны укудан баш тартуга чакыру законга каршы килә. 2004 елның 16 ноябрендә Россия Конституцион суды Татарстан мәктәпләрендә татар теле һәм рус телләрен дәүләт теле буларак укыту мәсьәләсен тикшерде һәм, Россия Конституциясенә каршы килми, дип тапкан иде.

ФАКТ

20 июльдә Йошкар-Ола шәһәрендә узган Милләтара мөнәсәбәтләр советы утырышында Россия Президенты Владимир Путин рус телен һәркем белергә тиеш, диде. Ә ана теле булмаган телләрне мәктәпләрдә мәҗбүри укыту һәм рус теле сәгатьләрен киметергә ярамаганлыкны әйтте. 28 августта ул Россия Генераль прокуратурасына һәм Рособрнадзорга төбәкләрдәге мәктәпләрне тикшерергә күрсәтмә бирде.

Әлеге күрсәтмәне үтәү йөзеннән, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, 2018 елның 1 гыйнварыннан республика мәктәпләрендә рус теле сәгатьләре артачак, дигән карар кабул итте дигән хәбәр килеп иреште.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Кев Салихов – физика-математика фәннәре докторы, электрон спин резонансы өлкәсендә әйдәп баручы белгечләрнең берсе. 1988 елдан 2015 елга кадәр Завойский исемендәге Казан физика-техника институтын җитәкли, бүген аның фәнни җитәкчесе булып тора. Фәнгә керткән хезмәтләре өчен абруйлы халыкара премияләргә лаек булган шәхес. Алар арасында фән һәм техника өлкәсендә Ленин премиясе, Александр фон Гумбольдт исемендәге фонд премиясе, Бөекбритания Король химия җәмгыятенең Брукер премиясе, Завойский исемендәге премия бар. 2006 елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнә.



Фото: Александр Эшкинин

КЕВ РЕЗОНАНСЫ

«Сездән бөркелгән яктылык мәгърифәткә һәм фәнгә хезмәт итүче иртәнге йолдыз балкышына охшаган...» – дип язган аның турында Нобель премиясе лауреаты Рихард Р. Эрнст. Кев Салихов – чын-чынлап дөнья масштабындагы галим. Безнең аң дәрәҗәбез төшенә алмаган нәрсәләр – аның өчен фәнни кызыксынулар объекты.

Автор:
Ольга Туманская

ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

«Республика җитәкчелегенә кирәргә туры килсә, каушап калмассызмы?!» – дип сорадылар миннән Казан физика-техника институты хезмәткәрләре моннан утыз еллар чамасы элек институт директорын сайлаганда. Минем кандидатурам да тавышка куелган иде. Ни өчен куркырга? Үзем өчен сорамыйм бит. Теоретик буларак, мин үзем өчен берничә тормыш кагыйдәсе уйлап чыгардым. Шуларның иң әһәмиятлесе – эш ахырына кадәр җиткерелмәячәк дигән уйны башка да кертеп карамаска. Директор постында иң беренче эшем диссертация советы төзү булды. Әлеге идея белән Фәннәр академиясенә киттем, ә миңа: «Институт илле ел советсыз эшләде, алга таба да шулай эшләсен!» – диләр. Бик абруйлы кешеләр – академиклар әйтте моны. Мин – малай-шалай – алар каршында басып торам. Борылып чыгып китә ала идем, тик ул уйны башыма да китермәдем. Нәтиҗәдә – хупладылар.

ФӘНМЕ? ФАТИРМЫ?

Һәр эштә вазгыять мөһим роль уйный, әмма ул шартлар гына тудыра – сайлау бездән тора. Әйтик, Югары молекуляр кушылмалар институтында аспирантураны тәмамлаганнан соң киләчәк язмышым турындагы сорау алга килеп басты. Ленинградта кала алмыйм – пропискам юк. Фәнни җитәкчем Казанга Борис Арбузовка мине эшкә алуын үтенеп хат язды. Ләкин баш тарттылар: янәсе, безгә теоретик кирәкми. Нәтиҗәдә мине укытучы итеп Казан университетына билгеләделәр. Ә мин тоттым да баш тарттым! Чөнки мин фән турында хыялландым. Ярар соң, Казан вузында эшләргә теләмисең икән, Карагандага кит диделәр. Җәза буларак. Әлеге институт ректоры турында иң җылы хатирәләр генә саклана миндә. Ул мине үзләрендә калдыру өчен күп тырышты – кафедра да, өч бүлмәле фатир да тәкъдим итте... Мин дөресен әйттем: «Әгәр ризалашып монда калам икән, фән белән шөгыльләнә алмаячакмын». Менә бит сайлау нәрсә ул! Тормышым бөтенләй башка сукмактан китәр иде! Бер елдан мине җибәрделәр. Мин Новосибирск шәһәренә киттем. Атаклы Академшәһәрчектә урнаштым. Анда узган егерме биш ел мине галим буларак формалаштырды. Бик шәп мәктәп уздым мин анда. Спин химиясенең теоретик нигезләрен төзегән өчен, Новосибирск һәм Мәскәүдәге коллегаларым белән бергә, Ленин премиясенә лаек булдым.

ИСЕМЕҢ ҖАВАПЛЫЛЫК ӨСТӘГӘН ОЧРАКТА...

Академшәһәрчектә электрон парамагнит резонансы өлкәсендә эшләгәндә Казан өчен уңайсызлык кичерә идем. Чөнки әлеге ачышның ватаны Казан бит! Якташым һәм хезмәттәшем Ренат Сәгъдиев белән кызып-кызып әлеге теманы тикшерә идек. Мөгаен, шуңа күрә дә Казанда институт директоры вазыйфасына кандидат буларак ясаган чыгышым шактый кискен яңгырагандыр. «Институтның ачыш ясаган дигән исеме бар. Бу аңа электрон парамагнит резонансы өлкәсендә иң яхшы институт исемен дәгъвалау хокукын бирә. Дөнья күләмендә дәгъвалау! Ләкин ул бу исемне аклыймы – монысы икенче мәсьәлә», – дидем мин ул чакта. Һәм өстәп шуны да әйттем: алдыма максат итеп институтны алдынгылар рәтенә чыгаруны куям. Сораулар ява башлады: директор булган очракта аларны нинди юнәлеш буенча эшләтәчәкмен. «Сез минем кебек үк профессорлар. Шуңа күрә теләгән юнәлешегездә эшләгез, әмма хезмәтегезне сыйфатлы итеп башкарыгыз. Ә мин үземдә бу турында нәрсә уйлавымны әйтү хокукын калдырам», – дип җавап бирдем мин. Шунысын да әйтергә кирәк: мондый сүзләрдән соң, мине сайламаячакларын төгәл белә идем. Әмма ялгыштым – өчтән ике өлеш минем өчен тавыш биргән иде.

«Теләгән юнәлешегездә эшләгәгез» сүзләрен минем исемә бер генә мәртәбә төшермәделәр. Ләкин мине бернәрсәдә дә гаепли алмыйлар, дип уйлыйм, гәрчә үз фикеремне белдерү хокукыннан шактый еш файдалансам да. Без җәмгыятьтә яшибез, һәм аның каршындагы җаваплылык – беренчел. Кайчак хезмәткәр белән шәхси әңгәмә вакытында: «Әйдәгез урамга чыгып, үтеп баручыга сезнең ни белән шөгыльләнгәнегезне аңлатып карыйк һәм аннан үзе түләгән салымның бу эшкә тотылуын теләү-теләмәвен дә сорыйк», – дип тә әйтергә туры килә иде. Салым түләүче турында беркайчан да онытмаска – бу институтыбызның кагыйдәсенә әверелде. Ә инде алдынгылыкка чыгару максатына килгәндә, утыз ел вакыт үткәннән соң, без моңа ирештек, дип әйтә аламдыр.

ОЧАРГА СӘЛӘТЛЕЛӘР

90нчы еллар башында мин Казанда атаклы Ампер конгрессын үткәрергә тәкъдим иттем. Илебез тарихында булмаганны. Ләкин бу идеяне алга сөрү җиңел булмады – Ампер җәмгыяте президенты моңа зур шик белән карады. Бәхеткә, без аны ышандыра алдык. Үзебездә, Татарстанда, республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев моңарчы күрелмәгән ярдәмне оештырды. Минтимер Шәймиев очарга сәләтле кешеләр токымыннан! Уйларыңны әйтергә өлгермисең, җавапка фикерләр өермәсе аласың! Ул бу идея белән канатланып китте һәм Франкфуртка чартер рейсын оештыруда төп ярдәмне күрсәтте. Ә Казанда конгресста катнашучыларның Минтимер Шәймиев белән кызыклы очрашуы узды – минем чит илләрдәге коллегаларым бу очрашуны бик озак искә төшереп тордылар әле! Әлеге тарихның ахыры гаҗәеп булды: 1994 елда Казанда фәнни дөньяда иң мөһим вакыйгаларның берсе – Ампер конгрессы гаять зур уңыш белән үтте.

АРАЛАШУ ТӘМЕ

Хәзергә кадәр Ашхабадка баруымны искә алам. Лекция укырга бардым, әмма хәтердә конференция калды. Мине үзем кебек үк галим озата йөрде, әмма без фән турында гына түгел, дөньядагы бар нәрсә турында гәпләштек. Хәтта төрекмән туенда күңел дә ачтык! Мин аралашудан әйтеп бетергесез тәм табам. Мондый мизгелләр минем өчен бик кадерле. Алар бик еш һәм һәрвакытта да фән докторлары белән генә аралашуга кайтып калмый. Новосибирскида яшәгәндә мастерскойда эшләүчеләр белән дус идем. Тагын бер иптәшем машина йөртүче иде, без гаилә дуслары булдык. «Ә кызыксынуларның уртаклыгы кайда?» – дип сорарсыз сез. Кафедра артында чыгыш ясаучы акыллы кеше, ә руль әйләндерүче – юк, дип кенә әйтә күрмәгез. Әйләндерүен әйләндерә ул, әмма тормышны күрә һәм уйлый да.

БӨТЕН ДӨНЬЯГА ЯҢГЫРАТАБЫЗ!

«Сезнең Үзәк комитетта кешегез бармы әллә?» – дип сорадылар миннән бервакыт СССР Элемтә министрлыгында пышылдап кына. Аларга бөтенесен дә энәсеннән җебенә кадәр сөйләп булмый бит инде! Эш шунда ки, магнит резонансы турында журнал нәшер итү идеясе белән мин бик озак янып йөрдем, әмма эшләр бик авыр барды. Беренче тапкыр бу турыда Академшәһәрчектә эшләгәндә сүз кузгаткан идем. Үзем директор булгач, ныклап тотынырга уйладым. Әле дә хәтерлим: СССР Фәннәр академиясенең вакытлы матбугат бүлеге хезмәткәре минем гаризамны алды да тыныч кына: «Бер биш елдан карый алырбыз дип уйлыйм», – диде. Ә мин артка чигенергә иялэшмәгән. Хезмәткәрнең башлыгына үземнекен исбатларга тотындым. «Бездә чират!» – дип акланырга тырышты тегесе. «Чит телдә халыкара журнал чыгарырга да чиратмы?!» – дип, кинәт кенә туган уемны әйтеп салдым мин. «Андыйларга – юк!» «Алайса мин – беренче!» – дидем.

Инде шундый матавыклардан соң әз генә калды – ҮК рөхсәтен алу. Кирәкле кешене мин МДУнда – Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында тоттым. Президиум әгъзалары белән төшке аш ашарга чыгып барган җирендә. «Мин бик мөһим эш белән йөрим – бары тик сез генә хәл итә аласыз», – дим. Ул аптырап калды. «Безнең ил – бөек ачыш – спин парамагнит резонансы ачылган урын. Дөньяда дистәләгән журнал шуңа багышлап чыгарыла, ә СССРда берәү дә юк...» – дидем мин. Шуннан эшләр уңга китте.

Безнең беренче редколлегия шедевр иде! Анда дөнья фәне йолдызлары тупланды. Нобель премиясе лауреаты Рихард Р. Эрнст рецензент буларак эшләде. Хезмәткәрләребез өчен дә бу менә дигән мәктәп булды. Аннан соң инде 27 ел узып китте. Германия, АКШ, Япония, Австралия, Кытай, Канада, Һиндстан... Фән булган һәркайдан безгә фәнни мәкаләләр агыла. Ә никадәр галим әлеге журнал аша Казандагы фән торышы турында белә!

АКАДЕМИКНЫҢ ХЫЯЛЛАРЫ

Яхшы спорт матчларын карарга яратам – бу чын көрәш тантанасы! Ләкин уенчыларның холкы чагылган һәр мизгелдә кешеләргә фәнне дә шулай мавыктыргыч итеп күрсәтеп булыр иде, дип уйлыйм. Без, галимнәр, ачышларга сокланудан нишләргә белмибез, әмма берүзең генә канәгатьлек алганда, бәхет касәсе тулы була алмый. Минем күптәнге хыялым бар. Чакырыгыз мине мәктәпкә – һәм мин рәхәтләнеп популяр лекцияләр белән чыгыш ясый алам. Парамагнит резонансы, квант компьютеры һәм телепортация турында гына түгел! Мин балаларга үземнең укытучыларыма никадәр рәхмәтле булуым һәм тормышта белем алырга өйрәнү никадәр мөһим булуы хакында да сөйләр идем!

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU

Фото: Лилиана Вәлитова, гаилә архивыннан.

«БАЛА БЕЗНЕ ТӘРБИЯЛИ»

Тирә-юнебездә гаҗәеп гаиләләр бар: кемдер ачы язмыш сынауларын сынмый, сыкранмый уза, икенчеләр исә тәрбиягә берничә авыру бала ала, аларны үзенеке шикелле итеп тәрбияли, өченчеләр... Казан шәһәрендә яшәүче Мотыйгуллиннарны да гадәти гаилә димәс идем. Бер-берсенә карата булган мөнәсәбәтләре, тормыш фәлсәфәләре үзенчәлекле аларның. Өстәвенә – милли җанлылар. Бу санда алар турында язуыбыз да юкка түгел. Берәүләр: «Татар теле нигә кирәк?» – дип «баш ватканда», бу гаилә үз мисалында шуны күрсәтә: татар теле уңышка ирешү өчен киртә түгел!

Автор:
Руфия Фазылова

17 ЕЛ – ТУЛАЙ ТОРАКТА

Җәлил һәм Гөлнара Мотыйгуллиннар 1990 елда таныша. Икесенең дә студент чагы, егет – Казан дәүләт педагогика университетының физика, кыз математика факультетында укый. Икесе дә – активистлар. Татарларның «суверенитет» дип урамнар һәм мәйданнарга чыккан вакытлары. Яшьләр анда да катнаша. Аралашалар, бәхәсләшәләр... Нәкъ шул вакытта араларында мәхәббәт очкыны кабына. Уку елы тәмамлангач, өйләнешергә булалар.

– Мин кечкенәдән мөстәкыйль булдым, – дип сүзен башлады Җәлил абый. – Үсмер чагымда гел өлкәннәр белән аралаштым. «Синдә бабайлар акылы», – дияләр иде. Үз ярымны очраткач, яраткач, гаилә коруны гадәти хәл дип санадым. Галимҗан Ибраһимов әйтмешли, без тормышның төбеннән күтәрелдек. Гаиләле булгач, студентлар

түбәтәйдән дә киләм. Сүз әйтүче юк үзе.

– Күптән дингә килдегезме? – дим.

– Яңа фатирлы булгач. Кайбер кешеләргә сәеррәк тоелырга мөмкин бу, әмма хак. 2008 елда әлеге өч бүлмәле фатирга күчендек. Аны алты ел университет укытучыларына дип, махсус төзеделәр. Башта шатлыктан, сөенечтән нишләргә белми йөрдем. Фатирның почмакларына барып, стеналарны тотып-тотып карадым: «Безнеке бит бу...» Чын күңелдән Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтәсем килде. Ничек итеп? Әлбәттә, дога белән. Шулай итеп, намаз укый башладым. Аллаһы Тәгалә әйткән: «Башта бер сынау бирермен, аннан рәхәтлек. Шуны аңламаган кешегә янә сындырырлык сынау бирермен». Мин сындырганын көтмәскә булдым. Рәхәт тормышта яшибез, гаиләмдә иминлек, үзебез сау-сәламәт. Ничек шөкер итмисең?!

«ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНӘ ИХТЫЯҖ БИК ЗУР ИДЕ»

Җәлил абый педагогика фәннәре кандидиты. Студент елларыннан алып бүгенгәчә фән, милли белем бирү системасы эшләсен дип яна. Университетта татар төркемнәре дә аның күз алдында оеша. Студентлар өчен рус дәреслекләрен татарчага тәрҗемә итүдә катнашкан мөгаллим ул.

Тарихка күз салсак, 1990 елда Татарстан Республикасы Югары Советында Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул ителә. Шуңа нигезләнеп, 1992 елның 8 июлендә «Телләр турында закон» эшләнә һәм кабул ителә. Һәм рус теле белән беррәттән татар теле дә дәүләт теле итеп игълан ителә. Нәкъ шул вакытта университетларда татар төркемнәре оеша. Җәлил абый аны чын мәгънәсендә татарларның күтәрелгән, чәчәк аткан чоры дип атады:

– 1990нчы еллар башында татар төркемнәрендә укырга теләүчеләр шулкадәр күбәйде, хәтта конкурс русларныкына караганда да зуррак булды. Мисал өчен, рус төркемнәрендә 25 студент белем алса, татар төркемнәрендә, кимендә, 30дан артык студент та укыды.

«Татар телендә укуга авыр күчтек», – ди Җәлил абый. Шулай да бер ел эчендә методик кулланмаларны тәрҗемә итеп чыгалар. Туры килүен кара: университетның физика лабораториясендә Рәмзия Шаһиморатова исемле мөгаллимә

тулай торагыннан аерым бүлмә бирделәр. Ә кызыбыз Айсылу тугач, ике бүлмәле булдык. Бик рәхәт яшәдек. Кеше тулай торак дип йөз чөерә, ә без сагынып искә алабыз.

Мотыйгуллиннар 17 ел тулай торакта яши. Икенче кызлары Мәликә дә шунда туа. Җәлил абый КДПУның физика факультетында студентларга белем бирә, параллель рәвештә мәктәпкә физика укытырга да урнаша. Ләкин аңлашыла, укытучы хезмәт хакына гына фатир алып булмый.

– Ул чагында кредитка фатир алулар юк иде, – дип сүзгә кушылды Гөлнара апа. – Баланы бакчага илтәбез дә эшкә йөгерәбез. Икенче кызыбыз тугач, кыйммәтләр үзгәрде. Күрәсең, яшь барган саен тормышка башка күзлектән карый башлыйсың. Кызларыбызның яшь аермасы – ун ел. Хәтерлим, Айсылуның рәсем укытучысы: «Кызыгызның сәләте бар, сәнгать мәктәбенә бирмисезме?» – ди киңәш биргән иде. Җәлил белән уйлаштык та баш тарттык. Эшкә барасы бар, өлгереп булмас, дидек. Хәзер үкенәм. Бәлки аннан бер дигән рәссам чыгар иде. Гомумән, баланың сәләте, теләге булганда, ата-ана аны үстерергә тиеш. Мәликә ул яктан бәхетлерәк булды, кечкенәдән теләгән җиренә барды, ошаткан эше белән шөгыльләнде.

Мотыйгуллиннар – зыялы гаилә, дини дә. Дөрес, монда хатын-кызлар хиҗаптан йөрми. Гаурәтләрен каплаган, матур күлмәк кигәннәр. Җәлил абый: «Иң мөһиме – Аллаһка ышану күңелдә булсын, кылган гамәлләрең намуска тап төшермәсен», – ди. Гаилә башлыгы намазын калдырмый, җомга саен мәчеткә йөри.

– Дәүләт эшендә бит, димәк, дингә басым ясарга ярамый, – ди Җәлил Мотыйгуллин. – Ләкин җомга көнендә эш бинасына

PRESSA.RU

эшли. Ул үз вакытында мәктәпләр өчен физика дәреслекләрен рус теленнән татарчага тәрҗемә иткән. Аның күзәтүе астында татар телен камил белгән университет укытучылары югары уку йорты студентларына дәреслекләр тәрҗемә итә.

Җәлил абый белән бүген татар теле тирәсендә барган шау-шу турында да сөйләштек:

– Татарлыгыңнан оялмаска, киресенчә, үзебезнең белемле икәнебезне башка халыкларга да расларга кирәк, – диде ул. – Мин, мәсәлән, барлык фәннәрне дә татарча укыдым. Университетка кергәндә кабул итү имтиханнарын рус телендә тапшырырга туры килде. Ике фәннән дә «5»ле булды. Без студент вакытта төркемнәр рус, татарга бүленми иде. Ягъни мәктәптә физиканы татарча укып, университетта рус телендә өйрәндем мин үзем. Һәм бер кыенлык та күрмәдем. Гомумән, хәзер дә документлар белән эшләгәндә, сөйләгәндә рус теле белән проблемаларым булганы юк дип саныйм. Мәктәптә рус телен укыдык, аралашып яшибез. Шуңа күрә бүген кайбер ата-аналарның татар теле башка фәннәргә комачаулый дип сөйләнүе бары тик эшнең асылын аңламауда, дип саныйм.

МИЛЛИ ҖАНЛЫ БАЛА

Мотыйгуллиннарның олы кызлары Айсылу татар гимназиясендә белем алган. Ә менә Мәликәне, заманга ияреп, беренче сыйныфка «престижлы» мәктәпкә биргәннәр. Әти-әнисеннән күчкәнме (Гөлнара ханым бүген дә, татар мәдәнияте белән кызыксынып, бар яңалыклардан хәбәрдар булып яши), Мәликә кечкенәдән татар дөньясына, әдәбиятка, сәнгатькә тартыла. «Яшь ТНВ» каналы барлыкка килгәч, телевидениегә алып баруларын үтенә. Аннан «Нур» татар балалар театр студиясенә йөри башлый. Шул рәвешле кызчыкны татар мохите «суырып ала».

– Мәликә: «Татар мәктәбендә укыйсым килә», – дип йөри иде, форсат чыкты, – дип сүзгә кушылды Гөлнара апа. – Алтынчы сыйныфка күчкәндә, укулар икенче сменада булачак диделәр. Ә «ТНВ»да тапшырулар төштән соң төшерәләр. «Телевидениедән китәсе килми», – дип, бик борчылды Мәликә. Шулай итеп башка мәктәпкә күчү турында сүз чыкты. Безнең өчен иң җайлысы – Ш. Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе, чөнки ул телевидение белән янәшә. Бердәнбер проблема – Мәликә биш ел төп фәннәрне рус телендә укыды. Татарча уку авыр булмасмы?

– Ә мин борчылмадым, – ди Җәлил абый. – Үз башымнан узды бит, русчадан татарчага яки киресенчә укуның авырлыгы юк. Әлбәттә, терминнар үзгә. Тик теләк булганда берничә атна эчендә өйрәнеп була. Мәликә татарча яхшы белә: «Борчылма», – дидем. Һәм чынлап та, ялгышмаганмын.

– Барыннан да бигрәк миңа гимназиядә татар мохите булу ошады, – дип фикерен белдерде Мәликә. – Барысы да татарча, үзебезчә! Ә уку программасына килгәндә, җиңелрәк тоелды. Мин укыган «престижлы» мәктәптә кирәкмәгән әйберләр күп иде. Программага сыешмыйбыз дип ашыктыралар. Нәтиҗәдә күп әйберләрне аңламый каласың. Ә гимназиядә андый кабалану юк, аңламаганны укытучылар янына барып сорыйсың. Сиңа рәхәтләнеп аңлаталар. Әлбәттә, бу минем шәхси фикер. Укыту программасы бар җирдә дә бер дип беләм. Шулай да ул дәрәҗәле саналган мәктәпләр күбрәк рейтинг өчен эшлидер дип уйлыйм.

Мәликә, укудан тыш, татар яшьләр тормышында актив катнаша. Җәй көне Бөтендөнья та-

тар яшьләре форумында эшләгән, төрле очрашулар оештыру, чыгыш ясаулар дисеңме…

– Быел тугызынчы сыйныфта укыйм, – диде Мәликә. – Әлегә җәмәгать эшләрен читкә куеп тордым. Бөтен игътибарны укуга бирәм, имтиханнар тапшырасы бар бит…

«ЯРАТТЫМЫ ИКӘН?»

Балалары Казан шәһәренең Ш. Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясендә укучы танышларым сокланып та гаҗәпләнеп тә сөйләде: «Җәлил абый кызы Мәликәне җитәкләп кенә йөртә». Бер карасаң, унбиш яшьтә балаңны җитәкләп йөртү сәеррәк тоелырга мөмкин. Бигрәк тә ата кешегә. Күпчелек аталар, кызлары балигълык яшенә җиткәч, нindидер ара сакларга тырыша бит. Яхшы түгел кебек. Ә монда…

– Мин эштән кайтканда Мәликә ишектән: «Әтием, кайттыңмы, мин сине яратам», – дип каршы ала, – ди Җәлил абый. – Балаң шулай дип торганда ничек инде: «Мин дә сине яратам, кызым!» – димисең!

– Олы кызыгыз белән дә мөнәсәбәтләр шундыймы? - дим.

– Юк, Айсылу белән алай булмады. Яратырга әле берничә ел элек кенә «өйрәндем». Без биш ир бала үстек, мин – дүртенчесе. Әти-әнинең безне иркәләп утырырга вакыты булмагандыр. Хәер, ир малайларга карата кырысрак та булыйк, дигәннәрдер. Һәм мин моны аңлыйм һәм килешәм. Авыл җирендә хуҗалыгын да алып барырга кирәк. Үскәндә әтине күрмәдек тә дияргә буладыр. Без йокыдан уянганчы чыгып китә, караңгы төшкәч кенә кайтып керә. Безне әни тәрбияләде. Ләкин гаиләдә әти дәрәҗәсе көчле иде. «Хәзер әтиегез кайта», «әтиегезгә әйтәм…» – аның һәр сүзе закон булды. Шулай да бер тапкыр әтигә каршы килдем. Мәктәпне тәмамлагач әти: «Улым, китмә быел Казанга, киләсе елга керерсең укырга. Безгә ярдәм ит, өс-башыңны кара. Колхозда эшләп ал», – диде. Мин шул чакта кырт кистем: «Әти, ачуланма, хәзер китмәсәм укырга керү авыр булачак. Бар белгәнемне онытачакмын», – дидем. Әти теләмичә генә ризалашты. Шулай итеп, туган авылны ташлап чыгып киттем.

Ул вакытта күпер юк, җәйге каникулны санамаганда, Аксубайга ике генә кайта ала идем. Әни йомшаграк булды безнең, авылга кайткач та аның белән озаклап сөйләшеп утырабыз. Ә әти корырак иде. Аннан әтиебезгә инфаркт булды, шактый озак авырып ятты. Менә шул вакытта да ачыктан-ачык сөйләшенмәгән. Әти вафатыннан соң озак уйлап йөрдем: «Яраттымы икән ул мине?» Ул сүзне бер тапкыр да әйтмәде. Хәер, мин дә бит әтигә: «Яратам», – дип әйткәнемне хәтерләмим. Югыйсә аның өчен үлеп тора идем. Тукта әле дим, мин дә бит балаларыма «яратам» дип әйтмим. Шулай итеп, әкренләп бу сүзне әйтергә өйрәнә башладым. Бер дә җиңел түгел ул, оясыңның кебек. Хатыныңа «яратам» дип барыбер әйткәлисең, ә балага… Ярамаган эш кебек. Юкса алар өчен дип яшисең, дөнья куасың. Исән чакта көндәлегесен әйтеп калырга кирәк – шуны аңладым. Бер өйрәнгәч, аның авырлыгы юк икән. «Ярату» сүзе ешрак яңгыраган гаиләдә яшәве рәхәтрәк, өй дә нурлырак була, дип уйлыйм. Монысына үз мисалыбызда инандым. Һәм балалар безне яратырга өйрәтә, бәлки тәрбиялидер дә әле.

PRESSA.RU

МЕДИЦИНА – **КИР БУЛЫЧЁВ БУЕНЧА**



Автор:
Ольга Туманская

Узган гасырның 60нчы елларында совет балалары яраткан Алисаларының әтисенең марсиа208нарны өйдән чыкмыйча гына видеофон буенча дәвалавы турында йотлыгып укый иде. Бүген фантастлар фаразларының күпчелеге чынбарлыкка әйләнә бара. Телемедицина – шулардан берсе. Ул Татарстан табибларына пространство һәм вакыт белән санашмаска мөмкинлек бирә. Репортажыбыз нәкъ менә шул хакта.

Фото: Александр Ефремов

СУГЫШЧАН ИПТӘШЛӘР

Ул көнне операция бүлмәсендә табиблар саны бик күп иде – өч бригада эшләде! Башта акушерлар, кесарев кисеме ясап, сәламәт сабыйны дөньяга китерде. Кисемне теккән арада, рентгенэндоваскуляр хирурглар командасы эшкә кереште: сабыр итәргә ярамый – хатын-кызның баш миендә яман шеш үскән иде. Табиблар «мишеньнең» канын агызып бетерде һәм «эстафетаны» нейрохирургларга тапшырды. Шундый мультидисциплинар тырышлык нәтиҗәсендә бер операция вакытында өч операция ясалды…

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе (РКХ) баш табибы урынбасары Марат Мәҗитов миңа әлеге очракны телемедицина практикасына мисал итеп китерә. Телемедицинаның монда ни катнашы бар соң, дип аптыравыма, аңлатып бирә: мондый катлаулы пациенттан сәламәт бәби таптыруга район хастаханәсе табиблары яңа телекоммуникацион мөмкинлекләр аркасында гына ирешә алган бит.

– Шеш бик тиз үсте. Аны кайчан алып ташлау яхшырак? Йөклелекне өзәргәме, әллә карындагы баланы саклап карарргамы? Сораулар күп иде. Район табибларына безнең тар профильле белгечләр дистанцион ярдәм итте. Бу бик көйле эш булды. Нәтиҗәсе – ана да, сабый да исән һәм сәламәт!

Бүген телемедицина республиканың иң ерак почмакларына кадәр барып җитте. Аныклыйм: «табиб – табиб» дәрәҗәсендәге телемедицина турында сүз бара, бу очракта шәһәр һәм район хастаханәләре хезмәткәрләре киңәш сорап республика клиникаларының тар профильле һәм тәҗрибәлерәк белгечләренә дистанцион мөрәҗәгать итү мөмкинлегенә ия.

– Без һәр очракта яшәү һәм үлем мәсьәләләрен хәл итәбез, шунлыктан безнең өчен телемедицина аерым бер төрле мәгънә ала, – дип раслый Марат Мәҗитов. – Беренчедән, ераклык төшенчәсе юкка чыга: пациентның кайда булуы – Әгерҗедәме, Актаныштамы яки Бөгелмәдәме – инде мөһим түгел. Икенчедән, вакыт янга кала. Элегрәк безнең белгечләргә урыннарга чыгарга туры килә иде – бүген исә алар көненә берничәшәр виртуаль кабул итү үткәрә. Үз пациентларының да янында була. Һәм тагын шунысы да бар. Телемедицина ниянең икенче башындагы табибларга аларның ялгыз булмауларын тоярга мөмкинлек бирә. Без, фронттагы кебек, сугышчан иптәшләр.

НӘРСӘЛӘР БАР?

– Телемедицинага ихтыяҗ еш туамы? – дип сорашам Марат Мәҗитовтан.

– Безнең ситуацион үзәктә көн саен бишләп тулы масштаблы видеоконсультация үтә – яздырып, пациентны тикшерүнең инструменталь методларын, рентгенограммаларны, лаборатория мәгълүматларын карап.

Сүз уңаеннан, Татарстанда ситуацион үзәкләр әйдәп баручы ике клиника – РКХ һәм РБКХ базасында эшли. ГЛОНАСС+112 системасы ярдәмендә санитар автотранспорт белән җитәкчелек нәкъ менә шуннан башкарыла. РКХнең яңа перинаталь үзәгендә дә кечкенә генә видеоэлемтә залы бар, аның белгечләре район табибларына йөклелекләрендә төрле патологияләр булган пациентларга ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирә.

– Бүген республикадагы барлык медицина учреждениеләре дә автоматлаштырылган эш урыннары белән җиһазландырылган һәм интернет челтәренә тоташтырылган, – дип сөйли ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры урынбасары Азат Мөгыйнов. – Алар барысы да (ФАПлардан башкалары) бердәм мәгълүмат системасында эшли. Әйе, медицина мәгълүматлары инде локаль түгел, ә бердәм үзәктә саклана.

2011 елда Татарстанда сәламәтлек саклауны заманчалаштыру федераль программасы гамәлгә кертелә башлады. «Татарстан Республикасында электрон сәламәтлек саклау» Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (БДМС) булдырылды. Бүген

PRESSA.RU

“ – Район хастаханәсенә йөрәге авырткан пациент китерелгән, – дип аңлата Марат Мәҗитов. – Ритм бозылу диагнозы куелган – тормышка куркыныч яный торган халәт бу. Безнең белгечләр табибка дәвалауның дөрес тактикасын сайларга булыша.

аны 18 мең медицина хезмәткәре куллана. Телемедицина тармагы өчен исә ул үзенә бер төрле мәгънәгә ия.

– 3,8 миллион электрон медкарта – Татарстан БДМСның бүгенге күләме шулкадәр, – дип сөйли Азат Мөгыйнов. – Әлбәттә, без әле юлның башында гына – татарстанлыларның электрон карталарында өлешчә мәгълүмат кына тупланган, әмма бу вакыт эше! Үзегез уйлап карагыз, 2016 елда гына да аларны 34 миллион язма тулыландырган. Бик тиздән БДМС телемедицинаны яңа баскычка күтәрү мөмкинлеген бирәчәк – табиблар пациент турында тулы медицина мәгълүматын аның кайда булуына карамастан оператив табачак.

ҺӘРВАКЫТ ЭЛЕМТӘДӘ!

Күзгә беренче күренгән нәрсә – бөтен диварны тутырып торган гаять зур экран. РКХ ситуацион үзәгендә мин телемедицинаның чынлыкта ничек эшләвен тикшермәкче булам. Табиб сере – телеконсультацияләрнең мәҗбүри аспекты, шунлыктан миңа язманың бер фрагментын гына күрсәтәләр. Ул безне Чистайга күчерә.

– Йөрәге авырта, салкын тир бәреп чыккан, – дип сөйли экраннан табиб. – Элек беркайчан да аның белән мондый хәл булмаган...

Сурәтнең бер өлешендә Казан күренә: линиянең икенче башында – РКХ кардиолог һәм аритмологлары. Диварда кардиограмма «яшене» пәйда булуга, Марат Мәҗитов язманы туктата.

– Район хастаханәсенә йөрәге авырткан пациент китерелгән, – дип аңлата ул. – Ритм бозылу диагнозы куелган – тормышка куркыныч яный торган халәт бу. Безнең белгечләр табибка дәвалауның дөрес тактикасын сайларга булыша.

Аның әйтүенчә, мондый мөрәҗәгатьләрнең лидерлары – Чаллы, Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт, Арча, Балтач хастаханәләре... Аңлашыла ки, бу һич тә җирле клиника табибларының белеме азрак, дигән сүз түгел.

– Кыен мизгелләрдә алар, башкалар белән киңәшеп, барысын да дөрес эшләүләрендә инаналар. Әмма, кызганычка, безнең аутсайдер районнарыбыз да бар, алар үзләре алдында ачылган мөмкинлекләрдән әлегә файдаланырга ашыкмый...

РКХ табиблары үзләре исә мондый мөмкинлекләрне кулдан ычкындырырга җыенмый: алар катлаулы очракларда дөньяның әйдәп баручы клиникаларына консультация сорап мөрәҗәгать итүдән тартынмый.

– Менә, мәсәлән, порфирия – сирәк очрый торган чир, Мәскәүгә исә андый авырулар бөтен илдән килә, шунлыктан башкала табибларының тәҗрибәсе зуррак, – дип сөйли Марат Мәҗитов. – Берничә тапкыр Майами университеты госпиталенә дә мөрәҗәгать иттек – эренле җәрәхәтләрне дәвалау буенча киңәшләштек. Майами шактый криминаль шәһәр, анда утлы коралдан, пычактан яраланучылар күп, шунлыктан табиблары бу өлкәдә – чын профессионал.

– Телеконсультацияләр форматы медиклар алдында мультидисциплинар мөмкинлекләр ача, бу инде чынга аша башлаган киләчәк элементы булып тора, – ди Мәҗитов.

– Бездә бервакыт төрле җирдән алты белгеч бер авыру турында киңәшләште. Ул чакта без, Мәскәү клиникалары, университет профессоры һәм пациент яткан Чаллы хастаханәсе элемтәгә чыктык – бу фантастика булды!

РКХнең телемедицинага кагылышлы статистикасы мондый: быел җиде айда табиблар 900ләп видеоконсультация үткәргән. Чагыштыру өчен: амбулаторияләрдә консультацияләр саны 200 мең тирәсе. Шул ук вакытта Марат Мәҗитов менә нәрсәгә басым ясый: «табиб-табиб» чылбырындагы телемедицина дәвалавы югары класслы яки тар профильле белгечләр катнашуын таләп иткән каты авыруларга гына кагыла. Бу белдерүдән соң 2017 елда барлыгы шундый 1000 консультация үткәреләчәк дигән фараз инде шактый саллы күренә.

ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР – ЕРАК АВЫЛЛАРГА

Элегрәк телеконсультация үткәрү өчен табибларга махсус техника кирәк булса, хәзер хәтта гаджет та эшкә ярый. Моннан бер-ике ай элек РКХ реанимация бүлекләре мөдирләренең смартфоннарына махсус кушымта куелган, ул видеоэлемтәнең саклана торган каналларыннан кичектергесез консультацияләр үткәрү мөмкинлеге бирә – табиб кайда гына булмасын, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында. Өчәр белгеч катнаша алган һәрбер мобиль конференция мәҗбүри язылып бара, кирәге чыкканда, аны кабат карап була.

Сүз уңаеннан, район табибы киңәш сорап мөрәҗәгать иткән белгеч үз карарларын дәлилсез-нисез кабул итми. Аның тәүлек әйләнәсендә Медицина сурәтләре үзәк архивына (МСҮА) керү һәм пациентның рентгенограммасы яки кардиограммасы белән оператив танышу мөмкинлеге бар.

– Асылда МСҮА – ситуацион үзәкләр эшенең нигезе, – дип сөйли Азат Мөгыйнов. – Аңа бөтен кыйммәтле цифрлы медицина җиһазлары – КТ, МРТ, ангиографлар һәм башка техника тоташтырылган – барлыгы 200 берәмлектән артык.

Әлеге архивта сакланган сурәтләр саны 250 миллионга якынлаша! Алар барысы да – пациентларның электрон медкарталарындагы мәгълүмат. 2017 елда республикада (МСҮА базасында) телемедицина технологияләрен кертүдә «Бердәм рентгенолог» проекты өстенлекле.

– Сервислар ерак районнардагы беренчел чылбырга диагноз куяр өчен махсус белемле табиблар тәҗрибәсен куллану мөмкинлеген бирә, – дип сөйли Азат Мөгыйнов. – Тикшеренүләр үзләре пациент булган җирдә үткәрелә, аларның шифрларын чишү һәм анализлауны исә югары технологияле медицина үзәкләре белгечләре башкара.

Иннополиста югары класслы белгеч тоту бик кыйммәткә төшә, менә шундый виртуаль күзәтүләр күпкә арзангарак чыга.

Шул рәвешле мәгълүмати технологияләр югарырак компетенцияләрне ерак район-авылларга җиткерергә булыша.

ФАНТАСТИКАНЫ КУЛЛАНЫП...

– Тере хирургның кулларын якын киләчәктә бернәрсә дә алыштыра алмаячак әле, – дип саный Марат Мәҗитов. – Шунлыктан без операцияләрне урыннарга барып ясыйбыз, ә менә аның барышын безнең ситуацион үзәктән күзәтеп торып була. Моннан тыш, роботлаштырылган система безгә пациентка диагноз куюда катнашу мөмкинлеген дә бирә. Мәсәлән, йөрәкне ультратавыш белән тикшерү (УЗИ) процессына кушылу һәм аны башкаручы табибтан теге яки бу өлкәне тәфсилләбрәк күрсәтүне сорый алабыз.

Ул кабат экранны кабыза, һәм без... Санта-Барбарага күчәбез. Минем каршымда – хастаханә бүлеге. Камера тормышны тәэмин итү аппаратларын күрсәтеп үтә һәм караватка җиткәч туктап кала. Анда исә пациент урынында... манекен ята!

– Без реанимациядә түгел, клиниканың шоу-румында гына, – дип елмая Марат Мәҗитов. – Монда перспектив технологияләр белән генә танышып калмыйбыз, система белән идарә итү күнекмәләрен дә шомартабыз. Моны табиб өчен тренажер дип әйтеп була.

Аннары без Иннополиска – инде чынбарлыктагы тернәкләндерү үзәгенә юнәләбез. Роботлаштырылган мобиль терәк – RP-Vantage системасы – зал буйлап йөри. Табиб РКХнең ситуацион үзәгеннән кешенең күнегүне ничек башкаруын, аңарда нинди алга китеш булуын күзәтә. Табиб тренажерның электрон таблосына якынрак килергә һәм параметрларны күрергә, кеше белән аралашып, программага төзәтмәләр кертергә мөмкин. Клиникадан читкә китмичә, консультацияне дистанцион үткәреп булганда, турыдан-туры тернәкләндерү залында булу зарурлыгы калмый. Хәер, тагын бер аспект та бар – икътисадый. Иннополиста югары класслы белгеч тоту бик кыйммәткә төшәчәк, виртуаль күзәтүләр күпкә арзангарак чыга.

Мондый видеотерәкләр бүген барлык район хастаханәләренең реанимация бүлекләренә дә куелган. Алар РКХнең югары класслы белгечләренә каты авыруларны ерактан торып күзәтү мөмкинлеген бирә. Мондый җиһаз Казанның технологик яктан алга киткән 7 нче хастаханәсендә дә бар.

ИНТЕРНЕТ БУЕНЧА ТАБИБ

Россиядә быел 25 июльдә «Сәламәтлек саклау тармагында мәгълүмати технологияләр куллану мәсьәләләре буенча РФнең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителде. Андагы иң зур маддә телемедицина технологияләренә багышланган. Ул, телемедицина хезмәтләре күрсәтү чылбырын авыруга кадәр китереп җиткереп, медицина хезмәткәрләренең үзара гына түгел, пациентлар белән дә үзара дистанцион бәйләнешен көйләп, илдәге сәламәтлек саклау тармагында яңа чор ача.

– Бүгенге көнгә кадәр «табиб-пациент» дәрәҗәсендәге телемедицина бездә норматив киртәләр аркасында үсеп китә алмады, – дип сөйли Азат Мөгыйнов. – Мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе урнаштырылмаган иде, якларның җаваплылыгын аңлау да булмады... Яңа закон гамәлдәге норматив базага телемедицинага кагылышлы үзгәрешләр кертә. Бүген без федераль министрлыклардан шул законга туры килгән актлар көтәбез.

Министр урынбасары республикада якын арада гамәлгә кертеләчәк телемедицина проектларына әлегә анонс ясамады, әмма аларның инде эшләнеп ятуында ышандырды.

– Без телемедицина технологияләре кулланылган медицина консультацияләре халыкка тулы күләмдә күрсәтелә башлаячак гаять көчле үзгәрешләр башында торабыз.

– Ә халык үзе моңа әзерме соң?

– Әлбәттә! Мин электрон сервислардан файдалануга безнең гражданнар күнекте инде дип саныйм – моңа ТР Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы ярдәм итте. Әйтик, былтыр татарстанлылар табибка өйдән язылу мөмкинлегеннән 11 миллион тапкырдан артыграк файдаланган.

Марат Мәҗитов әйтүенчә, телемедицинаның яңа аспектлары табибларның дә гайрәтен чигерми, чөнки аларның һөнәрләре гел яңаны өйрәнүне таләп итә. Моннан тыш, аның фикеренчә, закон әлеге тармакка хосусый бизнесның керү мөмкинлекләрен дә ача, бу исә, һичшиксез, сәламәтлек саклауда инновацион технологияләр үсешенә булышачак.



Сессия тәмамлаганда катнашучылар республика проектларына һәрьяклы анализ ясадылар, һәм шулай ук Татарстан өчен нәтиҗәле булган проектлар белән идарә итү моделенең ихтимал вариантларын эшләделәр.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН 100 ПРОЕКТ

Быелның җәендә КФУның Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбендә республика җитәкчелеге өчен проектлы идарә буенча квалификация күтәрүгә багышланган ике программага старт бирелде.

Автор:
Ксения Сёмина

Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе Игорь Привалов сүзләренә караганда, мондый курсларны оештыру идеясе әле 2015 елда ук туган булган. Ул чакта РФ Президент Владимир Путин үзенең Федераль Җыенга Юлламасында проектлы идарәне дәүләт хакимияте органнары эшендә нәтиҗәле инструментларның берсе сыйфатында билгеләп үтә. Быел Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе тарафыннан, «СКОЛКОВО» Мәскәү идарә мәктәбе белән уртак һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты күрсәтмәсе буенча эшләнгән программа уңышлы тәмамланды. Әлеге курсларның нигезенә РФнең башка төбәкләрендә проектлы идарәне кертүнең иң яхшы үрнәкләре, чит илләр тәҗрибәсе, һәм шулай ук үсеш темпларын арттыра барган Татарстанның бүгенге һәм иртәгәге таләпләре ята.

2017 елның 9–11 июне көннәрендә «Свияжские холмы» комплексы территориясендә «Татарстан Республикасының стратегик проектлары белән идарә итү моделе» стратегик сессиясе форматында узган беренче программага старт бирүдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашкан иде. Ул Татарстан Республикасында проектлар белән идарә итү моделен эшләүгә багышланган пленар дискуссиядә чыгыш ясады һәм әлеге сорауны ничек күзаллавы турындагы фикерләре белән уртаклашты.

Программада катнашучылар каршында чыгыш ясап, «СКОЛКОВО» Мәскәү идарә мәктәбе президенты Андрей Шаронов, Татарстанның федерация субъектлары арасында проектлы идарә буенча лидерларның берсе булуын билгеләп үтте.

– Сез масштаблары буенча республика дәрәҗәсеннән күпкә югарырак булган шактый зур сандагы проектларны гамәлгә ашырдыгыз, – ди ул үзенең чыгышында. – Проектларның барысы да уңышлы башкарылды. Бүген эшләтеп җибәрелгән программаның максаты – дөнья тәҗрибәсе үрнәгендә республикада, шул исәптән муниципаль дәрәҗәдә идарә процессын тотрыклырак, нәтиҗәлерәк итү. Республикада берүк вакытта 10–15 проект кына түгел, йөзләгәнен алып бару өчен нәрсә эшләргә.

Программаны тыңлаучылар арасында Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин,Татарстан Республикасы хөкүмәте әгъзалары, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары бар иде.

БЕР ТАБЛИЦА БУЕНЧА ЭШЛӘРГӘ

Укулар июльнең икенче яртысында дәвам итте. Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе мәйданчыгында квалификацияне күтәрүгә багышланган «Проектлар белән идарә итү» модуль программасы узды. Ул шулай ук Сколково белән уртак эшләнгәнде. Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр (дәүләт органнары җитәкчеләре урынбасарлары, башкарма комитет җитәкчеләре урынбасарлары һ.б.лар) проектларны гамәлгә ашыру этапларының һәрберсендә алар белән идарә итүнең гамәли методларын һәм инструментларын өйрәнү мөмкинлегенә ия булдылар. Беренчесе кебек үк, әлеге программа да өйрәнүчеләрнең командада үзара конструктив эш итә алуларына нигезләде. Моның шулай булуына «Татарстан» хәбәрчесе программаның агымдагы елның 16–18 августы көннәрендә Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбендә уздырылган икенче өлешендә шәхсән үзе катнашып инана алды.

– Бүген республиканың әйдәп баручы муниципалитетлары үсеше трендларының берсе мондый: башлыклар бик актив рәвештә инвестицияләр эзли. Һәм менә күз алдына китерегез: муниципалитет үз территориясенә резидентка ниндидер ташламалар бирә торган статуска ия булмаган инвесторны таба. Соңгысы, әйтик, эшкәртү предприятиесе төзи башлый, – дип идея бирә семинар модераторы. – Ләкин шул ук вакытта министрлык яисә агентлык АСИУТ статусына ия күрше муниципалитетта башка инвесторны табып, шундый ук проектны эшләтеп җибәрә. Бу очракта беренче инвестор кыен хәлдә кала. Сез ничек уйлыйсыз: ведомство проект офислары һәм муниципаль проект офислары әлеге проектларны максималь дәрәҗәдә нәтиҗәле итеп гамәлгә ашыру өчен үзара ничек эш итәргә тиешләр иде?

Иркен аудиториядә төркемнәргә бүленгән катнашучылар үз «өстәлләре»ндә бурычны тикшерә башлыйлар. Биш минуттан

Реклама

һәр төркем вәкиле үз җавапларын һәм аңлатмаларын бирә.

– Инициатива муниципалитетта да, министрлыкта да туарга мөмкин. Ләкин без максатчан күрсәткечләргә ирешү өчен җаваплылыкны барыбер проект гамәлгә ашырыла торган муниципалитет алып барырга тиеш дип саныйбыз, – ди катнашучыларның берсе, үз төркеменең фикерен башкаларга җиткереп.

– Республикада проектлар төрле баскычларда: федераль, республика, муниципаль, авыл советы дәрәҗәләрендә тормышка ашырыла. Ягъни билгеле бер градация бар, уйлавыбызча, гамәлдәге проект офисларының вәкаләтләре дә шуңа ярашлы рәвештә чикләнергә тиеш. Әмма кайсы гына офиска мөрәҗәгать итүенә дә карамастан, безнең өчен инвестор проектының югалмавы барыннан да мөһимрәк. Шулай да проектны гамәлгә ашыру җаваплылыгы муниципаль проект офисына төшәргә тиеш, министрлык методик ярдәм һәм ресурслар белән булышу өчен җавап бирә, – дип өсти чыгыш ясаучы төркеменнән тагын бер вәкил.

– Проектларның күп булуы һәм аларның төрлелеге әйбәт бит. Әгәр кешеләр акчаларын эшкә җигәргә телиләр икән, моны мөмкин кадәр нәтиҗәле итеп башкару өчен тырышырга кирәк. Әлбәттә, инвесторлар ихтимал булган югалтуларны күз алдында тотарга тиеш, югарыда аталган мисалдагы кебек хәлләргә тарымас өчен, без ярдәмгә килергә тиеш. Моның өчен инвестпроектларның бердәм базасын булдыру зарур, безгә бер таблица буенча эшләргә кирәк, – ди өченче оператор.

Модератор аудиториядән тагын фикерләр бармы дип сорый, һәм флипчарт битендә барлык әйтелгәннәрне терки. Аннан соң чираттагы «кейс» белән таныштыра. Төркемнәр яңа дәрт белән аны тикшерергә керешә.

БЕР ГЕНӘ КӨНЛЕК ЭШ ТҮГЕЛ

Курсларны оештыручылар шуны ачык аңлый: бүген Татарстанга проектлы идарәне гамәлдәге дәүләт идарәсе системасына анда инде булган механизмнарны, ресурсларны, оештырылган структураларны максималь дөрес кулланып кертеп җибәрергә кирәк. Һәм әлеге процессны дәүләт граждан хезмәткәрләренең проектлы идарә өлкәсендәге профессиональ компетенцияләрен үстерүдән башлап җибәрергә кирәк.

Шуңа күрә катнашучыларга бергәләшеп уйлау форматында теорияне һәм республикабызда инде булган проектлы идарә тәҗрибәсен синхронлаштыру, аны кертүнең өстенлекләрен генә түгел, ихтимал югалтуларны да ачыклау, теоретик концепцияләр белән көйләнми торган сорауларыбызны формалаштырырга һәм аларга җавап табарга тырышу тәкъдим ителде. Нәтиҗәдә һәр төркем Татарстанда республиканың киләчәген билгеләргә тиешле проектлы идарә моделенең төп компонентларын төгәлләштерде. Эшнең төп өлешен Икътисад министрлыгы үз өстенә алды.

Курсның теоретик өлешен «СКОЛКОВО» Мәскәү идарә мәктәбенең корпоратив клиентлары («Лукойл», ЕВРАЗ, «Новатэк») өчен үткәрелгән курслар нәтиҗәләре буенча максималь югары бәя алган Сколковоның программалар өчен проектлы идарә буенча уку материалларын һәм курсларын эшләүчесе, профессор Джордж Сифри үткәрде.

Motorola, HP, Dow Jones, BP (British Petroleum), «Лукойл», PKN Orlen, PeopleSoft, ABB, Eurolet һәм Novartis* кебек компанияләрдә өйрәтү курслары алып баручы, Проект-инжиниринг академиясенең төп курсларын, проектлар белән идарә итү буенча күпләгән курслар эшләүчесе һәм укытучысы профессор Сифриның күпьеллык һәм актуаль тәҗрибәсе тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты.

– Катнашучыларны бүген барган процесслар, булган техника, инструментлар белән таныштырасы килә. Тыңлаучылар аларны камил дәрәҗәдә кулланырга кирәклеген аңларга тиеш, һәм шул очракта гына максималь уңышка ирешеп булачак, – дип, кыскача үз фикерен формалаштырды сессиядә доктор Сифри. – Шулай ук катнашучылар шуңа да төшенергә тиеш: проектлар белән идарә итү офисы эшен оештыру өчен, күп нәрсә эшләргә кирәк. Бу бер генә көнлек эш түгел.

Катнашучылар тарафыннан республика башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә проектлы идарәне кертүнең уртак концепциясе төзелү программаның нәтиҗәсе булды. Проектлы идарәне гамәлгә кертү технологияләре буенча эшләнгән тәкъдимнәр профильле министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре дәрәҗәсендә килештерелер һәм норматив актларны эшләү өчен нигез булып торыр, дип планлаштырыла.

* Моторола, ЭйчПи, Доу Джонс, Бритиш Петролиум, Лукойл, ПКН Орлен, ПиплСофт, ЭйБиБи, Евротель, Новартис.

PRESSA.RU

«ЧИНОВНИК БУЛЫР ИДЕМ! ӨЙРӘТСЕННӘР ГЕНӘ!»

Үзендә киләчәктә дәүләт эшендә эшләрлек көч һәм омтылыш тойган, әмма бүген әлеге профессиягә турыдан-туры катнашлыгы булмаган белгечлеккә укучы студентка нишләргә? Вакытны әрәм итмәскә һәм өченче курстан «Татарстан Республикасында Дәүләт һәм муниципаль идарә кече академиясе» проектына әләгергә тырышырга!

Татарстанда 10 ел эчендә Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган проект кысаларында академияне республиканың төрле вузларыннан 150 кеше тәмамлаган.

Монда укырга теләүчеләрне кайбер сынаулар да көтә, шуларның берсе, әйтик, кеше укырга кергәндә чиновник эшенең җентекле хезмәт, зур җаваплылык, һәм шул ук вакытта һәрвакыт яңа белем алу һәм ил үсешенә шәхси өлешеңне кертү мөмкинлеге икәнлеген аңларга тиеш.

Кече академия студентын беренче көннәрдән ук менә шуңа әзерлиләр. Мастер-класслар, проект эшләре, экскурсияләр, түгәрәк өстәлләр,бәхәс клублары, эшлекле уеннар, «уку-өйрәнү министрлыгы» – барысы да булачак белгечләр дәүләт хезмәте атмосферасын укыганда ук тоя алсыннар өчен оештырылган. Мәсәлән, һәр инициативалы яшь кеше үзен закон иҗат итүче роленә куеп карый ала. Һәм академия мондый мөмкинлекне бирә: иң кызыклы биремнәренең берсе – «Парламент 2030» эшлекле уены. Бу вакытта курсларда укучылар Россия Федерациясе Федерация Советы эксперты җитәкчелегендә федераль закон проектларын эшли алалар. Иң уңышлы дип табылганнары РФ Дәүләт Думасы тарафыннан уздырыла торган конкурска юллана һәм депутатларның бәясен ала.

Дәүләт хакимияте органнары структурасының ничек эшләве турында булачак белгечләрдә төгәл күзаллау барлыкка килсен өчен, академия әлеге учреждение хезмәткәрләренә генә керү рөхсәт ителгән урыннарга экскурсияләр оештыра. Академия студентлары өчен Казан Кремленең Губернаторлар сарае ишекләре, аның сөйләшүләр һәм тантаналар алып барыла торган заллары ачыла, һәм шулай ук ТР Президентының Дәүләт беркетмәсе идарәсе вәкиле Татарстан Президенты катнашлыгындагы чараларның ничек оештырылуы һәм уздырылуы турында сөйли. Аларга утырышлар залына, киңәшләшү бүлмәсенә һәм ТР Конституция суды музеена керү рөхсәт ителә, студентлар өчен республика прокуратурасының Җәмәгать кабул итүе эшендә катнашу, Татарстан Республикасында РФ Президенты Владимир Путинның кабул итү бүлмәсе эше белән танышу оештырыла.

Лекторлар сыйфатында академиядә укучылар каршында яшьләр белән дәүләт эшчәнлеге буенча тәҗрибә уртаклашырга әзер экспертлар – РФ Федерациясенең Федерация Советы әгъзалары, республика министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре һәм җитәкче урынбасарлары чыгыш ясый.

Ләкин практикадан башка теория нәтиҗәле түгел. Шуңа күрә материалларны үзләштерү барышында, дәүләт хакимияте федераль органнарының территориаль бүлекләрендә, министрлыкларда һәм ведомстволарда һәм муниципалитетларда стажировка үтеп, студентлар булачак профессияләренә күбрәк төшенә баралар. Ә алар арасыннан иң яхшылары Россия Федерациясе Дәүләт Думасында стажировка үтәләр, студентлар анда эшләүче хезмәткәрләрдән бүгенге партияләр эшчәнлегенең үзенчәлеге, тыңлауларны оештыру һәм закон иҗат итү этаплары турында мәгълүмат алалар, һәм хәтта РФ Дәүләт Думасының берәр ведомствоара чарасында катнаша мөмкинлегенә ия булалар.

Уку һәм тиешле күнекмәләр үзләштерү барышында, студентлар Россия дәүләтчелеген үстерү проблемалары буенча үз тәкъдимнәрен кертәләр, фәнни, социаль, сәяси, икътисадый, бизнес сфераларында үз проектларын эшләү мөмкинлеге алалар. Иң яхшы проектлар «iВолга» Идел буе федераль округының Яшьләр форумы конкурсына юллана, җиңүгә ирешкән авторларга идеяләрен гамәлгә ашыру өчен грантлар тапшырыла.

«Кече академияне тәмамлаучылар – Россиянең үсеше һәм чәчәк атуы өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең киләчәк буыны» – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор Ренат Тимерҗанов проектка шундый бәя бирә.

Нәкъ менә монда, академиядә, Татарстанның талантлы һәм максатчан яшьләренә дәүләт хакимияте органнарында эшләү өчен яхшы старт алуның уникаль мөмкинлеге бирелә. Энергияле, максатчан, иҗади фикерләргә сәләтле яшьләрне эзләү, сайлап алу, укыту һәм аларга булышу буенча даими эш алып барыла, аларның бөтен мөмкинлекләрен ачу өчен шартлар тудырыла.

Һәр чыгарылышка йомгак ясый торган «Һөнәри әзерлек программасының максатына ирешелде» формуласы кече академиянең эшләү еллары өчен үзгәрешсез кала бирә. Бу республиканың «алтын» кадрлар резервы Татарстан дәүләтчелегенең күп гасырлык традицияләрен сакларга һәм үстерергә әзер яңа белгечләр белән тулылана бара дигәнне аңлата.

Реклама

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Татарстан» радиосына **НИЧӘ** яшь

Биш җәмәгать урынын **НИЧЕК** үзгәртергә

Кухня кунагы **НӘРСӘ** белән сыйлый

1

2

«БЕЗ КОНСЕРВАТИВ БУЛУЫБЫЗ БЕЛӘН КЫЗЫКЛЫ»

Аз да түгел, күп тә түгел: 90 яшь аларга. Кайчандыр, узган гасыр башында «Тыңлагыз, тыңлагыз! Казан сөйли...» дип, һәрбер өйгә килеп кергән «Татарстан» радиосының бүген бер гасырга якын тарихы бар. Һәр заманның афәтен дә, шатлыгын да үзе аша кичергән бу радионың кайбер кызыклы сәхифәләренә кыскача гына сәфәр кылып алыйк әле...

Автор:
Луиза Янсуар

«ӘНИЕМНЕҢ ҺӘР ИРТӘСЕ ТАТАРСТАН РАДИОСЫ БЕЛӘН БАШЛАНА»

Фирдүс Гыймалетдинов, «Татарстан» ДТРК директоры:

– Бездә һаман да 45–50 минутлы тапшырулар яңгырый. Бүгенге көндә бу уникаль күренеш. Кемдер моны архаизм буларак кабул итә ала. Хәзер радиоларда тапшырулар 8–10 минуттан да артык булмаска тиеш, дигән фикер дә бар. Килешеп бетә алмыйм, чөнки безнең татар кешесе сөйләшергә ярата. Ә бердәнбер сөйләшү радиосы булып, асылда, «Татарстан» радиосы калды. Сүз җитди әңгәмә турында бара.

Тыңлаучылар аудиториясе башлыча 40тан узган кешеләрне тәшкил итә. Нигездә, бу – хатын-кызлар. Әмма бу безне ир-атлар һәм яшьләр тыңламый дигән сүз түгел. Шалтыратулар буенча аңлашыла: төрле буын һәм һөнәр вәкилләре бар. Авыл кешеләре яратып тыңлый. Бу да – традиция. Иртәнге алтыда башлыйбыз эшне, һәм безне Татарстанның районнарындагы халык кабызып куя. Минем әнине генә алыйк, кухняда аның иртәсе, еллар дәвамында гадәтләнгәнчә, «Татарстан» радиосы белән башлана. Минеке дә шулай. Авылларга якынаю өчен, республика буенча без хәзер FM форматына күчтек. Республика буйлап йөргәндә үзебезнең радионы һәрчак «тотам», бөтен төбәкләрдә диярлек трассада, авылларда ул бар.

Бездә «алтын фонд» саклана. Дусларым арасында нәкъ менә шул фондны тыңлаучылар бар. 60–70нче елларда яздырылган спектакльләрне юлга чыкканда машинада тыңлап барыр өчен махсус соратып алалар. Мин әлеге фондны сату яклы түгел. Без ул язмаларны акрынлап сайтка урнаштырып барабыз, әлбәттә, бушлай. Алар дәүләт архивында да саклана. Фондтан бизнес ясау «Татарстан» радиосы эше түгел. Без язмаларны югары кимәлдәге сәнгати тапшырулар өчен нигез буларак кулланабыз.

Татар телендә булган күңел ачу радиоларын да кире какмас идем мин. Кеше, дөньяга килгәч үк, опера тыңлый башламый, балет карарга бармый бит. Барлык төр татарча радиолар да үз максатын үти – телне саклый. Без үзебезнең зәвыклы тыңлаучы өчен эшлибез. «Татарстан» радиосының аудиториясе гасыр дәвамында билгеләнгән. Әйтик, винил пластинкаларның үз тыңлаучысы бар бит. Безнең радионың эчтәлеге дә шул винил пластинкалар шикелле – һәрбер татар кешесе аңа акрынлап барыбер килә. Конкрет бер композитор җырларыннан төзелгән тапшыруларны гына алыйк. Мин бәләкәй чакта да шундый иде алар, хәзер дә. Аларны заман таләбенә йөз тотып үзгәртүне кирәк дип исәпләмим. Без – консерватив радио. Без әнә шуның белән кызыклы да. «Культура» каналы кебегрәк... Һәм шул консервативлыктан китсәк, мөгез чыгарып, бер гасырлык мирасыбызны сызып ташларга мөмкинбез.

Федераль канал буларак, бирелгән вакыт кысаларында, штат мөмкинлекләрен файдаланып, милли бурычны үтәргә тырышабыз. Татарча тапшыруларның күләме рус телендәгеләргә караганда өч тапкырга артыграк. Без – «Россия24» эфирында иң күп вакыт алып торучы төбәк филиалы. Россиядәге җитәкчелек милли тапшыруларның яшәргә хокуклы һәм үз халкына никадәр

1. Радио студиясе дә, театр сәхнәсе дә.

2. Режиссер пультында – Әлфия Гыйләҗи, Татьяна Олудина, Рамил Һидиятуллин.

Фотолар «Татарстан» радиосы архивыннан алынды

кирәкле икәнлеген аңлап эш итә. Тәүлегенә биш сәгать ярым эфирга чыгабыз. Чагыштырып карасак, башка төбәкләрдә әлеге эфир вакыты сәгать-сәгать ярымны гына алып тора. Азмы ул, күпме безгә бирелгән вакыт, – һәркем үзе өчен хәл итә инде. Заманалар да, мөмкинлекләр дә үзгәреп тора. Әмма без бүгенге шартларда мөмкин булганның бөтенесен дә эшлибез.

«ЯШЬ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҮЗ РАДИОСЫ БУЛЫРГА ТИЕШ...»

Россиядә «радио инкыйлабы» Мәскәүдән түгел, ә нәкъ менә Казаннан башлана. 1921 елның 1 маенда Казанның хәзерге Ирек мәйданында телефоннан сөйләшүне көчәйтүче рупор куела һәм ул хөкүмәт сәясәтен халыкка җиткерүче мөһим чарага әверелә. Берничә көннән «Известия» газетасы бу хәбәрне бөтен илгә тарата: «Казан шәһәрендә инженер Чистовский уйлап чыгарган телефон көчәйткече күрсәтелде. Телдән газета рупор аша укылды. Әлеге ачыш меңәрләгән кешедә соклану тудырды». Хәбәр Ленинның игътибарын җәлеп итә һәм ул Совнарком секретаре Н.П. Горбуновка күрсәтмә юллый: «Иптәш Горбунов! Мин бүген Казанда телефон тавышын көчәйтүләре турында укыдым. Сынап карау бик әйбәт нәтиҗәләр биргән. Тикшерегез! Әгәр дөрес булса, Мәскәүдә һәм Питерда да куярга кирәк!»

Н.П. Горбунов күрсәтмәсе белән Казаннан аппаратлар сатып алына, 1921 елның май ахырларында Мәскәү Советы бинасына рупор урнаштырыла. Ә Казанда… радио идеясе белән 1922 елның җәй ахырында хәрби җыеннан кайткан революционер, язучы Шамил Усманов мавыгып китә. Ул чакта әле Германия, Франция кебек техник яктан алга киткән илләрдә дә тапшырулар даими алып барылмый. Һәм менә Казанда талантлы инженер Александр Углов Мәскәүдән тапшырылган якшәмбе концертларын трансляцияли башлый. Бу хәл Шамил Усмановны үзебездә көчле радиостанция төзү фикеренә этәрә. «Яшь Татарстан Республикасының үз радиосы булырга тиеш» дигән идеяне яклап, ул VI өлкә партия конференциясендә чыгыш ясый. Әмма аны аңларга теләмиләр. Ул татарча һәм русча газеталарда мәкаләләр бастыра. Ахыр чиктә, мәсьәләне җентекләп аңлатып, нигезләп, Татарстан Халык Комиссарлары Советына язма юллый. Комиссия радиофикацияләү эшенең перспективалы булуын таныса да, техник һәм матди ягын сылтау итеп, проектны кире кага.

Ул арада инде радиотапшырулар бөтен ил күләмендә яңгырый башлый. Республикалар бер-бер артлы үз радиоларын булдыра. Эфирда Саратов, Ташкент, Махачкала, Харьков, Түбән Новгород станцияләре пәйда була. Ә Казан... дәшми. Татарстанда радио булдыру мәсьәләсе киңәшмәләрдә хәл ителү этабыннан уза алмый. Тынгысыз Усманов үҗәтләнүен дәвам итә: ул кат-кат ВКП (б) өлкә комитетына, Халык Комиссарлары Советына мөрәҗәгать итә. Мәсьәлә, ниһаять, Октябрьнең 10 еллыгына әзерләнгән көннәрдә хәл ителә. Дәүләт комиссиясе Казанда артык кыйммәтле булмаган радиостанция төзергә мөмкин дигән карарга килә. Яшь оешманың җитәкчесе итеп әлеге дә баягы «Усманов иптәш»не билгелиләр. Һәм ул башы-аягы белән оештыру, хуҗалык эшләренә кереп чума: җиһазлар юнәтә, белгечләр туплый, әле Мәскәүгә, әле Ленинградка чаба. Татарстан радиосы, ниһаять, билгеләнгән вакытта телгә килә.

> *«Дулкынның озынлыгы 750 белән 800 буласын алдан сорашып белгәнгә, радиоалгычымны шул диапазонга көйләп куйдым. Менә берзаман: «Слушайте, слушайте! Тыңлагыз, тыңлагыз! Говорит Казань! Казан сөйли!..» – дигән сүзләр ишеттем. Йөрәк ярсый, күңел дулкынлана...*
> *Әтием, бик зур игътибар белән тыңлаганнан соң:*
> *– Молодец, Шамил Усманов! Булдырды бит, йөри торгач! – диде...»*
>
> *Җәүдәт Фәйзи истәлекләреннән.*

«СЕЗ ДӘ ЫШАНЫГЫЗ...»

1927 елның 7 ноябрендә, беренче тәҗрибәдән соң озак та үтми, Казан үз тапшыруларын даими яңгырата башлый. «Татарстан» радиосы яралган беренче айлардан ук, сәясәт белән бергә, әдәбиятка һәм музыкага да зур әһәмият бирә. Исмәгыйль Һилалов искә алуынча, беренче татарча концерт Углов лабораториясендә вакытлыча җиһазландырылган, кара калын тукыма белән эчләнгән кечкенә генә студиядән алып барыла. Ул 2–3 кешене генә сыйдырырлык була.

Радио тиз арада яшь иҗат көчләрен берләштерүче үзәккә әйләнә. «Татарстан» радиосының техник өлешен тынгысыз җанлы инженерлар хәл итсә, рухи ягын – язучылар, артистлар, композитор-

1. Радиога нигез салучы – Шамил Усманов.

2. Радиокомитетның халык музыка уен кораллары кече оркестры. 1935-1937 еллар.

1. Алып баручылар: Камал Саттарова, Эльс Гадел.

2. Редакция хезмәткәрләре.

3. «Татарстан» радиосы коллективы – җәйге бакчада.

лар, галимнәр, җырчылар кайгырта. Ә караңгы авылларда яшәүче халык баштарак радиодан яңгыраган тавышларны бер-бер сихер дип пошаманга төшә. Бу хакта Шамил Усмановның бер язмасы да сакланган:

«Сөннәтле бүреген бик шәпләп бастырып кигән, билен каты итеп буган сары тунлы авыл егете радиостудиягә килеп керә. Кулында – авыл советыннан бирелгән язу. Анда «Радио эшләре белән танышу өчен җибәрелә» дигән.

– Абзыйлар, мине авыл халкы шушы сезнең рәдиу белән танышып, әртистләрне күреп, тыңлап, аннары шушы рәдиу аркылы бер-ике авыз сүз әйтергә кушканнар иде, – ди.

Микрофон алдына килгәч тә, бик каты итеп тамак кырып ала:

– Мин Арча кантоны фәлән авылның Исмәгыйль Фәтхуллин булам. Агайлар, сез мине рәдиу белән танышып кайтырга дип җибәргән идегез. Менә мин килдем. Бөтен җырчыларны, уйнаучыларны күрдем. Рәдиунең үзе белән сөйләштем. Хәзер инде мин рәдиугә ышандым. Сез дә ышаныгыз... »

ИДЕЛ БЕЛӘН УРАЛ АРАСЫНДА ГЫНА ТҮГЕЛ...

«Алтын фонд» дигәндә, әнә шул күздә тотыла да: һәр чорның иң күренекле сәнгать әһелләре биредә эшли, языла, кунак рәвешендә генә булса да, килеп китми калмый. Әлеге традиция бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Кайчандыр үзенең оркестры эшләп килгән, чорының иң олы җырчыларын, музыкантларын яздырып барган, әдипләргә әдәби сүз өчен мәйдан биргән радио хәзерге сәнгатькәрләрнең дә иҗатын берәмтекләп барлый. Бу, әлбәттә, яңалыклар кебек федераль курсны ышанычлы, тигез алып баруы белән параллель рәвештә.

Балалар иҗатына да зур игътибар бирәләр монда. Әйтик, Бөек Ватан сугышы елларында радионың Балалар тапшырулары мөхәррире Гадел Кутуй кечкенә тыңлаучылар өчен махсус "Яшь герой мажаралары" циклын ачып җибәрә. Соңыннан ул тапшыруларның бер өлешен язучы «Рөстәм маҗаралары» китабында да файдалана. Хәзерге көндә исә радиода **балалар һәм яшүсмерләр тапшырулары мөхәррире вазыйфасын язучы Дания Гайнетдинова** башкара. Ул эшләгән елларда гына да инде берничә буын сәләтле яшьләр «Татарстан» радиосының фатыйхасын алып өлгерде. Мин үземнең беренче тапкыр килеп, биредә курка-курка, ояла-ояла гына шигырь укыган мәктәп укучысы чакларымны хәтерлим...

– Без мәктәпләргә, балалар бакчаларына очрашуларга даими йөрибез, талантларны шуннан барлап, туплап, яздырып алып кайтабыз. Аерым-аерым кайберләрен студиягә чакырып та яздырып алабыз. Белсәгез икән, бүгенге сәнгатьтә, спортта һәм башка өлкәләрдә танылып, үз урынын тапкан күпме күренекле шәхеснең балачакта безнең радио аша узганнын... Бу безнең эшебезнең юкка булмавына, бәрәкәте барлыгына дәлил.

Әйтергә кирәк, сугыш елларында «Татарстан» радиосы үзенең эшчәнлеген нәкъ тыныч шартлардагы темпта, хәтта аннан да тыгызрак ритмда алып бара. Бөек Ватан сугышы елларында информацион программалар арттырыла. Электән тәүлегенә 2 сәгать 30 минут эшләп килгән радио 1941 елның сентябреннән 3 сәгать ярым дәвамында сөйли башлый. Элек иртәнге тапшырулар 6 сәгать 30 минутта эфирга чыкса, 5 сәгать 30 минутка күчерелә. Шул рәвешле, Башкомандующий фәрманнары һәм Совинформбюро белдерүләре Мәскәү тапшыруларыннан алда татар телендә бирелә.

Җиңү килгәч, фронттан исән-сау әйләнеп кайткан язучылар, музыкантлар, артистлар радиода яңа бер рух белән эшли башлый. Техник персонал ныгытыла. 1958 елда «Татарстан» радиосы инициативасы белән, автономияле республиканы берләштергән тарихи «Идел белән Урал арасында» тапшырулары эфирга чыга башлый. Бу тапшыру бүген дә Татарстан радиосының олы горурлыгы булып тора. Ул хәзер 7 республиканы берләштерә, үзенә күрә милли төбәкләрнең пульсациясен билгеләүче вазыйфасын башкара.

«Радиога мин 1945 елның язында урнаштым. Беркадәр балалар редакциясендә эшләгәннән соң, радиокомитетның ул чактагы рәисе Гариф Гобәй әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә күчәргә тәкъдим итте. Минем өчен бәхетле көннәр башланды. Аз гына вакыт эчендә бик күп эш эшләнде, зур-зур радиопостановкалар дөнья күрде. Лев Толстойның заманында бөтен СССРда шаулап барган «Анна Каренина»сы татар тыңлаучысына ифрат көчле тәэсир итте. Гомәр Бәшировның «Намус» романына нигезләнгән радиопостановка да тыңлаучыларыбызның күңеленә хуш килде...»

Әмирхан Еники истәлекләреннән.

1960–1980нче еллар радионың гөрләп эшләгән еллары буларак искә алына. Ә инде 1990нчы елларда, Милли азатлык хәрәкәте вакытында, ул гомумән дә үзенә күрә бер рупорга әйләнә. Шул еллардагы Татарстан Телевидение һәм радиотапшырулар

3

дәүләт комитеты рәисе Илгиз Хәйруллин искә алганча: «Илдә үзгәртеп корулар колач җәеп, әдәби һәм сәяси сүзгә игътибар арткан саен, эфирда яңгыраган тапшыруларга халыкның гына түгел, җитәкчеләрнең дә игътибары артты, кайчакларда җилнең кайсы яктан искәнен дә чамалап булмый торган сәясәт диңгезендә ышанычлы компасларның берсе буларак та кабул ителә башлады».

ТАРИХИ, ЯКИ МИЛЛИ ИММУНИТЕТ

«Татарстан» радиосының бүгенге көндә умырткасын, үзеген тәшкил иткән тапшырулар дистә еллар дәвамында, сәяси һәм мәдәни вазгыять, алшартлар нигезендә барлыкка килгәннәр. Аларның һәрберсенең үз бурычы, үз аудиториясе бар. Чорлар һәм буыннар алмашынып тора, әмма биредә бу сизелми диярлек. Монда заманчалык белән традицион рух янәшә атлый. Бу хакта бүгенге **радиотапшырулар хезмәте җитәкчесе Тәүфыйк Сәгыйтов** та әйтә:

– Җитәкче буларак, минем өчен иң мөһим шарт – радиода өч буын вәкиленең дә эшләве. Шулчакта гына коллективта сәламәт рух була. Моннан тыш, туплаган тәҗрибәне, осталыкны без, һичшиксез, яшь буынга тапшырып калдырырга тиешбез. Ә алар, инде үзләренең заман рухын кушып, без җитәкләгән радионы алга таба үстерергә бурычлы. Әнә шуңа да яшь кадрлар мәсьәләсендә без бик сак, нәзберек һәм таләпчән...

«Татарстан» радиосы ул – халыкны дәүләт белән тоташтыручы канал. Безнең очракта – милләтне кайгыртучы бер үзәк тә. Чөнки, без шундый шартларга куелганбыз. Элек тә шулай иде, хәзер дә шулай булып кала бирә. «КАМАЗ» төзелгән елларда без аның алдынгы сафларында булдык, суверенитет яуланган елларда – Дәүләт советында, мәйданнарда, халык арасында, телгә куркыныч янаган чорларда «Тел күрке – сүз» кебек тапшырулар әзерләп, татар теле сагына бастык. Бер генә мисалга тукталып узасым килә. Татарстан гимнының берзаман радиодан яңгыравы куркыныч астында калды. Мәскәүдән шалтыраталар: «Сез сеткадагы тәртипне бозасыз, Мәскәү тапшыруларына керәсез», – диләр.

– Нишләп, минәйтәм, – без яңалыкларны биштә, җидедә, сигездә тапшырабыз. Ә алтыда безнең үз тапшыруларыбыз башлана.

– Ярамый. Сезгә сетка буенча алты тулып ун минуттан гына башларга рөхсәт ителә.

– Әмма без биш тә илле җидедә – Россия гимнын, ә алтыдан Татарстан гимнын тапшырабыз...

– Берни дә белмим, рөхсәт ителми...

Югары җитәкчелеккә Россия белән Татарстан арасындагы дустанә, җылы мөнәсәбәтләрнең бары тик ике гимн да бер-бер артлы яңгыраган очракта гына була алганлыгын, халыкның үз радиосыннан туган телендәге республика гимнын ишетергә хокуклы булуын айлар буе аңлатырга туры килгән чаклар да булды...

Тәүфыйк ага белән радионың сәхифәләрен барлаганда, мондый четерекле мизгелләргә күп тукталдык. «Болар инде – эчтәге эшләр, сеңлем, иң мөһиме – безнең катлаулы заман шаукымында да, шөкер, үзебез булып калуыбыз», – дип хушлашты ул азакта. Ә редакциядә, мин аның кабинетыннан чыкканда, чынлап та яшьләр кайнаша иде. Эш хакы белән әллә ни куандырмый торган шартларда да, биредә, радиожурналистика өлкәсенә, әнә шулай энтузиаст кадрларның килүе – үзе бер феномен, дияр идем. Бу да безнең әлеге дә баягы консервативлыгыбыз, ә бәлки, четерекле вакытларда үзебезне саклар өчен уяна торган генетик ресурсларыбыз, хәтта ки тарихи-милли иммунитетыбыз турында сөйләмиме икән?

Нәсим Акмал, әдәби-нәфис тапшырулар бүлеге мөхәррире:

– Кайчандыр, мин монда эшкә килгәндә, гаҗәеп олпат, затлы кешеләр арасына килеп эләктем, дип сөенгәнем хәтердә. Кайберләре хәзер дә эшли. Техник яктан да көчле командасы белән аерылып торды радио һәрвакыт. Тапшыруларның мөхәррирләре, алып баручылары булып озак еллар дәвамында республиканың танылган сәнгать әһелләре эшләде һәм эшли. Язучылар, композиторлар, тел белгечләре, артистлар...

Федераль дәүләт каналы буларак, радио сәясәтне яктыртуга зур игътибар бирде һәм бирә. «Депутат каналы», «7 көн» тапшырулары – шундыйлардан. «Татарстан» радиосы ул – халыкка дәүләт дәрәҗәсендәге мәгълүматны вакытында һәм дөрес итеп җиткерү, без ике арадагы арадашчы, дисәк тә буладыр. Тел турындагы тапшырулар, әдәби-музыкаль тапшырулар гомер-гомергә югары зәвык тәрбияләүгә юнәлтелгән булды. Безнең сайтка кереп, тапшыруларны тыңларга мөмкин. 90 еллык юбилей алдыннан элеккеге, сирәк, кызыклы язмаларны тәкъдим итәбез. Фондтагы уникаль язмаларны... Мәсәлән, моннан 30 ел элек эфирга чыга башлаган «Пар канатлар» тапшыруын. Озак еллар дәвамында аны Рәзин Нуруллин алып бара. Бервакыт аңардан: «Татарстанда син әңгәмә кормаган берәр һөнәр вәкиле калдымы икән?» – дип сорыйлар. «Кызганыч, әмма калмаган икән шул», – ди Рәзин.

Идел Кыямов, «Татарстан» радиосы алып баручысы:

– «Корстон»дагы бер мәдәни чарада Тукай шигырен укыдым, аны радионың директоры ишетеп алган. Берничә айдан әдәби-музыкаль бүлек редакторы Нәсим Акмал шалтыратып, мине радиога эшкә чакырды. Бу 2014 ел иде. Шуннан бирле радио белән араны өзгән юк. Армияне исәпләмәсәң, билгеле, әмма мин хәтта анда булганда да, радиога хатлар яза идем.

Раил Садретдинов, «Татарстан» радиосы алып баручысы:

– Башка авылга йөреп укыганлыктан, йокыдан иртә торыла иде. Ә «Татарстан» радиосы иртәнге алтыда эшли башлый. Башта Россия гимны яңгырый, аннан – Татарстанныкы... ә аннан радио үзе дә телгә килә: «Татарстан Республикасы башкаласы Казан сөйли!» Күзләр үзеннән-үзе ачыла, тәрәзә аркылы офыкта күренгән кояшка карап елмаясың...

Радио белән тагын да якыннанрак танышу мәктәптә укыган чакта экология буенча республика конкурсына килгәч булды. «Көмеш кыңгырау» тапшыруы өчен интервью биргән идем Дания апага. Университетта укыганда да чыгыш ясадым... Соңрак, телевидениедә эшләгәндә, һаман барып чыга алмый идем. Әмма күңелне барыбер «Татарстан» радиосы» дигән уй кымтырыклап торды... Кемдер аны искелек калдыгы, яшьләр өчен кызыксыз мохит, дип санар, әмма балачактан шул тавышлар, кешеләрне тыңлап үскәнгә, минем күңелгә бик якын ул.

Тәвәккәлләп, 2015 елның декабрь башларында радиога практика үтәргә килдем. Беренче тапшыруым 14 көн дигәндә әзер булды һәм ул бик җылы кабул ителде. 2016 елның язы тормышыма зур үзгәрешләр алып килде, миңа биредә эш тәкъдим иттеләр. Үз эшемнән чын ләззәт алып эшлим. Юкка гына Конфуций: «Яраткан эшеңне сайла һәм сиңа бер көн дә эшләргә туры килмәячәк» димәгәндер.

PRESSA.RU

АЛАБУГА:
КАМИЛЛЕККӘ БИШ АДЫМ

Алабуга – Россиядәге «Төзекләндерүгә 5 адым» милли программасында катнашу хокукын алган 319 моношәһәрнең берсе. Программаның максаты – кыска вакыт эчендә биш җәмәгать урынын үзгәртү. Бу шәһәр халкының тормышын уңайлырак итү, шуның белән беррәттән туристларга да борынгы яңа Алабуганы ачу өчен кирәк.

Автор:
Алсу Троицкая

Шәһәр тормышының уңайлылыгы кибетләр, эш үзәкләре күп булу яки төрле хезмәтләрнең тоткарлыксыз эшләве белән генә билгеләнми. Әгәр шәһәрдә рәхәтләнеп йөрерлек, дуслар белән аралашырлык урыннар юк икән, ул төссез һәм уңайсызга әйләнә. Алабуга беркайчан да андый булмаган, аның үзенең кабатланмас тарихы һәм архитектур кыяфәте бар. Хәзер исә шәһәрдә үзенә җәлеп итәрлек урыннар тагын да артачак. Кимендә бишкә. Әйдәгез, бераз хыялланып алыйк һәм «Төзекләндерүгә 5 адым» проекты инде тормышка ашырылган дип күз алдына китерик.

«ГУЛЯЙ-ПАРККА», ЧИШМӘ ЯНЫНА

Таныш булыгыз, Алабугадагы «Гуляй-парк» бу. Гаҗәеп гүзәл яшел утрау Чернобыль һәлакәте ликвидаторларына багышланган мемориаль зонадан башланып, Пионерлар паркы янында бетә. Биредә соңгы тапкыр ике ел элек булучылар, бу бит Иске мәйдан, дип аптырый. Дөрес, биредә чыннан да бик моңсу, берән-сәрән сулган үсемлек кенә үсеп утырган ташландык урын иде шул бу. Хәзер исә төссез мәйданның эзе дә калмаган – «Гуляй-парк» аны да, аның әйләнә-тирәсен дә йотып, унбер гектарга җәелгән!

Эш аның зурлыгында гына да түгел. Биредә шулкадәр шау-шулы һәм күңелле ки, Марыля Родовичка яки Валерий Леонтьевка (кемгә кайсы күбрәк ошый бит) кушылып, үзеңнең дә борын эченнән генә «Этой ярмарки краски...» дип көйли башлавыңны сизми дә каласың. Яки, киресенчә, тавыштан качып, агачлар күләгәсенә кереп китә аласың. Амфитеатрда фонтанга карап хозурланып утырырга мөмкин. Туйдыргач, велосипед аласың да, йөреп киләсең. Кышын тагын да күңеллерәк – карлы таудан чанада шу, яки җәяү йөр, чаңгы шусаң да була. «Гуляй-паркның» күрке исә – чишмә, аның янына махсус маршрут буенча төшәргә мөмкин. Җәяүләп яки велосипедта, үзеңә ничек күбрәк ошый. Чишмә янынннан Алабуга шәһәрлегенә искиткеч манзара ачыла.

Без паркта бик озак йөрдек, һәм йөргән саен яшеллеккә чумган яңадан-яңа гүзәл почмаклар ачыла барды.

Фото: Александр Ефремов

Бүген «Гуляй-парк» урынында – буш мәйдан.

НЕЧАЕВ БАКЧАСЫНДА «ЙОКЫ СӘГАТЕ»

Һәр шәһәрдә көн саен кешеләрнең зур агымнары кисешә торган урыннар бар. Алабугада бу – яңа 4 нче микрорайон. Хәзер исә бу «кырмыска оясында» да вакыт агышы акрынайган тыныч урын бар. Сабыйлары мыш-мыш йоклап яткан арбаларын төртеп йөргән яшь әниләргә карап торганда, бу бигрәк тә нык сизелә. Хирург Леонид Нечаев исеме белән аталган скверда балалар да, өлкәннәр дә рәхәтләнеп ял итә алсын өчен кирәкле бөтен нәрсә бар – велосипед юллары, балалар һәм спорт мәйданчыклары, уңайлы эскәмияләр, яшеллек һәм чәчәкләр. Яңа төзелгән шау-шулы йортлар арасына кысан хрущёвкадагы швед стенкасы кебек килеп кысылган бу скверны район халкы тиз арада үз итте. Ул аларның очрашу һәм аралашу урынына әйләнде. Алабуга хәтта яңа шәһәрдә дә сөйкемле һәм күркәм.





ЧИРКӘҮ МӘЙДАНЫ: ИСКЕ ҺӘМ ЯҢА

Алабугада яңа белән иске янәшәлеге бик табигый килеп чыга. Моңа иң яхшы мисал – Спас чиркәве янындагы Собор мәйданын тәртипкә китерү. Биредә сквер, амфитеатр һәм уңайлы автопарковка пәйда булган. Яңа түшәлгән таш юлдан һәм сквердагы агач сукмаклардан үткәндә, агачлар күләгәсендәге нәфис эскәмияләргә утырып, чиркәү архитектурасы белән хозурланганда, унтугызынчы гасыр сурәтләрен күзаллау бер дә кыен түгел – әнә, Спас ярминкәсе ничек



гөрли! Хәзер ул «бер кат астарак» урнашкан Шишкин буаларына күчте. Һәм бүген без анда ниләр булганны Собор мәйданыннан гына күзәтеп тора алабыз.

Спас чиркәвенең нәкъ каршында – совет власте өчен көрәшүчеләрнең каберлеге. Бу да Алабугадагы саклана торган күпсанлы мирас объектларының берсе.

Чиркәү артында исә – Александр Невский кәшәнәсе, аны җирле экскурсия үткәрүчеләр «Алабуганың архитектура энҗесе» дип йөртә. Ул гаҗәеп төзек һәм гүзәл!

КАЙГЫРТУНЫ ҺӘРКЕМ, ҺӘРНӘРСӘ ЯРАТА

Хәтер мәйданын, Иван Шишкин һәйкәлен төзекләндерү, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгындагы Күргәзмәләр залына ремонт ясау... Күргәнебезчә, әлеге проектлар гигант зурлыкта түгел, алар Алабуга үлчәмнәренә туры килә. Әмма кайгыртуга, карап тотуга һәркем, һәрнәрсә мохтаҗ, хәтта мәйданнар белән күргәзмә заллары да. Тегесе дә, бусы да, өченчесе дә халык күп йөри торган урын булганга, әледән-әле биредә дә нәрсәнедер торгызырга, тәртипкә китерергә, яхшыртырга кирәк. Алабугалар һәм туристлар хәзер Хәтер мәйданы буйлап яңадан түшәлгән таш юллардан йөри. Һәм, берике минутка гына булса да туктап калып, Шишкин буаларының һәм Тойма елгасының биредән ачыла торган манзарасы белән хозурлана. Бер кулына кылкаләм, икенче кулына картина рамы тотып биредә басып торучы Иван Иванович үзе дә шул манзарага соклана кебек.

Табигать гүзәллекләре белән хозурланып туйгач, җәяү китәргә һәм сәүдәгәр Алексей Николаевның элеккеге кибетендә урнашкан Күргәзмә залына кереп, музей атмосферасына чумарга була. Ремонт шулкадәр сак ясалган ки, әлеге бинаның тарихи кыйммәтен һәм үзенчәлеген аз гына да бозмый. Менә шуның өчен без барыбыз да Алабуганы яратабыз да шул! Кәефне бер генә нәрсә төшерә – биредән китәргә кирәк бит. Ә китәсе килми...

2013 елда «Стрелка» Медиа, архитектура һәм дизайн институты шәһәрләрдә уңайлы мохит тудыруга комплекслы якын килү концепциясен эшләгән. «Күнеккәнне төзекләндерүгә биш адым» дип аталган әлеге концепциянең төп идеясе – шәһәрдәге биш җәмәгать зонасын үзгәртү. Соңрак бу концепция моношәһәрләрдәге җәмәгать мохитен төзекләндерү милли программасының нигезе итеп алынган.

БЕЛЕШМӘ

«Күнеккәнне төзекләндерүгә биш адым» проектларының барысы да РФ дәге 319 монопрофильле муниципаль берәмлекләрнең һәркайсында 2018 елның мартына кадәр башкарылырга тиеш.

Зөлфия Сөнгатуллина,
Алабуга муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары:

– Шәһәребезне яхшы якка үзгәртү, аны төзекләндерүдә халык үзе дә катнашса, уңышлырак бара. Болай күбрәк нәрсәгә ирешергә мөмкин. Бөтен нәрсә эзлекле һәм ачык эшләнелсә, нәтиҗә дә шәп була. Программаның биш юнәлеше кысасында җирле, республика һәм федераль бюджет акчаларына гамәлгә кертелгән чаралар, бөтенесе бергә дә яки аерым-аерым да, шәһәр халкының тормыш сыйфатын сизелерлек яхшырта һәм, әлбәттә инде, Алабуганың инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыра.

ЛЕНИНОГОРСК БАШЛЫГЫ КАРТА БЕЛӘН СЫЙЛЫЙ

«Татарстан» редакциясенең күчмә кухнясы Лениногорск төбәгендә аш-су әзерләү буенча осталык дәресендә катнашты. Безгә иң оста пешерә торган ашамлыгы – ат картасын район башлыгы Рәгать Хөсәенов үзе әзерләде.

КИРӘК БУЛАЧАК:

- 1 данә ат картасы;
- 3-4 эре суган;
- 1 данә лимон;
- 1 данә кишер;
- тоз, борыч, тәмләткечләр – тәмгә карап;
- 2–3 аш кашыгы үсемлек мае.

Фото: Алсу Дәүләтшина

ТАРИХИ АШАМЛЫК

– Бу ризыкны тарихи дип тә атарга мөмкин, чөнки ул балачагымнан, үткәннән килә. Карта – атның ашказаны ул, аны башта озак кына юарга, аннары озын-озак пешерергә, соңыннан суган белән табада кыздырырга кирәк. Аннан да тәмлерәк нәрсә ашаганым юк! Элекке заманнарда татарлар кышка ат ите әзерли торган булганнар. Аның һичнәрсәсен әрәм итмиләр, хәтта картасын да ташламыйлар. Шуңа күрә бу рецепт яңалык түгел, аны әле күчмә халыклар да кулланган, чөнки ат ите юлда йөргәндә яхшы саклана. Күчмә халыклардан үрнәк алып, яшь чагында мин дә, командировкага киткәндә, үзем белән һәрчак каклаган ат ите ала идем. Ә хәзер бөтен туганнарым, дусларым, танышларым, карта ашарга дип, миңа бик теләп кунакка килә. Аны үзем генә әзерлим. Гомумән, пешеренергә яратам, тик, кызганычка, моңа вакыт кына җитеп бетми. Эш. Район. Кешеләр. Мин үз кешеләрем турында сәгатьләр буе сөйли алам.

Автор:
Татьяна Вафина

PRESSA.RU

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘР

– Алар Ленигорскида үзенә бер төрлеме?

– Алар үзенчәлекле генә түгел, һәрберсе үзебезнеке дә әле. Күпләрен мин гомер буе беләм. Ничек үскәннәрен, ничек яшәгәннәрен һәм эшләгәннәрен белеп торам. Мин бит үзем дә монда тудым, монда кирәгем дә чыкты, шуңа күрә миңа барысы да якын һәм аңлаешлы. Ата-баба нигезе дә, гаиләм дә, яраткан эшем дә булган туган җир өчен хәл-көчемнән килгәнне эшлисем килә.

Рәгать Галиәгъзам улы ялтыратып юылган картаны кәстрүлгә сала, һәм менә безнең иркенләп сөйләшер өчен өч сәгать вакытыбыз бар (ул арада кәстрүлдәге суны берничә тапкыр алыштырырга гына туры киләчәк). Шул вакытта шашлык та әзерлибез – шундый галиҗәнап табигать кочагында аннан башка буламы соң! Бәрәңгесен дә кыздырабыз – ансыз тамак туя димени!

– Шәһәрдә никадәр әби-бабайның ял итеп йөргәнен, мөгаен, күргәнсездер. Үзебезнекеләр дә, читтән килгәннәр дә күп. Монда туып-үсеп, соңыннан читкә чыгып китеп, хәзер менә кире кайтучылар да шактый.

– Пенсионерлар каласымы?

– Пенсионерларныкы да. Безне пенсионерлар шәһәре дип атаганда, сөенегез генә, дим. Кешенең калган гомерен синең районыңда уздырырга теләве бик кыйммәт нәрсә. Бу бәяләмәнең, өстәвенә, уңай бәяләмәнең бер күрсәткече. Мин моны бер казаныш дип саныйм, ә инде чит кеше гомер итәр өчен районыбызны сайлаган икән, димәк, аны монда һәрнәрсә канәгатьләндерә, димәк, аңа кемдер монда тормышның уңышлы һәм яхшы икәнлеге турында сөйләгән. Ләкин бүген, кызганычка, үлүчеләр саны яңа туган сабыйлар саныннан күбрәк. Бала табу азайды. Хәзер әти-әни булырга тиешле буын – 90 нчы еллар вәкиле, ә ул чакта, хәтерлисездер, бала табу өчен тотрыклы вакытлар түгел иде. 90 нчы еллардан ата-ана булырдай буын азрак килде безгә...

БУ МИНЕМ ВАТАНЫМ!

– Безнең фотоаппарат Лениногорск урамнарында «электәргә» өлгергән бихисап бала коляскаларыннан чыгып фикер йөрткәндә, ни дисәк тә, сабыйлар актив туып-үсеп тора...

– Алай булганда яхшы. Шәһәребезгә, авылларга яшьләр дә килә. Без йортлар салабыз, сату өчен дә торак төзелеп тора, аларны читтән килгәннәр дә, туган ягына кире әйләнеп кайтучылар да сатып ала бит. Хәзер халык туган яктан да яхшырак урын юк икәнен аңлый башлады. Тамырлар, кан тарта.

– Лениногорскида фатирлар кыйммәтме?

– Казан һәм башка шәһәрләр белән чагыштырганда арзанрак. Ләкин Лениногорскига ниндидер уңышлы, тыныч тормыш кына түгел, ә монда яшәгәндә яки чыгышың шушыннан булганда, үз районыңа, үз шәһәреңә карата барыбер ниндидер бер тарихи якынлык тоюың да тартып китерәдер дип саныйм. Туган-үскән җирләр тормышыңны җанландыра, башкачарак фикер йөртәсең, уй-ниятләрең дә колачлырак. Мин, мәсәлән, монда тудым, һәм шәһәремнең алдынгы булуы мине турыдан-туры кызыксындыра да, районым турында яхшы яктан искә алуларын телим; менә җитәкче булып фәлән ел утыруын утырды, тик шәһәр өчен бернәрсә дә эшләмәде, дип әйтерлек булмасын соңыннан. Ник дигәндә, балаларым, оныкларым бар. Алар бит монда яши, укыйлар, балалар бакчасына йөриләр. Мин туган ягым өчен һичнәрсә эшләмим икән, үскәч, алар моны аңлап алачак, минем өчен оят булачак. Балаларыбызның йөзенә кызыллык китермәслек итеп яшик һәм эшлик – чын ир-ат булган бөтен әтиләр дә әнә шулай уйлый. Бу исә алар каршында да, шәһәр каршында да, район каршында да билгеле бер җаваплылык таләп итә.

ГОРУРЛАНАМ ҺӘМ ШАТЛАНАМ

– Горурланырлык нәрсәләр бар, минемчә. Шәһәребез – Татарстанның лаеклы бер бизәге.

– Республикабызны Россиянең башка төбәкләре белән чагыштыру күптән урынсыз инде. Без шундый призма астында эшлибез ки, уңга-сулга бер адым да атларга ярамый. Ләкин икенче яктан, мин нәкъ менә Татарстанда яшәвем һәм эшләвем белән горурлана һәм шатлана алам. Беренчедән, монда президент программалары, федераль программалар эшли. Бу бит районга шундый зур ярдәм! Без ел саен авылларда, калада ниндидер объектлар төзибез, социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашырабыз – болар бит Президентыбызның, хөкүмәтебезнең ярдәме белән эшләнә. Һәм без һәрнәрсәнең яхшы якка үзгәрүен күрәбез дә. Менә кичә генә диярлек федераль каналдан бер тапшыру карадым. Анда болай дип сөйлиләр иде: «...Бөтен Россиягә фәлән миллиард акча бүлеп бирелгән, бер өлкәгә ФАПлар төзер өчен миллион ярым туры килә...» Шулчак уйлап куям: соң мин бит һәр ел саен, һәр авылда ФАПлар төзим. Ә республика буенча бу елына 45 миллионнан артык дигән сүз! Безгә никадәр ярдәм икәнен уйлап карагыз! Бу бик кыйммәт нәрсә.

БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА АВЫЛДАН ЧЫКТЫК

Ә мәктәпләр, балалар бакчаларын төзекләндерү, авылда клублар салу! Авыл яшәсен өчен, боларның барысын да эшләргә кирәк. Һәм алар яши дә. Авыл халкы терлекчелек белән шөгыльләнсен, бу тармакны үстерсен өчен, ветеринария пунктлары төзибез. Элекке кебек колхозлар юк ич инде. Авылда белгечләр җитешми икән, ветерина-

рия пунктларына берничә авылга хезмәт күрсәтеп, шәхси секторга булышлык итү мөмкинлеге тудырыла. Районда төрле катлау халкы яши. Һәркемнең дә шәһәргә күченеп китү мөмкинлеге юк икәнен аңларга кирәк, фәкать бу очракта ул кешеләр тулыканлы, мавыктыргыч тормыш белән яшәсен, югалып калмасын өчен, без аларны ничек эшкә җигү, мәшгульлеген тәэмин итү турында уйларга тиеш.

Мин үз яшем югарылыгыннан хәзерге яшь гаиләләрнең нинди леген, аларның безнең буыннан кайсы да булса бер өлкәдә никадәр сәләтле һәм кызыклырак икәнен күрәм. Авылда халык аракы сазлыгына чумган дип сөйлиләр. Юк, андый заманнар артта калды. Эчкән кеше эчә инде ул, ә яши һәм эшли белгәннәр эштән бушамый, андыйлар үз киләчәген авылда күрә, аны шәһәргә кызыктырып та китерә алмыйсың. Шәһәргә кирәк-ярак алыр өчен барып килергә була, тик аңа үз өендә тынычрак, уңайлырак һәм иркенрәк. Яки шәһәрдән гел әти-әниләре янына, туган нигезенә, үз тамырларына һәрдаим кайтып йөриячәк. Асылда, без бөтенебез дә авылдан чыктык. Бездә нефтьчеләр дә, төзүчеләр дә һәр ял көнендә, ничек тә булса ярдәм итәр, нигезне саклап тотар, төзекләндерер өчен, туган авылларына юл тота. Бу хәзер бигрәк тә күзгә ташлана, авыллар үзгәрә, җанлана. Без һәр авылда башлангыч мәктәпне, балалар бакчасын саклап калырга тырышабыз, бу да киләчәккә зур өметләр... Авылда коллектив хуҗалык юк икән, авыл хуҗалыгы тармагында эш итә торган бригадалар, участоклар, фермерлар бар. Аграр секторда мәсьәләне болай хәл итү дә – нормаль күренеш.

ШӘҺӘР

– Авыл турында сөйләшеп, шәһәрне бөтенләй онытып җибәрдек...

– Иң мөһиме, картабыз турында онытмаска, – дип елмая Рәгать әфәнде. Ул кәстрүлнең суын түгеп, яңаны агыза. Аңа бер баш суган, кишер, яртыга бүленгән лимон сала. – Болар исне бетерер өчен, – дип аңлатып үтә ул. – Башта үзенчәлекле ис була. Аның каравы, соңыннан... Хәер, үзегез күрерсез.

Без кайнап утырган кәстрүлне тагын бер сәгатькә тынычлыкта калдырабыз, һәм бу сәгатьне шәһәр турында гәп коруга багышлыйбыз.

– Кала бүген секторларга бүленгән: нефть, төзелеш, коммуналь хуҗалык, машина төзелеше, бизнес секторлары. Хәзер бездә кече төзелеш бизнесы үскән. Әмма шул ук вакытта шәһәрдә зур күләмле федераль программалар белән эш йөртә торган өч эре эшмәкәр бар, бу яктан миңа уңыш елмайды. Алар үзләренә яхшы, тотрыклы бюджет булдыра, хезмәтләре Владивостоктан Калининградка кадәр территорияне колачлый, якын һәм ерак чит илләрдә дә эшлиләр. Бу халыкны эш белән тәэмин итү дә, безнең бюджетка ярдәм дә дигән сүз. Бездәге эшсезлек дәрәҗәсе бүген 370 кеше дип исәпләнә. Бу 85000 кеше яши торган шәһәр һәм район өчен! Әлеге 370 кеше – физик сәбәпләр аркасында эшли алмый торган инвалидлар. Калганнарын – мин аларны кайчак сөрхәнтәйләр дип атыйм – без яңадан укытабыз, башка һөнәргә өйрәтеп, эшкә юллама бирәбез. Бездә хәзер 460тан артык вакансиягә эшче куллар таләп ителә. Түбәнрәк хезмәт хакына эшләргә теләмәгәннәргә авыррак, катлаулырак эш тәкъдим итә алабыз. Эшләргә телисең икән, күңелеңә яткан, үзеңне мавыктыра алган эшне һәрчак табып була. Тәкъдим ителгәне ошамый икән, эшне үзең эзлә, үз тамагыңны үзең туйдыр. Бүген иректе базар заманы, эшлә генә!

Сәнәгатьне үстерү өчен булсынмы, башка тармакларны үстерү өченме – бездә резервлар зур. Әйе, заманында шәһәр шау-гөр килеп торды, оборона, авиация, радиоприбор предприятиеләре бар иде... Без нефтьчеләрнең кем икәнен ишетмәдек тә. Мазутка, нефтькә батып беткән, аркасына кыр букчасы салган бер мескен дип күз алдына китерә идек нефтьчене. Дөрес, нефтьчеләр монда гомер буе булды, ләкин 80нче елларга кадәр бездә цехлар, заводлар гөрләп эшләде, анда хезмәт хакы да нефтьчеләрнекеннән зуррак иде, эшләре дә чистарак. Кешеләр за-

ЛЕНИНОГОРСК БАШЛЫГЫННАН БЕР КИҢӘШ:

Ат картасын пешергәндә чыга торган тәмсез истән тизрәк котылу өчен, кәстрүлгә урталай киселгән лимон салыгыз.

1. Пешерәбез!

2. Чыгарабыз!

3. Бүләбез!

4. Турыйбыз!

5. Кыздырабыз!

6. Өстибез!

7. Томалыйбыз!

8. Табынга бирәбез!

PRESSA.RU

водларда төнге сменаларга эшкә йөрде... 90нчы елларда болар барысы да ишелеп төшкәч, авыр вакытлар җитте, шәһәрне яңадан корып, аякка бастырырга кирәк иде. Нефть тармагы өстәмә эшче көчләр җыйды, киңәйделәр. Профессионаллар арасында табигый сайланыш барды, чөнки оборона сәнәгатеннән бик күп белгечләр килде, ә алар нефть тармагы өчен дә бик кирәк иде. Халык арасындагы миграция дә күзгә ташланырлык булды, оборона предприятиеләренең үзенчәлеге кайбер кешеләрне Казанда, башка шәһәрләрдә эш эзләргә мәҗбүр итте.

РЕЗЕРВЛАР БАР

...Болар барысы да демографиягә йогынты ясады, ләкин, Аллага шөкер, үткәндә калды, без моны җиңеп чыктык. Шәһәр үз йөзен саклап калды, нефть тармагы тотрыкланды. Мин районыбызда нефть тармагында булсынмы, төзелеш комплексындамы, машина төзелешендәме – резервларның зур потенциалы барлыгын күреп торам. Мондый потенциал булганда, һәркем үз районы белән мактана ала. Чөнки бу – иң мөһим резервлар, иң төп мөмкинлекләр. Бүген республикада гына түгел, ил күләмендә, хәтта чит илләрдә дә күп еллар дәвамында ихтыяҗ булырлык нәрсәләр эшләргә, шундый товарлар җитештерергә кирәк. Берничә адым алга китеп, ашыкмый-кабаланмый, киләчәккә йөз тотып фикер йөртү таләп ителә. Шундый мөмкинлекләр сайлап алу, шундый инвесторлар эзләү зарур: 20-30 түгел, ә 1000-1500-2000 кешене эш белән тәэмин итәрлек җитештерү предприятиеләрен оештырып җибәрерлек булсын. Чөнки бүген бөтен шартлар да бар: тимер юл, аэропорт моннан утыз километрда гына, автомобиль юлы салынган. Якында гына Самара, Оренбург өлкәләре, Башкортостан чиге, димәк, башка төбәкләргә ишек ачык. Һәм без шундый инвесторлар эзлибез дә.

Һәм бүген, «Стратегия-2030» программасына ярашлы рәвештә, без аграр юнәлештә алга барабыз, акрынлап максат бурычларыбызны машина төзелеше тармагында да тормышка ашырабыз. Терлекчелек комплексы төзибез, кошчылык фабрикасын киңәйтәбез, эшкәртү һәм машина төзелеше тармагын камилләштерәбез...

– Ә районда уртача хезмәт хакы нинди?

– Районда уртача хезмәт хакы 18000 сумнан 22000 сумга кадәр тәшкил итә, шәһәрдә исә – 31000 сум чамасы. Эшләгән кеше акча таба ала ул.

ТОРМЫШ КАЙДА ЯХШЫРАК?

– Ягъни Татарстан башкаласыннан ерак булу сездә һичничек чагылыш тапмый?

– Иң төп проблема – юллар. Менә шунда сиздерә. Без шәхси секторда эшне киңәйтә барабыз, әмма юлларга бәйле зар-шикаятьләр күп әле. Бер көндә барысын да эшләп булмый, юлларны карап тору, яңаларын салу өчен бүленгән сумма җитәрлек түгел. Аннары шунысы да бар: Казан да, Самара да бездән 300 км ераклыкта, Уфа бераз гына якынрак – без Бермуд өчпочмагындагы кебек, зур шәһәрләр арасында урнашканбыз. Барысы да безгә килә, барысы да безне карый. Без дә үз белгечләребезне җибәрәбез – карыйбыз, өйрәнәбез, тәҗрибә уртаклашабыз.

– Сез бит үзегез дә күрше төбәкләргә сәяхәт кыласыз: кайда яшәү яхшырак – Лениногорскидамы, әллә Самара өлкәсендәме икәнен, мөгаен, чагыштыра торгансыздыр?

– Әлбәттә, Лениногорскида, бу хакта сүз дә була алмый. Мин Самара өлкәсендәге район башлыклары белән дус, алар бездә күргән нәрсәләренә, эшләребезнең ничек баруына, нинди карарлар кабул итүебезгә шулкадәр көнләшә; бездәге җитәкчелекнең киләчәкне шулай кайгыртып эш итүенә шаккаталар. Безгә министр, хөкүмәт кешеләре яки тагын кемдер килми калган бер ай да юктыр. Без һәр ай күзгә-күз сөйләшәбез. Моннан тыш видеоконференцияләр гел булып тора. Фикер алышабыз, карарлар кабул итәбез, хисап тотабыз. Ә аларда югары җитәкчеләрнең районга килүе – бик сирәк хәл. Ә инде берәр программага эләксәләр, бу бер зур бәхет, чөнки аларда мондый мөмкинлекләр, мондый чыганаклар юк.

– Гадәттә, безгә Ульяновск өлкәсе ягыннан көнләшеп карыйлар дип әйтәләр иде, ә монда Башкортостан да, Самара да искә алынды...

– Ташландык авыллар барысында да тулып ята. Ләкин аларда нинди селкенү, үзгәртергә тырышу дигән нәрсә юк. Мин шәхсән алардан көнләшер җир күрмим. Менә бүген парклар, скверлар ясыйбыз, су саклау зоналарын рәткә китерәбез. Шәһәр буйлап йөреп килегез, элек ничек иде дә хәзер нинди икәнен үзегез күрерсез. Чокырны катыкурадан чистартырга дигән хыялым бар иде – 40 ел торды ул – һәм, менә сиңа, бер ел эчендә без бу чокырдан кешеләр өчен шундый шәп ял урыны ясап куйдык. Тагын да яхшырак итеп эшли алыр идек, акча җитеп бетмәде. Тик гомуми картина барыбер үзгәрде, халкыбыз рәхәтләнеп йөри. Үзем исә көнделдән бик канәгать түгел, чөнки теләгән югарылыкка

кадәр ирештерә алмадым, ләкин кешеләр хыялларым турында белми бит, алар өчен уңайлы, матур булуы үзе үк яхшы,әлбәттә.

ТУЛЫ БӘХЕТ ӨЧЕН

– Лениногорск районына ни җитми? Район башлыгының бәхет касәсе һичшиксез тулып ашсын өчен, менә шуны эшләргә иде дип йөргән хыялыгыз бармы?

– Мин нинди дә булса предприятиеләр резервы булдырырга теләр идем. Ул 1500-2000 кешелек булып, нефть тармагына көндәшлек итә алсын. Шул рәвешле җирле бюджетка өстәмә керем чыганагы да, халыкны эш белән тәэмин итү өчен запас урын да булсын ул. Чөнки без мондагы уку йортларында кластер ысул кулланып эш йөртәбез. Бездәге көллият бик күп тармаклы, ягъни аның белгечләрен теләсә кайсы предприятиедә файдаланырга мөмкин.

Икенчедән, мин территорияләребездә яңа төзелешләрне дәвам итәргә теләр идем. Бездә кеше кулы тимәгән урыннар күп әле. Яңадан торгызырга кирәк тарихи җирләр бар. Шәһәргә нигез салган беренче нефтьчеләрдән калган урман-парк, мәсәлән. Ул ташландык хәлдә иде. 2009 елда, мин хакимияткә килгәч, нефтьчеләр тырышлыгы белән аны бераз рәткә китерә алдым, аннары шәһәр бюджеты хисабына үзебез дә тырышлык куйдык... Әлеге парк хәзер эшли, ләкин анда әле узган шимбә көнне генә диярлек йөрештереп чыккач, бу эшкә тагын тотынырга кирәк диген фикергә килдем. Аны шундый күңел ачу урыны итеп төзекләндерергә мөмкин ки, монда башка шәһәрләрдән дә кешеләр киләчәк. Әйтик, күрше әлмәтлеләр. Аларда мондый урман-парк юк. Ул ясалма булдырылган түгел, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән хозурлык.

ЧИШМӘ СУЫ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

Кәстрүлдә пешеп яткан нәрсәбезгә өченче тапкыр су салгач, чишмә суы белән тәэмин итү турында да искә төшерәбез. Лениногорскида краннан чишмә суы ага дигән хәбәр дөрес микән?

– Чишмәләребез бик күп. Әйе, шәһәр тулысынча үз суы белән тәэмин ителә. Бу әле 2010 елгы корылык вакытында үзен сиздерде дә: кайбер каптажлар туктады, кайбер чишмәләрдә су югалды, җир асты суларының тәэминаты бозылды. Мин Чулманның күз алдында саегуын күреп тордым. Ә без өстәмә су чыганаклары таптык. Ул чакта безгә Фәрит Мөхәммәтшин килгән иде. Без аның белән басу-кырларны карап йөрибез, шул вакытта мин иң якын көннәрдә шәһәребез һәм мондагы предприятиеләр тырышлыгы белән яңа чыганаклар табарга, су запасларын тулыландырырга вәгъдә бирдем. Шулай булып чыкты да: без дистәгә якын каптаж өстәдек, тоташтырдык. Шул вакыттан бирле су резервы сакланып килә. Хәер, әле бүген дә кушылу мөмкин булган яңа чишмәләр бар, ләкин аларның суын шәһәргә китерү өчен зур акчалар кирәк, алары да берничә елны күздә тотып бүленергә тиеш... Җир астында шундый запаслар һәм чишмәләр булуына сөенәм.

НЕФТЬ БЕЛӘН АВАЗ САЛГАН

– Чишмәләр дөньяга китергән шәһәрме? Әллә шулай да нефтьме?

– Тегесе дә, монысы да. 1943 елда Шөгердәге беренче скважина фронтка нефть бирде. Нефть чыгару аркасында, шәһәргә нигез салына. Бу Татарстан кара алтынының «бишеге» булды. Безгә бөтен Советлар Союзыннан төзүчеләр килде, шәһәрләребезне төзеде. Бүген бездә кая карама скважиналар, торбалар, электр баганалары, ә без әле шушы территориядә – баганалар арасында – икмәк тә үстерергә мөмкинлек табабыз.

– Эшли аласызмы соң?

– Без һәрнәрсәне булдыра алабыз, теләк кенә булсын. Монда тракторлар һәм комбайннар шундый оста йөриләр. Машинистлар һәм механизаторлар югары класслы. Икмәккә дә юл бирәбез, нефтьчеләргә дә һичкайчан тоткарлык ясамыйбыз. Җир маен чыгаручылар өчен бөтен мөмкинлекләр каралган, беренче адымны алар ясый. Теләсә кайсы территориядә йөрү, казып карау – аларның өстен хокукы. Нефть нефть инде ул. Ләкин кишәрлекләрне һәм юлларны шундый итеп билгелибез – авыл хуҗалыгына зыянга булмасын. Һәрнәрсә ике як өчен дә уңайлы рәвештә, экологияне саклап эшләнергә тиеш.

ЯРАТКАН УРЫНЫМ

– Районда яраткан урыныгыз бармы? Бар күңелне биреп, кайда ял итә аласыз?

– Мин шәһәрне әйләнеп үтә торган юлга чыгам да ерак-еракка, басу-кырларга карап басып торам. Моңа иртән-иртүк торып барам, шуннан рәхәтлек алам. Ә көндез, күңелдә ниндидер авырлык тойганда, шәһәрдән район эченә таба ераккарак юл тотам, анда матур урыннар шулкадәр күп: кая гына туктасаң да – шунда хозурлык көтә. Мин монда сурәткә төшерерлек бихисап урын беләм, рәссамнар да ул хәтле картина язмагандыр. Армиядән кайтуга ук шушында эшли башладым бит. Райпода хезмәт куйган ун ел эчендә бөтен районны өйрәнеп бетердем диярлек. Ул вакытта әле юллар бөтен җирдә дә юк иде, асфальт турында әйтеп тә тормыйм, басу, урман юлларыннан йөрдек. Шуңа күрә тиңдәшсез матур урыннарны күп беләм дә.

КУЛИНАР ТӘНӘФЕС

«Татарстан» район башлыгының төп ризыгын татып карау эше белән мәшгуль булган (хәер, башка нәрсә белән мәшгуль була да алмый иде) озын һәм бик туклыклы тәнәфестән соң, баш ашчыга рәхмәтләребезне яудырабыз. Ник дигәндә, үзенең 96 еллык тарихында журнал һәм аның хезмәткәрләренең моннан да тәмлерәк ризык ашап караганы юк иде.

Делегациябезне озатканда, Рәгать Галиәгъзам улы «юл астына» нотык тотты. Шигъри нотык. Ул карта турындадыр дип уйласагыз, ялгышасыз, чөнки ул дусларга багышланган иде. Әнә шул дуслар белән бергә Лениногорск башлыгы районын тагын да матурлый, тагын да яхшырта, чөнки үз туган ягына карата ул башкача мөнәсәбәттә була да алмый.

– Сегодня я горд и счастлив,
Что в обнимку с друзьями стою,
Что после работы любимой
Я ужином их накормлю.
И вечер удался, и завтра
Пусть так же удастся день –
На ход ноги лишь добавлю:
Покорим мы любую ступень!

Фото: Ната Смирнова

Елдан-елга, гасырдан-гасырга кабатланып килә торган, күңел түрләренә үтеп, сеңеп калган мәктәп иншасының темасы бу… Бу темага тонналаган юллы дәфтәр битләре язып тутырылган, аларга кем генә йөрәккә якын җәйге истәлекләрен бушатмаган: әниләр дә, әбиләр дә, әбиләрнең әниләре дә, бүгенге укучыларның әтиләре дә, укытучылар үзләре да, кырыс мәктәп директорларына да кагылмый калмаган бу тема – җәй турында барысын да искә төшерү, һәм күңелле җәй маҗараларын дәфтәр юлларына җөмләләр һәм абзацлар итеп тигезләп тезү.

Быелгы укучылар уку елы башында ук бу эшне уңышлы башкарып чыктылар һәм электрон көндәлекләренә үз тормышларындагы тагын бер искиткеч җәй турындагы иншаларына тиешле билгеләрен алдылар да инде.

Ә кемнәрдән өйгә эш турында беркем дә сорамый, тик аларның сөйлисе сүзләре күп икән? «Татарстан» бирелгән темага «иншалары» белән журнал битләрендә уртаклашырга тәкъдим итә. Чөнки мәктәп укучылары булмаганнарның да җәйге еллары бер эшсез пляжда яту гына түгел, кайчакта ул бик мәгънәле сәяхәт була бит – эксклюзив һәм искиткеч, нәкъ менә балачактагы кебек.

Мин җәйне ничек үткәрдем

СОҢГЫ ШАМАННАРНЫ ЭЗЛӘП…
44 бит

СВИЯЖСК БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР
48 бит

PRESSA.RU

Мин җәйне ничек үткәрдем

СОҢГЫ ШАМАННАРНЫ **ЭЗЛӘП...**

Казанның билгеле астрологы Лариса Усманова – социология фәннәре докторы, ТР ФАнең тарих институты хезмәткәре – бик күп илләрне йөреп чыккан. Әмма иң гаҗәеп тәэсирләрне быелгы җәйдә Россиядә кичергән. Аның «Соңгы шаманнарны эзләгәндә» дигән соңгы экспедициясе онлайн режимында безнең protatarstan.ru сайтында алып барылды. Бүген Лариса «Татарстан»да кунакта һәм без аның Алтай буенча сәяхәтенең үзебезгә мәгълүм булмаган тәфсилле бәянен исебез китеп тыңлыйбыз.

Автор:
Алсу Дәүләтшина

– Лариса Рафаэловна, ял итү урынын сез ничек сайлыйсыз?

– Мин сайламыйм, мин үземнең тормыш юлыннан барам, үз алдыма ниндидер бурычлар куям, сораулар бирәм, һәм миңа тормыш бу сорауга җавапны фәлән-фәлән урында табарсың, дип белдерә... Мәсәлән, Алтайда. Юнәлеш күрсәтелә. Шулай итеп, мине әлеге экспедициягә чакырдылар.

– Шаманнардан сез нинди сорауларыгызга җаваплар таптыгыз?

– Миңа шаманнарның рухлар белән ничек аралашуын күрү кызыклы иде. Чөнки шаман – кешеләр һәм рухлар арасындагы арадашчы зат. Христиан яки ислам динендәге кешеләр Аллаһ белән имам яисә дин әһеле аша гына түгел, ә турыдан-туры да аралаша, ә монда – юк. Күп этнографларның эшләренә караганда, шаманны рухлар үзләре сайлаганы аңлашыла.

– Шунысы аңлашылып җитми, ни өчен кешегә, янәшәсендә генә Аллаһ белән турыдан-туры аралашырга мөмкинлек биргән христиан, ислам диннәре була торып, шаманлык кирәк? Ни өчен, ерак юллар үтеп, мәҗүсиләр янына барырга?

– Кызык бит! Шаманнар күзгә күренми торган рухлар белән турыдан-туры аралаша, теләкләрне тапшыра, җавапларны җиткерә. Безнең җәмгыятьтә мондый сәләткә кемнәр ия? Экстрасенслар, йә булмаса – күрәзәчеләр. Тик мин аларга ышанмыйм. Ә шаманнар гап-гади җир кешеләре, һәм алар кешеләргә рухлар дөньясы белән аралашырга булыша. Һәм миңа аларның моңа ничек килүләрен белү кызык иде. Аларның чыннан да шундый сәләткә ияме, түгелме икәнен тикшерү. Татар тотып карамый ышанмый, дигән кебек, безгә бит барысына да үзебезгә, инанырга кирәк...

– Бу сәләтне үзегезгә дә күчереп алырга теләмәдегезме?

– Бу мөмкин түгел. Теләсә кем шаман була алмый. Аны рухлар сайлап ала. Идел ярларыннан килгән таныш түгел татар хатынын шаманлыкка сайларга телəрләр идеме икән алар, ай-һай. Син бары тик шаманның контактка керүен генә карап тора аласың. Әгәр син ритуалда катнашасың икән, аның ничек рух белән аралашуын күрергә була. Трансперсональ психология белән шөгыльләнүче кеше буларак, мин аның ул чакта нинди ысуллар куллануын күрәм. Мәсәлән, бубен – көрәш һәм хезмәт инструменты. Безгә ул нибары бубенга тукмак белән төйгән кебек кенә тоела. Ә юк! Ул аларны чакыра, ә аннары куып җибәрә – монысы да бик мөһим. Ягъни, бубен – көрәш өчен кылыч куллану кебек, мәсәлән, явыз рухларга каршы. Иң кызыгы – без дә

Фото: Лариса Усманова, Елена Васта

PRESSA.RU

Мин җәйне ничек үткәрдем

мавыгып китәбез, шул атмосферага чумабыз. Тауларда бу аеруча яхшы сизелә, чөнки анда җир актив һәм тау рухлары үзләрен ачык чагылдыралар.

Аннары, шаманнар кызык сүзләр сөйли: балалар кичке 7 дән 9 га кадәр урамда йөрмәскә тиеш, чөнки бу вакытта адашкан җаннар да йөри һәм алар баланы алып китәргә мөмкин. Тауларда рухлар гына уза торган сукмаклар бар, һәм кешеләр ул сукмаклардан йөрмәскә тиеш, чөнки син шул рәвешчә чик сызыгыннан аргы дөньяга эләгергә мөмкинсең. Һәм сез хәтта кире кайтсагыз да, ахыр чиктә барыбер анда китәргә теләячәксез...

– Бу безгә балачагыбызда лагерьда бу мәсьәләдә тәҗрибәлерәк булган пионерлар йокы алдыннан сөйләгән куркыткычларга охшаган... Шунда ук башыбызга сорау килә: ә бездә андый рухлар юкмыни? Азнакай районында, мәсәлән, Чатыр-тауда?

– Бик тә ихтимал, мин, бездә мәҗүсилек мәдәнияте булгач, борынгы заманнарда төркиләрдә дә шаманлык булгандыр, дип уйлыйм. Аннары гына дин килгән бит, ислам. Моңа кадәр, әлбәттә, ниндидер мәҗүсилек булгандыр...

– Аңлашылды. Шаманнар белән очрашудан аеруча истә калган тәэсирләрегез?

– Әйтик, беренчедән, алар тормышта гадәти кешеләр. Эшкә йөриләр. Гаиләләре, балалары бар. Гадәти тормыш алып баралар. Әмма билгеле бер социаль функцияне башкаралар – рухлар һәм җәмгыять арасында арадашчы булып торалар. Анда бу нормаль кабул ителә, пионер лагерьларындагы куркыткычлар кебек түгел. Мәсәлән, бер шаман Улаган районының мәшгульлек хезмәте җитәкчесе – Тойдонов Леонид Ильич. Моны бездә күз алдына да китереп булмый. Без шаманнарны искелек калдыгы буларак кабул итәбез, хорафатларга ышану белән тиңләштерәбез. Ә анда ул тормыш системасына аерылгысыз бәйләнгән. Хәтта хакимияттәге кешеләр дә бу нәрсәләргә ышана. Һәм халык үз тормышларын шаманнардан башка күз алдына китерә алмый. Мондый әйберләр белән анда шаярмыйлар. Чөнки ахыры хәерле булмаска мөмкин. Бу елның март аенда шундый хәл булган – Телец күленә вертолёт килеп төшкән. Вертолётта биш кеше һәлак булган. Алар арасында Алтай республикасының ниндидер бүлекчәсенең элекке җитәкчеләреннән берәү дә булган. Вазыйфасыннан киткәннән соң, күзәтү астында тотылган ул... Эшкуарлык белән шөгыльләнә башлаган, алтайлылар әйтүенчә, Телец күлен үзенеке итәргә, анда курорт зонасы төзергә җыенган. Һәм күлне үз милке итеп үзләштергән. Әмма, күрәсез, күл монда үзен-үзе яклап калган.

– Аяусыз хөкем. Әмма гадел.

– Мондый вакыйгалар җитәрлек. Мәскәү кешеләре әледән-әле нәрсәгәдер ия булырга, нидер төзергә, табыш алу өчен акчаларын кая да булса кертергә тырышалар. Алтайлыларга бу ошамый, әмма алар тыныч – Алтай үз-үзен яклаячак, диләр. Монда шундый җир, бирегә килеп, аны табыш алу максатында кулланырга ярамый, ул сиңа барыбер андый мөмкинлек бирмәячәк. Әгәр син аны хөрмәт итмисең икән, кирәгеңне алачаксың.

– Ә туристлар моның өчен кирәген алмыймы соң? Алар үз артларыннан чүпләрен җыймаска да, үзләрен бик үк әдәпле тотмаска да мөмкин бит? Рухлар аларга ничек карый?

– Юк, без бернинди тәртипсезлекләргә юлыкмадык. Бәлки, хәзер туристлар үзгәргәндер. Һәрхәлдә, без бу яктан сак булырга кирәклеге турында нәтиҗә ясадык. Рухларны ачуландырмаска.

Слава Челтуев исемле иң көчле шаман сөйләде безгә... Узган ел ул Америкага, Гавайларга, Җир Конгрессына барган – Алтай шаманнары вәкиле булып. Ә аны принцесса Укок белән бәйле мәгълүм вакыйга буенча чакырганнар. Ишеткәнегез бардыр?

– Нәрсәдер, кайдадыр, ничектер...

– Аңлашылды. Археологлар 90 нчы еллар ахырында бер курганны казыганнар һәм анда 25 яшьлек хатын-кыз мумиясен тапканнар. Киемнәренә карап, ул чакта яшәгән халыкның күренекле бер вәкиле икәнен ачыклаганнар. Аны принцесса Укок дип исемләгәннәр. Мумияне, генетик экспертиза ясау өчен, Новосибирскига алып киткәннәр, аннары Алтайда бик көчле җир тетрәү булган. Шуннан иген уңышлары кими башлаган, таулардан кар ишелгән һ.б... Алтайлылар мумияне кире кайтаруны таләп итәргә керешкән. Җитәкчелеккә мөрәҗәгать иткәннәр. Шулай итеп, мумияне кире кайтарганнар, Таулы Алтай башкаласы музеена куйганнар. Аның өчен цоколь этажында махсус төрбә билгеләгәннәр, күмү йоласын үткәргән кебек булган. Тантанада катнашырга барлык шаманнарны чакырганнар. Ягъни, йоланы үтәү карары дәүләт дәрәҗәсендә кабул ителгән.

– Ә ни өчен принцессаны кабат җирләмәгәннәр? Эш болайга киткәч, шул ук курганда, мәсәлән?

– Шаманнар, аны нинди йола буенча җирләгәннәрен белмибез, дигәннәр. Бәлки, дөрес булмаган йола белән үз халкыбызга, табигатебезгә зыян китерербез. Нинди хәлдә булса, шулай калдыру яхшырак – әнә шундый фикергә килгәннәр алар. Менә шундый гаҗәеп карашлар белән яши ул халык.

– Бу сәяхәттән ниди дә булса файда ала алдыгызмы?

– Мин бөтен шаманнар белән сөйләштем, үзем турында, эшләрем турында сораштым. Әлбәттә, минем бу шаманнарның ялган затлар түгелме, туристлар аша акча эшләмиләрме икәнлеген беләсем килде. Ә аннары бу юл белән акча эшләү куркыныч икәнлеген аңладым. Сүз уңаеннан, бер шаман Яр Чаллыда үзенең укучысы барлыгын, аның янына өйрәнергә килүен сөйләде. Мин, әлбәттә, аның ни дәрәҗәдә татар булуын белмим, бәлки ул ярымалтайлыдыр, чөнки синдә моңа тартылу булмаса, шаман укучысы була алмыйсың. Һәм шаман юлы белән бару куркыныч та, хәтта, рух белән аралашканда, һәлак булырга да мөмкинсең.

– Ул рухлар күпме соң?

– Шаманнар дөньяны өч өлешкә бүлә. Ягъни: түбәнге дөнья, кешеләр дөньясы һәм югары дөнья. Түбәнге дөнья – ул явыз рухлар, алар үлем белән бәйле, ә югары дөнья – алга таба хәрәкәт итү, үсеш, ярдәм. Шаман үзе – бу дөньялар арасындагы арадашчы. Кешеләр аның янына сәламәтлек, карьера, туганнары югалуга кагылышлы төрле сораулар белән килә, һәм шаман ярдәм итә. Вәзгыятьне яхшыртуга юнәлтелгән йолалар үткәрә... Аларны ничек атарга соң? Тылсымчылар дипме, шарлатаннар дипме? Әмма алар тылсымчылар да, шарлатаннар да түгел, алар җәмгыятебезнең бер өлешен тәшкил иткән һәм башкаларга булышучы гадәти кешеләр. Шаманнар, бер сүз белән әйткәндә.

– Бу «шаман җәе» сезне ниләргә өйрәтте?

– Беренчедән, без табигать белән үзебезне тыныч, тәртипле тотарга тиешбез, шау-шу белән аңа комачауламаска өйрәнсәк әйбәт. Без, Алтай табигатенең тынычлыгын бозып, артык тынгысызлык тудырган һәм ниндидер авылда, дуңгыз балаларының котларын очырып, алар белән фотога төшкәннән соң, ниндидер сәер һәм бик үк күңелле булмаган хәлләргә юлыга башладык: бер кызыбыз чак кына умыртка баганасын сындырмый калды, шәһәрдә-





ге банкомат карточканы чәйнәде, машина йөртүче безне кире алып кайтудан баш тартты, җитәкчебезнең кызы Мәскәүдә нәрсәдәндер агуланды... Безне ниндидер көч аннан читкә этәреп чыгарды. Югыйсә, без эчмәдек тә, чүпләмәдек тә инде. Бары тик, кем әйтмешли, табигатькә ябырылдык кына.

«Табигатькә сакчыл карарга кирәк, кешеләр хәзер бу сыйфатны югалттылар, – дип нәсихәт бирде безгә шаман Василий Иванович. – Сез урманга яки тауларга чыгасыз икән, тыныч булырга тиешсез: тыңларга, тирә-якка колак салырга... Табигатьне хөрмәт итәргә, аңа ышанырга кирәк».

Без моңа төшенүгә, күктә салават күпере күренде. Ул безне бөтен сәяхәтебез буенча озата барды. Бу яхшы билге иде.

Мин үзем бернинди начарлыкка да юлыкмадым, әмма башкалар мисалында Алтайның башта безне кабул итмәвенә, ә аннары инде кабул итүенә ышандым.

PRESSA.RU

СВИЯЖСК БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР



Татарстан Республикасы Президентының матбугат хезмәте җитәкчесе Свияжскида бер генә җәен үткәрмәгән. Нәтиҗәдә, Свияжск белән әңгәмәләр пәйда булган – иң матур фотосурәтләр, узган һәм бүгенге тормыш мизгелләрен чагылдыручы фикерләр тупланган аларда. Сез күргән-белгән бернинди юлкүрсәткечләрдә дә урын алмаган нәрсәләр. Аның каравы, «Свияжск: монологи» китабында таба алачаксыз боларны.

Елгалар кочагында
Безне өч елга уратып алган: Идел, Зөя һәм Чуртан (Щука). Бәхетебез утрауда иде безнең – беркемгә дә бәйле булмауда. Тагын әнидән кәнфит эләккәндә бәхетле идек.
Александр Попов

Аня (Лобашова) түти
Без бит уңайлы тормышка ияләшмәгән. Элек менә, иртүк торуга, тәрәзәгә капланасың – урамда ничек, һава торышын карыйсың. Чиләкне чыгарырга, утын ватарга, су китерергә кирәк. Менә ул өч эш бар иде. Ә хәзер торасың – эш юк, чәй эчәсең… Рәхәт, уңайлы.
Анна Лобашова

Рич атлы эт һәм Олимпия ишегалды
1980 елда күчендек, шуңа да Олимпия ишегалды дип йөртәләр. Тагын бер исеме – Тишек, коймадагы тишектән йөргәнгә. Менә утырабыз, көнбагыш чиртәбез, себереп алабыз, тагын утырабыз.
Вера Морозова

Мунча көне
Свияжскига килеп кенә керәсең – борының белән сизәсең: мин өйдә. Агач йортларның бүрәнәсе тараткан, мунча яккан, утын кискән ис. Әрем, кычыткан әчесе, төтен һәм, әлбәттә, тирес исе, ансыз булмый – бөтен кеше терлек асрый бит. Менә шундый җанга якын рух яши иде биредә.
Людмила Елисеева

Барлык Кайгыручылар Шатлыгы Изге ана соборы
Шайтан тавы. Күңеле керлеләр өчен фаҗигале урын. Әшәке уйлар белән килгән кешеләр биредә сәер вә могҗизаи төстә бәлагә таралар. Ә ниятләре пакъ булганнарның бәхетләре арта. Монда шундый нәрсә бар.
Ирина Аксёнова

PRESSA.RU

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Алтын Урда **НӘРСӘ** алып килгән

Җиләкле бистәсендә **НИК** җиләк үсми

Тинчуринның олпатлыгы **НИДӘ**

Марат Бәшәров **НИЧЕК** хыялын тормышка ашырган

Джанни Родари Казанда **НӘРСӘ** эзләгән

АЛТЫН УРДА ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ

XIII гасырның II яртысында монгол ханнары тарафыннан оештырылган Алтын Урда дәүләте тарихын начар өйрәнелгән дип әйтеп булмый. Әлбәттә, заманына карап әлеге тарихта төрле концепцияләр өстенлек иткән. Советлар чорында, мәсәлән, Алтын Урданы буйсындырылган халыкларның изгән варварлар дәүләте дип санасалар, хәзер, киресенчә, аны урта гасырның цивилизацияле дәүләтләре исәбенә кертеп, бераз идеаллаштыра да башладылар кебек. Чынбарлык исә алтын урталыкта булырга тиеш.

Алтын Урда ханын тәхеткә утырту тантанасы. «Шахнамә». 1330нчы еллар.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Алтын Урда ул монгол-татар гаскәрләре тарафыннан Урта Азия һәм Көнчыгыш Европа җирләрен, шул җирләрдә яшәгән халыкларны басып алганнан соң барлыкка килгән дәүләт. 1236 елның көзендә монгол баскыннары Идел Болгары дәүләтен дә җимереп ташлыйлар. Болгар цивилизациясе яшәүдән туктый, борынгы бабаларыбызның дәүләтчелеге юкка чыга.

«УГЛАННАР БЕРГӘ КУШЫЛА...»

Советлар чорында монгол-татарлар алып килгән фаҗигане күпертеп күрсәтәләр иде. Имеш, Болгарда да, рус кенәзлекләрендә дә дистәләрчә, хәтта йөзләрчә шәһәрләр яндырылып юкка чыгартылган, халкы кылыч аша үткәрелгән һ.б. Әйе, Рус дәүләтенең Көнбатыш Европа илләре белән чагыштырганда күпкә көчсезлеге, артталыгы сәбәпләрен аңлату өчен монгол яуларын сылтау итеп алырга кирәк иде. Хәзер Мәскәү тарихчылары үзләре үк мондый карашның дөреслеккә туры килмәвен таныдылар. Әмма ни генә димә, сугыш сугыш инде ул, кан коюсыз гына булмый: җимерәләр дә, үтерәләр дә. Шул чорда яшәгән елъязмачыларның хәбәрләренә генә күз төшерик: «Болгар җирендә угланнар (монгол ханы уллары) бергә кушыла; гаскәрләр шулхәтле күп була ки, җир гөрелдәп һәм ыңгырашып тора, дошман явы тудырган шау-шудан кыргый хайваннар һәм ерткыч кошлар катып кала. Башта монголлар штурм белән Олуг шәһәрне (Биләрне) алдылар. Бу шәһәр халкының күплеге, ныгытмаларының көчлелеге белән бөтен дөньяга билгеле була. Башкаларга гыйбрәт итеп, шәһәр халкының бер өлешен үтереп бетерделәр, икенче өлешен әсир иттеләр». Бу сүзләрне фарсы тарихчысы Җүәйни язып калдырган. Шуңа охшаш мәгълүматны рус елъязмачысы китерә: «Шул ук көзне көнчыгыш илләрдән Болгар җиренә алласыз татарлар (монголлар) килә һәм Олуг шәһәрне яулап ала, картлардан алып имчәк балаларына кадәр барысын да корал аша уздыра. Бик күп товарлар кулга төшерә, шәһәрне яндыра һәм бөтен җирне әсир итә».

Кече манара янындагы төрбә. Болгар шәһәре. Җүчи Олысы. XIV гасыр.

Фотолар автордан алынды

Бөек Ефәк юлындагы кәрван. 1375 ел.

Биләр шәһәрлегендә ул сугыш эзләре әлегә кадәр саклана. 1236 елны бик күп болгар шәһәрләре һәм авыллары талана, яндырыла һәм мәңгегә юкка чыга. Күренекле археолог Равил Фәхретдинов туплаган мәгълүматлардан күренгәнчә, монголларга кадәрге Идел Болгарындагы 100дән артык шәһәрнең бары тик 20се генә, 600ләп авылның 100 гә якыны гына Алтын Урда чорында яшәвен дәвам итә. Бу хәлне, теләсәң-теләмәсәң дә, монгол яуларының нәтиҗәсе, болгар тарихындагы олы фаҗига дип аңлатырга кирәк, минемчә.

ЯҢАРЫШ ҺӘМ КҮТӘРЕЛЕШ

Әмма тормыш туктап калмый бит ул, нинди генә канкоюлы сугышлар булмасын, халыкның бер өлеше исән кала һәм, бераз тынычлык урнашуга, торгызу эшләренә керешә. Тулысынча Алтын Урда дәүләте составына кушылган Болгар җирләрендә дә шулай була. Ике дистәгә якын шәһәр-крепость, йөздән артык яңа авыл үсеп чыга. Хәтта нигезенә кадәр җимертелгән Биләрнең халкы да, элеккеге башкаладан ике-өч чакрым гына төньяккарак китеп, Чирмешән елгасына якынрак бер урында яңа шәһәр торгыза башлый. Дөрес, бу шәһәрнең ныгытмалары булмый (монголлар рөхсәт итми), әмма территориясенең мәйданы ягыннан – 180 га чамасы – русларның иң эре дип йөртелгән Владимир, Суздаль, Мәскәү, Ростов ише шәһәрләреннән дә өстенрәк тора ул. Хәзерге Татарстан җирләрендә генә түгел, башка өлкәләрдә дә яңа шәһәр һәм авыллар калкып чыга (әмма ничек кенә булмасын аларның саны монголларгача чор белән чагыштырганда күпкә аз).

Алтын Урда чорында Болгар олысының алга китешен ачык күрсәтеп торучы атаклы тарихи-археологик истәлек, әлбәттә, барыбызга да мәгълүм булган Болгар шәһәрлеге. Аның гөрләп чәчәк атып утыру чоры нәкъ менә XIV гасырга туры килә. Башлыча шул гасырның беренче яртысында хәрабәләре генә булса да бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган Җәмигъ мәчете, Кара пулат (хөкем бинасы?), Ак пулат (җәмәгать мунчасы), Кече манара, таштан салынган төрбәләр һәм әлегә җир астында сакланып ятучы башка күпсанлы архитектура корылмалары төзелә. XIV йөзнең икенче яртысында, тиздән илне һәлакәткә китерәчәк хан тәхете өчен көрәш – «бөек чуалышлар» башланган чорда, Болгарның яңа ныгытмалары торгызыла. Монголларга кадәрге чор белән чагыштырганда Болгарның территориясе 10 тапкыр диярлек киңәйтелә – 380 гектарга җиткерелә. Алтын Урданың башка төбәкләре арасында Болгар олысының тагын бер өстенлеге була. Биредә халык элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгән, һәм ул хәзер дә Урда шәһәрләрен, беренче чиратта, әлбәттә, башкала булган Сарай халкын яхшы сыйфатлы ашлык белән тәэмин итеп торган.

Болгарның күзгә күренеп баюы күпләрне кызыктырган, әлбәттә. Аңа юлбасар рус ушкуйниклары да тынгы бирмәгән, вакыт-вакыт талап китә торган булганнар, Сарай хакимнәре алып барган сәясәткә каршы күтәрелгән әмир-ханзадәләр дә (мәсәлән, Булат-Тимер) Болгарны үзләренеке итәргә омтылган.

АЛТЫН УРДА ФЕНОМЕНЫ

Соңгы елларда тарихчы галимнәр Алтын Урданы (рәсми телдә – Җучи Олысы) урта гасырларның иң югары үскән, цивилизацияле дәүләтләре исемлегенә кертәләр, дигән идек. Бу чыннан да шулай. Алтын Урда феномены беренче карашка аңлашылып та җитми кебек. Ничек инде малчылыктан һәм сугыш эшеннән башканы белмәгән кыргый монголлар икътисады да, мәдәнияте дә шулкадәр алга киткән дәүләт төзи алганнар? Әйе, алар – күчмәннәр, башлыча терлек асрау белән шөгыльләнгәннәр. Әмма, тупас көчкә нигезләнгән булса да, XIII йөз башында ук үзләренең дәүләтләрен дә төзеп куйганнар ич. Дәүләтнең башкаласы итеп 1207 елда Каракорым шәһәренә нигез салганнар. Тиздән тагын берничә шәһәр барлыкка килгән. Тора-бара ул шәһәрләр һөнәрчелек үзәкләренә әверелеп киткән. Димәк, монголларга утрак тормыш та, күчмә терлекчелектән башка шәһәр һөнәрчелеге дә күптән таныш булган икән.

Яулап алган җирләрендә тарихка Алтын Урда, яки Җучи Олысы булып кереп калган мөстәкыйль дәүләт барлыкка килгәч (монгол империясеннән тулы бәйсезлекне ул Батый ханның оныгы Мәнгү Тимер хакимлек иткән чорда, ягъни 1266–1282 еллар гына ала), монгол ханнары үзләренең кул астындагы өлкәләрнең һәм анда яшәүче күпсанлы халыкларның тотрыклы үсеше өчен шартлар тудырырга омтылалар. Ничек итеп? Көчле дәүләт – бай дәүләт ул, ә байлыкны тудыручылар – гади халык: игенчеләр, терлекчеләр, һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр. Һәркемгә аңлаешлы шушы принциптан чыгып, монгол ханнары иң беренче чиратта бөтен илдә, шул исәптән, рус кенәзлекләрендә дә халык саны алу үткәрәләр һәм исемлеккә кергән һәр хуҗалыктан Сарай казнасына еллык керемнең уннан бер өлеше (дисәтинә) күләмендә салым – ясак

Туктамыш ханның Тархан ярлыгы. 1392 ел.

PRESSA.RU

Хатын-кыз баш киеме бизәге. Алтын.
Җучи Олысы. XIV гасыр башы.

Каеш бизәкләре. Алтын.
Җучи Олысы. XIV гасыр.

Чылбырга асылган кулон. Алтын.
Җучи Олысы. XIV гасыр.

түләүне таләп итәләр. Күп тә түгел, аз да түгел. Артыгын таләп итсәң, гади халык бөлергә мөмкин – бу куркыныч нәрсә. Баесыннар – салым да күбрәк керәчәк. (Исегезгә төшерегез: Татарстан Россия казнасына байлыгының күпме өлешен күчереп бара әле?). Тик шунысы бар: озак та үтми, салым җыюны монгол баскаклары кулыннан алып, кенәзләр кулына тапшыралар. Болар инде тунапмы-туный үз халкын, кирәк кадәресен хан казнасына озаталар, калганын – үзләре файдасына (Мәскәү кенәзе Иван Калита менә шулай баеган бит инде).

СӘҮДӘСЕЗ ДӨНЬЯ – ФАЙДАСЫЗ...

Байлыкның байтак өлешен, әлбәттә, һөнәрчелек тармаклары җитештергән продукция тәшкил итә. Һөнәрчелек дигәннән. Аның үсеш дәрәҗәсен күрсәтүче төп мәгълүмат, һичшиксез, археологик казу эшләре вакытында туплана. Алтын Урда шәһәрләре ярыйсы гына өйрәнелгән. Һөнәрчелек бистәләрен без монголларга кадәр яшәгән шәһәрләрне казыганда да табабыз. Артык зур булмаган чүлмәк яндыру, тимер кою мичләре – кирпечтән өеп ясалган горннар, һөнәрчеләрнең эш кораллары, ярымфабрикатлар... Ә менә Алтын Урда шәһәрләрендәге һөнәрчелекне нишләптер хәзерге заман термины белән сәнәгать дип, ә аларның остаханәләрен чын заводлар дип атыйсы килә. Әлеге «заводлар», мәсәлән, Сарай әл-Мәхрүсәдә (Әстерхан тирәсендәге Селитренное шәһәрлегендә) табылган чүлмәк ясау, кирпеч сугу һәм яндыру остаханәләре дистәләрчә гектар мәйданны биләп торган. Металлургия «заводларында» Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып чуен коя башлыйлар (дөрес, чуенны безнең ерак бабаларыбыз һуннар әле б.э.га кадәр II гасырда ук койганнар). Эре шәһәрләрдә зәркән әйберләре, пыяла савыт-саба, сугыш кораллары ясау осталары, күнчеләр яшәгән. Ләкин шуны искәртеп үтәргә кирәк: остаханәләрдә монголлар да, татарлар да түгел, бәлки Болгардан, Хәрәземнән, Кавказ якларыннан китерелгән тәҗрибәле һөнәрчеләр – сугыш әсирләре эшләгән.

Икътисадның хан казнасына иң күп керем бирүче өлкәсе – сәүдә. Бигрәк тә тышкы сәүдәгә нык игътибар бирелгән. Әле Токта хан заманында ук, 1311–1312 елларда, илдә акча рефомасы үткәрелә. Сарай дирһәме тотрыклы акча берәмлегенә әверелә. Ул Алтын Урдада гына түгел, күрше дәүләтләрдә дә әйләнештә йөри. Үзбәк хан (1312–1342) сәүдә үсешенә мөмкин кадәр күбрәк ирек тудырган тәртип урнаштыра. Йөзләрчә чакрымнарга сузылган сәүдә юллары төзекләндерелә, кәрван-сарайлар төзелә, юлбасарларның сәүдә кәрваннарына һөҗүм итү, талау ихтималы юк дәрәҗәсенә җиткерелә. Ә иң мөһиме – чит ил сәүдәгәрләре өчен таможня салымы бик аз күләмдә билгеләнә һәм сатылачак товар бөясенең 3–5 процентыннан артмый. Сәүдәгәрләр өчен махсус юлкүрсәткечләр, Codex Cumanicus тибындагы икетелле сүзлекләр чыгаралар. Тышкы сәүдә төп ике транспорт юлыннан алып барыла. Бөек ефәк юлы (коры җирдән) һәм Бөек Идел юлы буйлап Алтын Урда шәһәрләренә рус кенәзлекләреннән, Көнбатыш Европа, Балтыйк буе, Кытай, Һиндстан, Урта Азия, Кавказ һәм Якын Көнчыгыш илләреннән бай сәүдә кәрваннары агыла. Хан казнасына тупланган байлык шәһәрләр коруга, хан гаскәрен тотуга, сарай чиновникларын асрауга, мәдәниятны үстерүгә тотыла.

ШӘҺӘРЛӘР ҺӘМ БАЗАРЛАР МӘМЛӘКӘТЕ

Бүгенге көндә Алтын Урданың археологик картасына 100дән артык шәһәр билгеләп куелган. Сарай әл-Мәхрүсә (Сарай-Бату), Сарай әл-Җәдид (Сарай-Бәркә), Кырым (Солхат), Хаҗитархан, Маҗар, Үкәк аларның иң зурларыннан саналган.

Сарай әл-Мәхрүсәгә Батый хан нигез сала. Ул Алтын Урданың икенче (Болгардан соң) башкаласы була. Хәрабәләре Әстерхан тирәсендә, бүгенге көндә дә Казан археологлары тарафыннан тикшерелә. Шәһәр үзенең матурлыгы һәм зурлыгы белән замандашларын таң калдырган. Ибн Баттута, шул заман сәяхәтчесе, болай дип язган: «Сарай шәһәре – аеруча зур, тигез җирдә урнашкан, халкы тулып торган, матур-матур базарлы һәм киң урамлы гүзәл шәһәр. Бервакыт шәһәрнең бер олуг кешесе

Коръән савыты. Көмеш.
Җучи Олысы. XIV гасыр.

Мәдрәсә. Солхат.
XIV гасыр.

Җаникә ханым төрбәсе.
Кырк-Ер. XV гасыр.



Түрәбәк ханым төрбәсе.
Күнә-Үргәнеч. XIV гасыр.

белән без, атка атланып, шәһәрне әйләнеп чыгарга ниятләдек. Без шәһәрнең бер читендә яши идек, аннан иртән чыгып киттек, ә икенче читенә төштән соң гына барып җиттек... Бу шәһәр урамнары тоташ йортлардан гына тора. Биредә җәмигъ гыйбәдәте өчен 13 мәчет бар. Аннан кала башка мәчетләр дә гадәттән тыш күп». Сарайда 75, ә кайбер исәпләүләр буенча 100 меңгә якын кеше яшәгән – бу урта гасырлар өчен искитәрлек зур сан.

Археологик материаллар күрсәткәнчә, башка шәһәрләрдән Сарай үзенең төзеклеге, уңайлыклары белән аерылып торган. Монда керамик торбалардан сууткәргечләр һәм канализация системалары эшләгән. Шәһәр кешеләре эчәр өчен суны арыклар белән тоташтырылган чыганаклардан алганнар. Шәһәр мәйданнарында фонтаннар атып торган. Тышлары балчыктан сырлап ясалган бизәкләр, ялтырап торган төсле плитәләр белән бизәлгән матур сарайлар һәм башка җәмәгать биналары, бай кешеләрнең торак йортлары яндырылган кирпечтән салынган. Диварларга, бинага керә торган төп (парадный) ишек өсләренә зәңгәр фонга ак буяу белән матур итеп Коръән сүрәләре язып куелган. Бүлмәләр мичтән торбалар аша идән астыннан җибәрелгән эссе һава белән җылытылган. Биналар эчендә яисә ябулы ишегалдында еш кына су бассейннары да ясалган.

Алтын Урда шәһәрләренең шул вакыттагы күренешен күз алдына китерү кыен түгел. Үзбәкстанның Сәмәрканд, Бохара шәһәрләрендә булган кешеләр шул чорда салынган биналарга охшаш архитектура истәлекләренә карап сокланалар. Менә шундый гүзәл биналарны инде XIV йөздә үк төзергә өйрәнгәннәр икән. Һәм бер Сарайда гына түгел.

УРДА – ӘДӘБИ БОСТАН

Алтын Урданы чын цивилизацияле дәүләт ясаган факторларның берсе – аның югары үскән мәдәнияте. Үзәкләштерелгән дәүләт, куәтле икътисад, күпсанлы шәһәрләр, чит илләр белән тыгыз бәйләнешләр мәдәният үсеше өчен уңай шартлар тудыра. Алтын Урда хакимнәре, бигрәк тә Бәркә, Үзбәк, Җанибәк ханнар, үз тирәләренә ерак илләрдән чакырып китерелгән зур галимнәрне, дин белгечләрен, шагыйрьләрне, башка гыйлем ияләрен җыйганнар, аларга эшләрендә, иҗатларында ярдәм итеп торганнар. Бу хакта аларның замандашлары язып калдырган. Мәсәлән, «Бәркә үз халкы арасында ислам дине тарата башлый, үз биләмәлеренең барысында да мәчетләр ача, галимнәрне һәм закон белгечләрен үзенә якынайта, алар белә дуслаша» (Ибн Халдун). Үзбәк хан вакытында ислам дине дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрелә, ул «галимнәр өчен өчен мәдрәсә төзи, гыйлемгә, фән кешеләренә бик тугрылыклы була» (әл-Омари). Җанибәк тә «галимнәргә, белемнәре, суфыйлыгы һәм диндарлыгы белән аерылып торган һәркемгә зур ихтирам күрсәткән» (Абу-л-Гази Баһадур). Урта гасырлар тарихчысы Ибн-Гарәпшаһ язганча, Бәркә хан чорында ук инде Сарай «фән үзәге һәм рәхәтлек чыганагы булып җитешә, кыска гына вакыт эчендә анда мактаулы галимнәр, атаклы телчеләр һәм башка атказанган зыялылардан торган шактый күпсанлы һәм көчле бер төркем оеша». Галимнәр хезмәтләрен гарәп, фарсы, төрки телләрендә язалар. Әдәби әсәрләр нигездә татар теленә якын торган кыпчак телендә үсеш ала. Рәсми хан ярлыклары, Алтын Урда әдәбиятының иң гүзәл әсәрләре – Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358), Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан» (1369), Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» (1391) әсәрләре шушы телдә язылган.

Алтын Урдада мәдәният чәчәк аткан чор озакка сузылмый, ул башлыча Бәркә, Үзбәк һәм Җанибәк ханнар идарә иткән елларга туры килә. XIV гасыр урталарында башланып киткән тәхет өчен бертуктаусыз көрәш, төрле өлкәләрнең бәкләре-әмирләре арасындагы сугышлар тискәре нәтиҗәләргә китерә. Алтын Урда таркалуга йөз тота. Моңа кадәр тыныч кына иҗат итеп яткан укымышлы затларның күпчелеге илне ташлап китәргә мәҗбүр була. Әмма Алтын Урда цивилизациясе бабаларыбыз тормышына, яшәешенә үзенең тирән тамырларын җибәрергә өлгерә инде. Татар тарихыннан Алтын Урда чорын алып ташлау мөмкин түгел.

PRESSA.RU

ҖИЛӘКЛЕ БИСТӘСЕНДӘ ҖИЛӘК НИК ҮСМИ?

Казанның Киров районына караган Җиләкле бистәсенә барырга җыенганда танышлар: «Газ пистолеты булса да алыгыз, куркыныч анда», – диделәр. Чынлап та шулай икән! Рәхмәт, бистә кешеләре ташламады: урамнар буйлап сәяхәт кылганда озата йөрделәр. Туктаусыз этләр өрә. Бер кулда – таяк, икенчесендә – тимер чүкеч. Өстәвенә, көн дә болытлап яңгыр ява башлады... Куркыныч фильмнар бер якта торсын, билләһи!

Автор:
Руфия Фазылова

«ЕЛЫЙ-ЕЛЫЙ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ КАЛМАДЫ...»

Җиләкле бистәсе Казанның үзәгендә урнашкан дисәм дә була: машина белән Кремльгә нибары ике-өч минутлык юл. Биек йортлар артында шундый авыл (дөрес, рәсми исеме андый түгел аның) бар дип һич кенә дә уйламассың! Монда барысы да гаҗәп: урам уртасында күл булып җыелып яңгыр сулары мөлдерәп ята, ярым ишелгән йортлар моңаеп утыра, капка төпләрендә кеше биеклегендәге чүп үләннәре гаскәр кебек тора... Шәһәр белән авыл арасында – ун метр ара һәм... әйтеп бетергесез аерма.

Матур йорт эзләп, Кече Крыловка урамында йөрибез. Яңа, зур гына эшләнгән йортның кап-

Фото: Александр Ефремов

касын шакыдык. Ишек алдында башына яулыгын бөркәнгән сөйкемле генә апа күренде. Нурия исемле икән:

– Мин бирегә 1975 елда килен булып төштем, ә ирем Илшат монда туып-үскән. Әйдә, танышырсыз, – дип, Нурия апа Галимова безне өенә чакырды.

Капкадан кергәч тә, күзем әнис алмаларына төште. Рәсемдәге кебек алар: кып-кызыл.

– Янгында алмагачның бер ягы янды, бөтенләй корыр дигән идек, быел, шөкер, алма бирде, – диде Нурия апа.

Галимовлар гаиләсенә 2015 елда бик зур фаҗига килгән: җәй башында йортлары янып беткән. Документтан гайре ялкыннан бер генә әйберләрен дә алып чыга алмаганнар.

– Бишәү: ирем, улым, киленем, яңа туган онык белән урамда калдык, – дип, Нурия апа моңсу хатирәләрен яңартты. – Ирем белән иртәнге чәйне эчеп бетереп базарга җыенып йөри идем, балалар бүлмәсеннән кара төтен чыкты. Документларны гына алырга өлгердек. Әле ярый балалар өйдә юк, оныкны хастаханәгә алып киткәннәр иде. Бабай да, мин дә – намазда. Янгын буласы көнне дә төне буе намаз укыган идек. «Ни өчен безгә мондый хәсрәт бирдең?» – дип елый-елый күздә яшь калмады. Бу күкләр тарафыннан бирелгән сынау булган, моны соңрак аңладык. Аллаһ Тәгалә: «Бер кулым белән алсам, икесе белән бирермен», – дигән. Хак ул, кыш башланганчы яңа йортыбыз әзер булды. Могҗиза димичә, нәрсә дип әйтәсең?!

Илшат абый Галимов та тормыш иптәше кебек үк ачык йөзле, сабыр кеше. Җиләкле бистәсе турында күп мәгълүмат белә булып чыкты.

– Бездә Җиләкле бистәсе тарихы турында китап та бар иде, – дип сүзен башлады Илшат абый. – Әти-әнидән калган иде ул, янды бит. Менә шул китаптан укыган мәгълүматлар истә. Җиләкле бистәсе атамасын Казан ханлыгы чорында биргәннәр. Ул чорда кура җиләге, җир җиләге, каен җиләге, караҗиләк һәм башка бик күп төрле җиләк-җимеш үскән. Казан ханлыгы яулап алынганчы Җиләкле бистәсендә татарлар тормышы чын мәгънәсендә чәчәк аткан. Аннан соң бистәгә руслар да күченеп утырган, ә татарларның күбесе куылган. 1825 елда

– Бу каркас йортыбыз 2 миллионга басты, – ди Илшат Галимов.

Җиләкле бистәсе Казан шәһәренә кертелгән. Атаклы Алафузов фабрикасы монда булган. Нигездә, бистәдә гади крестьяннар яшәгән. Биредә 1930нчы елларга кадәр «Бишвакытлы» дип исемләнгән мәчет эшләгән. Эшчеләр өчен халык училищесы булган. Анда татар сыйныфлары да эшләгән.

Илшат абый Җиләкле бистәсендәге һәркемне белә, «аяклы энциклопедия» дияргә дә мөмкин аны. Ленская, Батыршин, Серов урамнарындагы күпкатлы йортлар, Мәскәү базары аның күз алдында төзелгән. 1970нче еллар башына кадәр анда шәхси йортлар булган.

– 1960–1970нче елларда безнең бистәдә тормыш гөрләп тора иде, – ди Илшат абый. – Җитен комбинаты, тегү фабрикасы, күн эшкәртү фабрикасы, дары заводы, йон юу, йон эшкәртү фабрикалары – барысы да Киров районында булды бит. Иртәнге дүрт-биштә бистәдә тормыш башлана иде. Завод-фабрикалар аркасында үскән дә ул. Халык эш урынына якынрак җирдә яшәргә тырышкан. Югыйсә, монда җирләр бер дә кызыгырлык түгел, сазлыклы урын. Яшелчә утыртам дисәң, ел саен әллә ничә йөк машинасы ком, туфрак кертергә кирәк. Хәзер дә шулай. Гомумән, ул чор белән хәзерге вакыт арасында әллә ни үзгәреш юк: халык гомер буе үзләрен биредән күчерерләр, йортларны сүтәрләр дип куркып, шуны көтеп яшәгән. Бүген дә шул ук хәл. Инде балалар үсеп җитеп, оныклар туды. Һаман билгесезлектә яшибез...

Галимовлар, йортлары янганнан соң, ике ай документлар тотып төрле ишекләрне шакып караганнар: ун сутый җирләре урынына, бәлки, аларга фатир бирерләр? Тик анык җавап ишетмәгәч, яңа йорт салырга карар кылганнар.

– Бу каркас йортыбыз 2 миллионга басты, – ди Илшат абый. – Янган йортны иминиятләштергән идек, аннан 500 мең сум акча күчте, калганы мәрхәмәтле кешеләр ярдәме белән булды. Мин, вертолет заводында эшләп, лаеклы ялга чыктым. Заводның ветераннар советына барып гариза язган идем, рәхмәт җитәкчелеккә, 156 мең сум акча бирделәр. Улым эшләгән «Оргсинтез» заводы да бик ярдәм итте, акчалата да, хезмәттәшләре дә килеп булышты. Тагын бик зур ярдәмне мөселман кардәшләребездән күрдек. «Рамазан», «Ярдәм» мәчетеннән зур суммада акча, азык-төлек тә китерделәр. Туганнар, күршеләр – берсе дә ташламады. Барысына да зур рәхмәт! Аллаһы Тәгалә ярдәмен бирә, мәрхәмәтле кешеләр дә тирә-юнебездә күп икән, шуңа инандык.

PRESSA.RU

Әдһәм абый Закирҗановның ихатасы балачакка алып кайтты.

РЕТРО АВТОМОБИЛЬ ХУҖАСЫ!

Галимовлар яшәгән урамда асфальт юл бар, өч ел элек түшәгәннәр. Янәшәдә генә тугыз катлы йорт салмасалар, мондый бәхет тәтемәгән дә булыр иде. Ә эчкә таба, бистәнең калган урамнарында, асфальт юк. Нурия апа аягына резин итекләр киеп безне күрше Гончаров урамына алып китте. Кулына таяк тотты:

– Әйдә, озата барыйм, монда таяксыз йөрергә куркыныч, этләр ташлана, – ди Нурия апа. – Узган ел Батыршин урамына барганда, юлны кыскартыйм дип бистә эченнән киткән идем. Каршыма унлап эт чыкты, чолгап алдылар. Ни селкенергә, ни кычкырырга куркып торам. Бәхеткә, тәрәзәдән мине күреп бер хатын чыкты. Таяк белән этләрне куып җибәрде.

Нурия апа безне кечкенә генә йортка алып килде. Капка эченнән өзгәләнә-бәргәләнә эт өрергә тотынды. Җиләкле бистәсенең бер үзенчәлеге – һәрбер йортта эт бар.

Капкадан кечерәк кенә буйлы, түгәрәк йөзле бабай күренде. Әдһәм Закирҗанов икән, 1933 елда туган. Йорты да үзеннән әллә ни яшь түгел, 1953 елда салынган.

– Әти-әни бу нигезгә 1941 елда Биектау районыннан килеп төпләнгән, – диде Әдһәм абый. – Әнинең абыйлары бирегә яшәгән. Кайвакыт: «Ичмасам, берәр уңдырышлы туфраклы җиргә дә килеп урнашмаганнар», – дип уфтанам. Бигрәк начар бит җире. Үземне белгәннән бирле бу нигезгә балчык кертәм. Җир аска китә, су өскә чыга. Бакчаны карап тормасаң, яшелчә үстерәм димә...

Әдһәм абыйның тормыш иптәше тугыз ел элек вафат булган. Бүген кызының балалары ике оныгы белән яши. Тугыз сутый җирләрендә барысы да бар: йорты, сарае, гаражы, бакчасы. Элек мал-туар да асраганнар, хәзер инде җиде тавык кына калган.

– Үз йортың белән яшәп, бер хайван да асрамагач, әллә ничек, – дип куйды Әдһәм абый.

Тавыкларны ике елга бер алмаштырып тора икән. Аларны кош базарыннан барып алалар. Игенне исә көзге ярминкәләрдән алып калалар.

Әдһәм абый мыек астыннан гына елмаеп: «Хәзер мин сезгә бер нәрсә күрсәтәм әле», – дип, гаражын ачып җибәрде. Ә анда «Москвич» тора. Ялт иткән, 1981 елгы машина икән.

– Ул чорда машина алырга рөхсәтне һәркемгә дә бирмиләр иде, – дип горур елмайды Әдһәм абый. – Мин илле елдан артык Дары зоводында эшләдем, Мактау тактасыннан төшмәдем. Заводның иң яхшы эшчесе буларак, «Москвич» алырга рөхсәт бирделәр. Җиде меңгә сатып алдык аны. И, ничек сөенгәнне белсәгез! Зур нәчәлникләр кебек, машинага утырып чыгып китәм...

Әдһәм абыйның ике гаражы бар (дөрес, алар зур түгел). Икенчесендә «Урал» мотоциклы саклана. Шулай ук, бер дигән кыяфәттә.

– Бу техникалар йөриме соң? – дим бабайга.

– Ничек йөрмәсен, әлбәттә, йөри. «Москвич» белән быел бер тапкыр гына чыктым, ә менә «Урал»да еш йөрим. Мотоцикл булганга, машина яхшы сакланды. Хатыным белән «Урал»га утырып печән дә ташыдык, базарга да йөрдек. Ә машина рәеш өчен торды.

Әдһәм абыйның ихатасы балачакка алып кайтты. Такта капкалар, караеп беткән кечкенә сарайлар, җиргә утырган йорт. Әби-бабайлар яшәгән йортлар нәкъ менә шундый була иде. Хәзер авылларда мондый йортлар сирәк инде, булса да, аларда кеше яшәми. Ә монда – Казан уртасында...

Бабай, елмая-елмая, алмагачыннан алма өзеп бирде. Ул нәкъ татар карты: изге күңелле, юмарт, җор телле.



Рәшидә апа Сафина.

Әминә апаның биш савым кәҗәсе бар.

ФАНТАСТИКА ЯЗАРЛЫК...

Җиләкле бистәсендә кәҗә асраучы берничә кеше бар диделәр. Нурия апа безне Полевой урамында яшәүче Наилә апага алып китте. Һәр капка төбендә эт ята. Исебез китеп җиргә сеңеп үк беткән өйләрне карап барабыз. Аларда да кеше яши икән. Дөрес, яңа салынган йортлар да күзгә чалынды.

– Балалар ата-аналарына караганда кыюрак, иске өйдә яшисе килмичә, кайберләре ата-ана нигезенә яңа йорт сала, – ди Нурия апа.

– Ә сүтсәләр? – дим.

– Шулай кала инде. Сүткән очракта йортка карамыйлар, сутый исәбеннән акча түләячәкләр.

– Сутыена күпме акча өмет итәсез?

– Белмим, әйтүче юк. Миллион ярымнан да ким булмастыр, дибез. Монда җир кыйммәт йөри.

Нурия апа белән бер капканы шакыдык, ачучы булмады. Шунда гына дүрт-биш ир сөйләшеп тора иде: «Ул кәҗәләрен бетерде», – диделәр. Ирләрнең берсе – Николай – безне кәҗә асраучы күршеләренә алып барырга булды. Нурия апага рәхмәтләр әйтеп саубуллаштык. Икенче экскурсиячегә ияреп, юлны дәвам иттек.

– Икешәр метрлы чүп үләннәре үсеп утыра. Ни өчен аларны чапмыйлар? – дим Николайга.

– Ә ул безнең эш түгел!

– Кеше капка төбен үзе чабарга тиештер инде? – дим.

– Юк, администрациядән кеше җибәрсеннәр. Әнә, юлларны карамыйлар. Монда һәр ике йорт саен – балалар. Махсус мәйданчык эшлибез дип, җитәкчелек яз көне вәгъдә бирде. Шул этләрне дә аулаучы юк, «беспредел» монда...

Николай да шушы бистәдә туып-үскән икән. Әлегә кадәр хатыны белән әбисеннән калган йортта яшиләр. Әллә нинди сәер, серле хәлләр турында сөйләде, фантастика язарлык! Ул безне кеше яшәми торган бер йортка алып китте. Кыргый этләр шунда балалап, үрчеп ята икән. Шулай ук тәртипсез тормыш рәвеше алып барган кешеләр дә кергәли ди. Моның кадәр кыйссаны ишеткәч, шикләнеп калдым. Ә фотограф Александр экскурсияче артыннан элдертә генә.

– Курыкмагыз, кулда тимер чүкеч, – ди Николай.

Куаклар басып киткән йортта, чынлап та этләр яши булып чыкты. Төрле зурлыктагылары бар. Юкка борчылганмын, этләр хәтта өреп тә карамады.

– Алар мин булганга гына сезгә тими, ә чит кешеләргә ташланалар, – диде бик зур эш башкарган кебек Николай. Күршесе өйдә булып чыкмады. Шулай да элек кәҗәләр асраган икенче ханым белән таныштык:

– Ике ел элек соңгы кәҗәне күршеләргә саттым, – диде Рәшидә апа Сафина.

Озын сүзнең кыскасы, бу мөлаем ханым безне Җиләкле бистәсенең атаклы кәҗә асраучысы – Әминә апа янына алып барырга ризалашты.

– Бер белмәгән кеше бистәдә еш кына адаша, этләр дә күп, озатыйм сезне, – дип кулына таяк тотты.

– Ни өчен кәҗәне бетердегез? – дим.

– Йөрәккә операция ясаттым, карарга кеше калмады.

Рәшидә апа татарча газеталар да алдыра икән. Күн эшкәртү фабрикасында эшләгән.

– Бистәдә татарлар күп. Аралашып яшибез, – диде ул.

– Бистәдә җиләк үсәме? – дим.

– Хәзер юк инде. Чүп үләне басып алды, бар җирдә – чүп өеме. Үзегез күреп торасыз. Элек бар иде...

Әминә апаның биш савым кәҗәсе бар икән. Ишек алды чәчәкләр белән тулган.

– Сезнең кәҗәләр тәртипле ахры, моның кадәр чәчәк үстерә алгач, – дим.

– Алар икенче яктан йөри, ишек алдына кермиләр, – диде Әминә апа.

– Биш кәҗә сөтен кая куясыз дим?

– Сатам, яшь балалары булган ата-аналар Казанның икенче почмагыннан ук килеп алалар. Кәҗә сөтен үзебез дә яратабыз.

Әминә апа кәҗә сөтен литры 120 сумнан сата икән. Аның файдасы турында бәйнә-бәйнә сөйләде. Халыкта «Кәҗә мал түгел...» дигән гыйбарә яшәсә дә, Әминә апа гомер буе әлеге хайванны асраган. Көнеле шулай куша, акчасы да, акмаса да, тама бит.

– Кәҗәләрне ел саен киметермен, дим дә, шулай кала. Аларга ияләнү бик тиз, балаң кебек күрә башлыйсың, – диде ул.

Җиләкле бистәсе миңа бер музейны хәтерләтте. Аның хәтта кешеләре дә үзгә, ачык, гади. Күңелдә авылга сусау тойгысы барлыкка килсә, шунда барып кайтырга киңәш итәм.

КҮКТӘН МОГҖИЗА ТӨШӘРМЕ?

Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы урынбасары **Айдар Заһиров** белән элемтәгә кердем. Андагы проблемалардан хәбәрдар булып чыкты ул:

– Җиләкле бистәсендә яз саен диярлек булам. Ташу вакытында халыкның идән асларына су тула, юлларны да су баса. Махсус машиналар чакыртабыз, насос белән суны суырттырабыз. Дөресен генә әйткәндә, анда җавапсызрак халык яши. Язын ул карны су төшмәслек итеп көрәп була бит. Җәен капка төпләрендә чүп үләннәрен дә чапмыйлар. Күктән могҗиза төшкәнне көтеп яталар.

Әлбәттә, бу урын инвесторлар өчен бик кызык, шәһәр үзәгендә бит. Тик әлегә бистә халкын күпкатлы йортларга күчерү турында сүз бармый. План буенча 2019 елга канализация суларын суыртучы станция (КНС) эшли башларга тиеш. Менә шуннан соң Җиләкле бистәсенә күпкатлы йортлар салырга мөмкин булачак. Аңлашыла ки, ул вакытта кешеләргә үз ихаталарын ташлап китәргә туры киләчәк.

PRESSA.RU

«ДУСЛАРЫМ, САГЫНЫП КАЙТТЫМ...»

Кәрим Тинчуринның
130 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ УҢАЕ БЕЛӘН ЧОР ҺӘМ ШӘХЕС ТУРЫНДА ЭСКИЗЛАР

Безнең балачак аның сагындырып, хәтта ки зарыктырып сәхнәләргә әйләнеп кайткан «Зәңгәр шәле», «Сүнгән йолдызлары» гөрләп барган елларга туры килде. Без бу җәһәттән – бәхетле буын. Тинчуринның Булаты, Мәйсәрәсе, Сәрвәре, Надир мәхдүме, абыстайлары, урман качкыннары һәм башка каһарманнары да, әсәрләрендәге лейтмотивлар да тормышыбыз микрокосмосы эчендә даими яшәп килделәр.

Луиза Янсуар
әзерләде

Туган-тумачалар, халык гыйбарәләре кебегрәк. Берәр ашыгычрак эш булса: «Тизрәк, юкса абыстайлар куера», – дип шаяртып кую – табигый күренеш. Һәркемгә сүзнең ни турында баруы аңлашыла. Ә Сәйдәш белән Тинчуринның ул спектакльләргә язган җырлары. Алар телдән төшми җырлана иде. Шуңадыр, бәлки, аны – сәхнәләрдә уйналып торса да, инде кабат үзебезгә әйләнеп кайтса да – сагынып яшим. Куркыныч, шомлы булса да – чорларын. Ул чордагы соклангыч иҗади тандемнарны. Алар калдырган югары кимәлдәге сәнгатьне. Тәрбияне. Затлылыкны. Эстетиканы.

Татар драма сәнгатенә, театрына нигез салучыларның берсе булган Кәрим Тинчуринның язмышы милли сәнгатебезнең иң күркәм, күтәрелеш кичергән еллары белән бергәттән, иң шомлы, канлы сәхифәләренә дә туры килә. Исеме акланганчыга кадәр, татар театрына җан өргән бу шәхес турында 19 ел дәвамында беркем дә искә алырга җөрьәт итми. Аның спектакльләре, әсәрләре турында да тел тибрәтеп әйтү ярамый, билгеле. Әмма иң гаҗәбе – халык, исемен телгә алырга ярамаса да, Тинчуринның үзен дә, спектакльләрен дә хәтерендә саклый. Бигрәк тә – алардагы каһарманнарны, җырларны, репликаларны...

Мөхәммәт Мәһдиев, язучы:

«Килер вакыт, куярлар...»

«Аның барлыгын, Татар академия театрында бөтен бер Тинчурин чоры, Тинчурин мәктәбе булганлыгын без, яшьләр, интуиция буенча сизә идек. Безнең буын авыл сәхнәләрендә «Зәңгәр шәл» һәм «Кандыр буе»н куйган кешеләр арасында тәрбияләнеп үсте. «Кандыр буе»ның көен:

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...

дип җырлыйлар иде. Әле кырыгынчы елларда гына, мәктәп коридорында шыңшып узган укытучылардан ишеткән бар иде:

Дусларым, сагынып кайттым...
Дусларым, ерак илләрдән...

Моның нәрсә икәнен белми идек, ләкин ниндидер сихри-лирик интонация безне әсир итә иде.

– Ни өчен «Зәңгәр шәл»не куймыйбыз?

Скрипкада уйнаучы ак чәчле укытучы, елмаеп:

– Килер вакыт, куярлар, – диде. Аннан, көрсенеп: – Их, Булатны уйнаган заманнар бар иде, – дип, скрипкасын сызып җибәрде.

...Казан университеты студентлары белән фәнни экспедициядә йөргәндә, Себер татарлары безне күп мәртәбәләр адаштырдылар. Без алардан халык иҗаты әсәрләре өмет итәбез, ә алар безгә Тинчурин җырларын яздыралар икән. Шулай, Томск өлкәсе Кызылкаш авылында бер карттан тырышып-тырышып җыр язабыз. Кулда дәфтәр-карандаш, картның янында шыпырт кына портатив магнитофон әйләнә. Җырның сүзләренә, аһәненә гаҗәпкә калабыз:

Тамбур инәләре көмеш саплы,
Немец илләреннән алынган...

Казанга кайткач, тикшереп карасак – бу җыр Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ыннан икән...»

1956 елда, исеме аклангач, Тинчуринның әсәрләре кабат сәхнәгә әйләнеп кайта. Тамашачы спектакльләргә йөрмәгән торгынлык елларында сәхнәгә Шириаздан Сарымсаков куелышында кабат «Зәңгәр шәл»нең күтәрелүе олы бер вакыйгага тиң. Һәм барысын да гаҗәпкә калдырган хәл була: тамашачы «Зәңгәр шәл»гә агылып йөри башлый. «Мин моңа үзем шаһит – спектакль ай буе алкышлар белән барды, зал шыгрым тулы иде. Шунысы гына аяныч: Салих Сәйдәшев бу әсәрнең терелүен, шундый уңышка ирешүен күрә алмыйча, ике ел алдан вафат булды», – дип язып калдыра бер истәлегендә инде үзе дә мәрхүм Марсель Сәлимҗанов.

Хәзерге көнгәчә театр тәнкыйтьчеләре бу спектакльнең тәэсир итү көченә төшенеп җитә алмыйлар. «Зәңгәр шәл»нең хәзергесенә кадәрге куелышына да, яңасына да башка милләт вәкиленнән булган шактый гына танышларымны алып барганым булды. Искиткеч дәрәҗәдә халыкчан, милли булуына карамастан, теләсә кайсы милләт вәкиле тарафыннан «укыла» ул. Ә «укылып» җитмәгән элементлар кызыксыну, ымсыну уята, алары хакында сораштыра башлыйлар, белешә, эзләнә. «Шекспирдагыдан да көчлерәк тәэсир ясый хәтта. Тегендә хакимият өчен патшалар, династияләр, кланнар көрәшә, кан коя... ә монда... гади җирлектә... гадәти кешеләр... Бу һәр заманда булган, һәм булачак...» – дигән иде бер танышым. Бәлки, аның сере әнә шундадыр?

1887 елның 15 сентябрендә Пенза өлкәсенең Аккүл (элеккеге Таракан) авылында туа кечкенә Кәрим. Әтисе Гали тырыш, урта хәлле крестьян була, әнисе Мәхмүдә исә – укымышлы мулла кызы. Улының белемгә атлыгып торуын хуплаучы, киләчәктә аны Казанга җибәрүче дә әнисе була. Күрше авыл мәдрәсәсендә башлангыч белем алгач, 1900 елда Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә Кәрим. Алты ел укыганнан соң, мәдрәсәдәге фәннәр белән генә канәгать булмыйча, үзлегеннән белем ала. 1906 елда мәдрәсәгә реформа таләп иткән шәкертләр белән бергә протест йөзеннән, Кәрим Тинчурин да «Мөхәммәдия»не ташлап чыга. Аннан соң төрле эшләрдә эшли. 1910 елда ул Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр»гә актер булып эшкә урнаша. Беренче драма әсәрләрен яза. Үзе уйнау белән

Мөнир Сәләхетдинов,
яшьлек чорындагы танышы:

«Миңа юл күрсәтүче булдыгыз...»

«Кәрим Тинчуринны 1911 елдан бирле беләм. Ул вакытта Галиулла исемле бер егет белән өс киеме һәм тамак ялына Садыйк Мусинның мануфактура магазинында «өйрәнчек» булып эшли идем. Ә Кәрим абый монда конторщик вазыйфасын үти. Ул иртәнге якта гимназия күләмендә өлгергәнлек аттестаты өчен имтиханга әзерләнә, эшкә көннең икенче яртысында гына килә иде. Кичләрен «Үзбәк» кушаматы белән «Шәрык» һәм Яңа Клубларда «Сәйяр» труппасы составында спектакльләрдә катнаша һәм аларны карарга Галиулла белән мине дә алып баргалый иде. Аның өстендә кара костюм, җәйге пальто, башында эшләпә, муенында һәрвакыт бер үк галстук була. Чәче җитү.

Кәрим абый ачык чырайлы, мәзәк яратучан кеше иде. Безнең кибет подвалының бер өлеше ашау-эчү урыны булып хезмәт итә. Мин Рамазановлар харчевнясыннан самовар кайнатып чыгам, кибетчеләргә чәй эчерәм, ә Кәрим абый мине: «Безнең Мөнир бар иде, чәйне бик сөя иде. Чуди-чуди, чудиса, чәйне бик сөя иде...» – дип үрти иде. Мондый чәй мәҗлесләрендә бай өйдә булмаган вакытларда Габдулла Кариев, Габдулла Тукай, Гафур Коләхмәтов, Хөсәен Ямашев, Галиәсгар Камал, Ибраһим һәм Исмәгыйль Айтугановларның да катнашулары хәтердә.

1912 елның җәендә булса кирәк, Кәрим абыйны Газиз Гобәйдуллин Кырымга курортка алып китте. Шуннан соң инде ул конторада эшләмәде. 1936 елда, Кәрим абыйның иҗат эшчәнлегенең 25 еллыгы уңае белән, мин аны котлап хат язган идем. Шул елның 16 июнь числосы белән ул миңа түбәндәге хатны җибәрде: «Хөрмәтле Мөнир иптәш! Сезнең минем 25 еллык хезмәт бәйрәмемне искә алып, котлап дусларча язган хатыгызны укып бик куандым... Сез: «Эшләп укырга миңа юл күрсәтүче сез булдыгыз», – дисез. Минемчә, сезгә дә, миңа да юл күрсәтүче, безгә бүгенге матур тормышны тудыру өчен ул чакта ук көрәшүче батыр большевиклар булган...»

1918 елда Кәрим Тинчурин «Сәйяр» труппасының җитәкчесе итеп билгеләнә. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиянең сәяси идарәсе карамагындагы Унөченче труппаның баш режиссеры, 1920 елда Самара шәһәрендә ачылган театр студиясендә укытучы һәм баш режиссер, 1921 елда Оренбург шәһәрендә Г.Кариев исемендәге труппаның җитәкчесе вазыйфаларын башкара, 1922 елда Ташкентта Гыйльми советның театр бүлегендә эшли. Аннары Казанга әйләнеп кайта һәм 1922 елның 8 ноябрендә Казанда махсус бинада Татар дәүләт театры ачыла...

Журналист, актер һәм язучы буларак актив эшчәнлек алып бара ул бу елларда. Иҗатында музыкаль драмалар өстенлек итә башлый, Салих Сәйдәшев белән аларның уңышлы тандемы барлыкка килә. Уртак иҗади дуслык нәтиҗәсендә «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе», «Ил», «Сүнгән йолдызлар» пәйда була. Тинчурин оста педагог буларак та таныла: күп кенә яшь драматургларны иҗатка тарта, әсәрләрен сәхнәгә менгерә. Артистлар аны зур ихтирам белән искә ала торган була.

«Тинчурин – үзенең күңел байлыгын юмарт өләшүчән кеше иде, – ди бер хатирәсендә актриса Фатыйма Ильская. – Аның бөтен хәрәкәтендә, йөрешендә, кешегә мөрәҗәгать итүендә, артистларга күрсәтмәләр бирүендә кешегә зур хөрмәт сизелә. Ул һәрвакыт якты йөзле. Уен-көлке ярата... Чын кеше, олы йөрәкле кеше иде...»

PRESSA.RU

1. Кәрим Тинчуринның футлярлы зур сәгате.

2. Кәрим Тинчурин тормыш иптәше Зәһидә ханым белән.

беррәттән, труппаның репертуарын баету өчен дә тырыша.

Кәрим Тинчуринның тормыш иптәше Заһидә ханым белән язучы Рабит Батулла 80нче елларда очрашып, еш кына әңгәмәләр кора. Бу сөйләшүләрдән Кәрим Тинчуринның тормышта нindirәк кеше булуы яхшы шәйләнә. Алар булмаса, Тинчурин турында без бик аз белгән булыр идек, мөгаен. Шул сәхифәләргә тукталмасак, дөрес булмас иде.

«БИК ИНТЕРЕСНЫЙ ЕГЕТ ИКӘН...»

«Кәрим Тинчуринның булачак хатыны Заһидә Әхмәрова затлы гаиләдән була. Яхшы белем, тәрбия алып үсә, үз заманының алдынгы фикерле туташларыннан санала. Гимназия тәмамлый. «Шәрык» клубына, Мәдәният йортына әдәби кичәләргә йөри. Бервакыт Мәдинә Терегулова үзенең туена Заһидә туташны да чакыра:

– Кил, зинһар, туебызга Кәрим әфәнде Тинчурин да чакырулы. Мин сезне таныштырырмын. Гаять мәһабәт егет, зыялы нәселдән.

Туй башлана. Тинчурин юк та юк. Туй азагында гына Кәрим әфәнде мәҗлескә килеп керә.

– Тинчурин килде, Тинчурин килде! – диләр барысы да.

Тинчурин, пианинога таянып, һичкемгә һични әйтмичә, шулай озак кына басып тора да, бер җай табып, юкка чыга. Ул чыгып китүгә үк, Заһидә туташ Мәдинәгә:

– Шушы булдымы инде синең Тинчуриның? – ди. – Бик интересный егет икән, сөйләшә дә белми.

– Юк, юк, – ди Мәдинә ханым. – Әйбәт кеше ул. Бүген әллә ни булган аңа.

– Ошамады миңа синең Тинчуриның! – ди Заһидә туташ».

«МОРЗА КЫЗЫНА ӨЙЛӘНГӘН!»

«1919 елда Кәрим Тинчурин белән Заһидә Әхмәрова өйләнешәләр. Заһидә үзе Европа, рус культурасына ныграк тартылса да, туганнарының: «Никах укытабыз» – дигәненә каршы килми.

Зур туйлар ясап тормыйлар, авыр вакыт. Тары ярмасыннан ботка, өйрә пешереп, мулла чакырталар. Никах вакыты килеп җитеп, узып китсә дә, мулла да юк, Кәрим кияү дә юк. Йорттагылар борчуга төшә. Нишләргә инде? Кәрим никахтан качса? Бөтен татар дөньясына, бөтен Казанына оят, валлаһи!

Менә берзаман, көпчәкле арбага утырып, мулла белән Тинчурин кайтып килә. Кәрим күп итеп чәчәк бәйләмнәре алган – колашенә бүләк.

«Кәрим Тинчурин морза кызына өйләнгән!» – дип бөтен Казан шаулый.

Заһидә ханым ихластан көлә:

– Ә ул морзаның ашарга әпәе дә юк! «

«РӘХМӘТ, КИЛЕН!»

«1922 елда Заһидә ханым ире Тинчуринга әйтә:

– Кәрим! Безнең өйләнешкәнгә ничә ел?

– Өчтән артты, – ди Тинчурин.

– Синең туган авылыңа кайтып килик инде. Атаң-анаңны күрәсем килә. Аларның да килен күрәселәре киләдер бит инде?

Бүләк-санак алып, юлга чыгалар болар. Тарбиевка ыстансасына чаклы поезд белән кайталар. Ыстансада аларны Кәримнең атасы Гали абзый ат җигеп каршы алырга килгән. Такта арбага печән салган, печән өстенә түшәк түшәгән. Ыстансадан Тинчурин туган Таракан авылына кырык чакрым икән. Бик озак кайта торгач, Кәрим, кулын алга сузып:

– Ә-ә-әнә, алда тау күрәсеңме, Заһидә? Шул тау астында безнең авыл булыр, – ди.

Шулай дигәч, Заһидә тиз генә калфак киеп, әйбәт чачаклы-чуклы шәлъяулык бәйләп, төзәтенә башлый. Моңарчы дәшмичә кайтучы каената:

– Рәхмәт, килен! – ди. – Рәхмәт! Ату анагыз алдына, авыл халкы каршына шулай тузган баш белән кайта икән, дип кайгыра идем».

«...Унсигез ел буена арабызда «яратам, сөям, гашыйк, мәхәббәт» кебек сүз булмады. Безнең өчен ул сүзләр табу иде. Башка сүзләр аша әйтелә иде ул мәгънәләр. Ул гастрольдәнме, репетициялрдәнме арып кайта да, ишекне кергәч тә борыска сөялеп, миңа карап:

– Ой, рәхәт! – ди иде.

Бу аның «Заһидә, мин сине яратам» дигән сүзе иде... Кәрим бик яхшы ир, дус иде. Миңа бик миһербанлы булды. Мин Кәримгә уңай булсын дип тырыша идем. Аның үз дөньясы барын да аңлый идем. Шуңа күрә мин иремә комачауламаска тырыштым».

Заһидә Тинчурина сөйләгәннәрдән.

«САКЛА, КАЙТКАЧ БИРЕРСЕҢ...»

1937 елның җәендә Заһидә Тинчурина Малиевкага ял итәргә, ә Тинчурин белән Сәйдәшев авылларга – Мамадыш якларына чыгып китәләр. Тинчурин хатынына хатларында болай яза: «Материал җыйдым. Ләкин келтемәчен табып булмый әле...» «Келтемәч» дип Тинчурин пьесаның «формасын, сюжетын» атый торган була. «Келтемәче табылса, пьеса тиз языла ул», – дияргә ярата. Шуннан соң тагын бер хатында: «Яза башладым, келтемәче табылды, язып бетерәм инде», – ди.

Алар көзен Казанда күрешәләр. Көз көне Кәрим Тинчурин яңа пьесасын артистларга, язучыларга укый. Бик олылап аның 50 еллык юбилеен уздыралар. Бу аңлашыла да, Кәрим Тинчурин ул чорда гаять популяр була бит. Заһидә Тинчурина аны кулга алуларын менә ничек искә ала:

«1937 елның 15 сентябреннән 16сына каршы төндә, юбилеен уздырганнан соң, булды бу хәл... Кулга алу өчен прокурор санкциясе дә, ордер да юк килеш, хәрби киемле өч кеше өйгә басып керә дә, капитан әйтә: «Сез Тинчурин Кәрим буласызмы? Киенегез, тиз булыгыз!» – дип боера.

Йокы аралаш Кәрим башта берни аңламый тора. Ике боец идән уртасында кәгазьләр актара. Нидер эзлиләр. Үзләре ни өчендер бик ашыга. «Тиз булыгыз!» – дип кычкыра капитан боецларга... Ул арада Тинчурин киенеп бетте. Тегеләр һаман актарыналар, тентиләр. Кәрим мине тәрәзә төбенә утыртты да, иң өстемә кулын салып: «Әйдә, Заһидә, соңгы тапкыр тыныч кына бергә утырып калыйк әле», – диде. Без икәү, тегеләрнең өй актарганнарына игътибар итмичә генә, соңгы мизгелләрне уздырдык...

Ниһаять, капитан:

– Ирегезгә алмаш күлмәк-ыштан бирегез! – диде.

Мин, тиз генә кирәк-ярак төреп, Кәримнең кулына тоттырдым...

Шулчак Кәрим бармагындагы йөзеген салып, миңа бирмәкче булды:

– Сакла, кайткач, үземә бирерсең, – диде.

Ләкин йөзек салынмый. Кәрим тешләре белән дә тартып карый – юк. Шуннан соң кухняга барып, сабынлап, Кәримнең бармагын каната-каната салдырдык. Йөзек миндә калды...

Ни өчен шулай ашыктылар микән, дип уйлыйм мин гомер буена... Ихтимал, гаделсезлек кылганнарын күңелләре белән сизенгәннәрдер. Ярамаган эшне тизрәк, кабаланып башкаралар бит җинаятьчеләр».

Кәрим Тинчуринны Казанның бөтен төрмәләрендә дә диярлек йөртеп чыгалар. Аның үлеме турындагы хәбәр дә 47нче ел датасы белән килә. «Ничек инде ул 10 ел буе миңа уч төбе кадәр дә хат та салмасын, бу дөрес дата түгел», – ди торган була Заһидә ханым. Рабит Батулла аңа, әлеге датаны төгәллләштерүләрен үтенеп, Тинчуринның чираттагы юбилее алдыннан КГБга хат язарга өнди. Шулай эшлиләр дә. Озакламый КГБдан Кәрим Тинчуринның 1938 елда атып үтерелгәнлеге турында белешмә килеп төшә.

«ҺӘРКЕМ – ҮЗ ЭШЕНДӘ...»

«26 елда кайбер артистлар һәм язучылар Кәрим өстеннән: «Тинчурин үзе яза, үзе куя, үзе уйный. Театрны ул үз монополиясенә әверелдерде», – дип яздылар. Кәримне театрдан чыгардылар. Ишектән мескенләнеп кенә кайтып керде бу. «Заһидә, мине театрдан чыгардылар бит», – ди. «Бик яхшы булган, – дидем. – Язарга вакытың күп булыр. Рәхәтләнеп өйдә генә язарсың. Ә болай төне буе пьеса язасың, йокламыйча театрга китәсең. Эшмени ул?» Әмма эшсез калгач, иҗат итә алмыйча йөдәде. Ул, көндез театрда эшләп, төнлә язу тәртибенә күнеккән иде. Эш эзләп йөри торгач, Политпросветка урнаштырдылар.

– Туктале, Кәрим, – дим. – Син анда нинди эш майтарасың соң?

– Кем ни тели, шуны эшли. Һәркем үз эшендә. Мин «Ил» пьесасын язып утырам, – диде Тинчурин.

...Ачлык бик интектерә башлагач, Кәримнең әйберләрен базарга чыгарып сата башладым. Иң соңыннан аның бер пинжәге генә калды. «Кәрим, – дим, – бар инде, монысын үзең сатып кайт». Көтәм – юк, көтәм – юк. Чыгып киттем эзләргә. Барсам, күрәм, мескенем, аптырап, кыюсыз гына, үзенә генә ишетелерлек итеп: «Харуший пиджак, харуший пиджак», – дип тик басып тора. Кыяфәте чиста, Кәрим үзе мәһабәт кеше иде, янына килүче юк... Озак басып торды ул пинжәген селкетер-селкетмәс.

Тинчурин киткәч, театрның эшләре ал да гөл булыр, дип уйлаганнар бик нык ялгышты. Театрның репертуары да, актерлары да, режиссеры да каушауда иде. Шулай да Тинчуринны театрга кайтармадылар. Аны Әстерханга сөргенгә җибәрделәр».

Заһидә Тинчурина сөйләгәннәрдән.

3

Мәхшәр вакытында Заһидә ханым Кәрим Тинчуринның кульязмаларын сакларга тырыша. Ул аны Әстерханга озата бара алмый, Казанда кала. Аңа: «Тинчуриннан нинди кәгазь калды, барысын да яндыр, үзең белән тотма», – дип киңәш бирәләр. Әмма ул аларны яндырмый. Соңыннан шул кульязмалар арасында сакланып, харап ителмичә калган «Мәрҗәннәр»не бастырып, дөньяга чыгару мөмкинлегенә дә ирешә.

2015 елның 11 ноябрендә бер төркем яшь иҗатчылар тарафыннан Камал театрының Кече сәхнәсендә «1926» дип исемләнгән әдәби-музыкаль спектакль куелган иде. Ул татар театры, әдәбияты, музыка сәнгатенең бәхетле – шаулап-гөрләп торган елларын тасвирлады. Әмма 1926 ел – махсус органнар тарафыннан инде кара исемлекләр төзелә башлаган ел. 30нчы елларда шул исемлекләр буенча тулы бер интеллигенцияне, сәнгать әһелләрен «кырып» ташлыйлар.

Тинчуринның пьесасы да бер төркем иҗатчыны кулга алуга сәбәпче була. Быелгы сезонда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры Тинчуринның шәхесен һәм тормышын өр-яңадан күздән кичереп, аның имин калган «Мәрҗәннәр» әсәрендәге «Утыз өч көн» новелласын нигез итеп алып, «Соңгы әсәр» премьерасын тәкъдим итте. Бу – тарихтагы сәхифәләрне актарып, яңадан күздән кичереп, бүгенге торышыбыз, кайда барышыбыз хакында уйлану да, бәлки?

3. Кәрим Тинчурин иҗатташ дусты Салих Сәйдәшев белән.

Риза Ишморат:

Соңгы әсәр фаҗигасе

«Камал театрында мин баш режиссерлык вазыйфасын алып барган 30нчы елларда пьесалар күп кенә очракта драматургларга махсус заказ биреп яздырыла иде. Тинчуринның соңгы әсәре дә махсус заказ белән язылды... Кәрим абый бу пьесаны вәгъдә иткән вакытында тәмамлады, һәм без аны, партия өлкә комитетындагы иптәшләрнең теләге буенча, театрда түгел, өлкә комитетының культура-пропаганда бүлеге мөдире Гариф иптәш Яушев кабинетында укыдык...

Пьесадагы персонажга чит илдә яшәгән бер татар эмигрантыннан почта аша шунда чыгарылган журнал килеп төшә. Бу эпизодка карата арабыздан берәү: «Шундый хәл булырга мөмкинме?» – дип сорау бирде. Кәрим Тинчурин: «Заманында мин үзем чит илдән пакет алган идем. Бу Гаяз Исхакый җибәргән «Милли юл» журналы иде, мин аны «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә илтеп бирдем», – диде. Бу сүзләрне ишетеп, без аптырабрак калдык. Бу бит шәхес культы афәте иң нык канат җәйгән, Гаяз Исхакый кебек эмигрантларны телгә алырга да ярамаган чор – 1937 ел иде.

Пьеса укылып, күпмедер вакыт үткәч, контрреволюцион милләтче, халык дошманы дип аталып, 1937 елның сентябрендә, нәкъ 50 яше тулган көннәрдә, Тинчурин кулга алынды... Аның язмышы турында төгәл хәбәрне без соңгы елларда гына ишеттек. Ул 1938 елның 15 ноябрендә Плетән төрмәсеннән ерак түгел генә җирдә судсыз-нисез атып үтерелгән...»

PRESSA.RU

«МУЛЛА» КАЙТА...

Без олы юлдан читкә борылабыз да кечерәк кенә бер калкулыкның түбәсенә килеп чыгабыз. Мәһабәт имәннәр һәм тирәкләр арасында ялтырып-балкып торган мәчеткә моннан илаһи бер күренеш ачыла. Бәлки, бу мәчетнең күккә ашкан манарасы, Туфан Миңнуллинның танылган «Мулла» пьесасын фильмга әйләндерү өчен Түбән Шашы һәм Күңгәр авылларын сайлаганда, кино төшерү төркеменә тәүге илаһи билге, хәбәр булгандыр.

Автор:
Олеся Бондаревская

Фото: Ната Смирнова



Кино төшерүчеләрне биек үләнле болында эзләп таптык. Алар фильмда исән килеш бер тапкыр да күренмәячәк Габдрахман исемле геройның җирләү йоласын төшерә. Мәет илтә торган кабык-носилканы сигез ир-ат күтәреп бара.

– Әми-ир, сто-о-оп! Тагын бер мәртәбә! – болынның камера янына төшерү төркеме штабы җыелган тарафыннан әнә шундый тавыш килә.

Җеназа процессиясе әмергә буйсынып туктый һәм барысы да яңадан башлана.

ГЕРОЙНЫ ҮТЕРМӘГЕЗ!

«Мулла»ны экранлаштыру нияте белән янып йөрүчеләрнең берсе, композитор һәм продюсер Марат Әхмәтшинны да шушында – төшерү мәйданчыгында очратам. Сөйләвенчә, фильмны эшли генә башлаган мәлдә, иң әүвәл Россия кинойолдызы Марат Бәшәров катнашындагы эпизодлар төшерелә. Бу персонаж роленә продюсер башка танылган актер, үзенең яхшы танышы Артур Смольяниновны чакырырга ниятли, әмма тегесенең эш графигы, кызганыч, бик тыгыз булып чыга. Шулай итеп, Марат Бәшәров үзенең күптәнге хыялын тормышка ашырып, Татарстан фильмында уйнау мөмкинлеге ала. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектаклендәге кебек, кино ахырында мулланы үтерәчәкләрме – актерны борчыган бердәнбер сорау әнә шул була.

PRESSA.RU

– Ничек соң, – дип кызыксынам, – үтерәләрме?

Марат Әхмәтшин исә безгә ике төрле уйларга урын калдырып, иңбашларын сикертеп куя.

– Димәк, дин өчен җанын фида кылучы булмаячак? – дип, ничек тә ачыкларга тырышам.

– Корбан булачак. Фильмны карагыз, – дип, продюсер барыбер бирешми.

Марат Әхмәтшинның Әтнә театры режиссёры Рамил Фазлыев белән бергә инде өч ел элек ниятләгән проекты быел «Татаркино» оешмасын җитәкләгән Миләүшә Айтуганова инициативасы белән чынга ашу мөмкинлеге ала. Нәкъ менә М.Айтуганова проектның рекламасын иң югары даирәләргә ирештерә һәм фильм өчен грант бирелү аларда яклау таба.

Без кино мәйданчыгы шакылдавыгының актерларны кабат-кабат кире юл башына кайтаруын күзәтеп торабыз. Ул арада Марат Әхмәтшин, аның дингә якынлыгына-ераклыгына карамастан, һәр мөселман тормышында урын алган мулла образы турында үз фикерләре белән уртаклаша. Ни өчен мулла хезмәте һәркемгә кагыла? Бу фигура ник шулкадәр мөһим? «Мин беркайчан да, бернәрсәгә дә ышанмадым, ә ышанасым килде» – пьесада төп мәгънә салынган бу сүзләр асылда ни аңлата?

Хәбәр-билгеләр – һәркайда.

Кино төшерә башлауга үк, бу төркемнең эшенә күп нәрсә нииндидер гаҗәеп рәвештә туры килеп тора.

– Карагыз әле – хәзер яңгыр явачак, – ди әңгәмәдәшем. Башымны күтәреп карыйм: чиксез аяз күкне тиз арада кара болытлар камап ала. Эре, авыр тамчылар белән сәлам биргәндәй яңгыр чиләкләп коя да башлый.

– Беләсезме, бу җеназа күренеше яңгыр вакытында төшерелергә тиеш. Һәм яңгыр нәкъ менә бүген, әлеге күренешне планлаштырган көнне яуды. Ә мондый ымишарәләр, туры килүләр – һәркайда, – ди продюсер. Аннары каядыр авыл эченәрәк күрсәтеп, дәвам итә:

– Әнә шундагы өйләрнең берсенә героебызны – Саматны «урнаштырдык». Рәшәткә артында иманга килгән Әсфәндияр мулланы сюжет буенча авылга әнә шул Самат алып кайткан да инде. Ни гаҗәп: «Самат йорты»ндагы чын хуҗаның язмышы Әсфәндияр тарихының бер чагылышы булып чыкты. Мулла булып китмәгән ул, ләкин төрмәгә эләккәч, иманга килгән. Һәм хәзер яхшы, лаеклы тормыш алып бара.

Ә тегендә, продюсер башка якка ымлый, мулланың булачак хатыны Нәлимәнең гомерендә беренче мәртәбә Коръән уку күренешен төшергән йорт. Анда фильмны төшерә башлагач кына, шул ачыкланды: гаиләсендә авыр хәл-вакыйгалардан соң күршедәге бер хатын бу өйгә кереп Коръән укыган икән.

Марат Әхмәтшин сөйләвенчә, монда – Шашыда да, Күңгәрдә дә, Әтнәнең үзендә дә, районда да кино төшерү бригадасына туры мәгънәсендә төрле яктан ярдәм күрсәтелә.

– Менә «Тукай» авыл хуҗалыгы предприятиесенең директоры Илфат Хәкимов. Ике су помпасын каян табып булыр икән дип сорадым гына аннан. Ун минуттан помпалар күтәреп килеп тә җитте. Монда һәрчак әнә шундый мөнәсәбәт.

Яңгыр бетүгә, актерлар өчен төшерү мәйданчыгында кыска тәнәфес ясала. Гап-гади авыл күлмәкләре кигән актерлар ашыкмый гына, кул уңаена туры килгән чамбыр үләннәренең очларын, сарут койрыкларын өзгәләп, үзләре генә аңлый торган нәрсәләр турында гәпләшә-гәпләшә, болын буйлап йөренә.

БУЙ ҖИТМӘСЛЕК ЕРАК ТА, ГАДИ ДӘ МАРАТ

Кино төшерүдә катнашкан бер авыл кешесен куып тотам. Үзен Радик абый дип таныштырды ул.

– Ә сез Марат Бәшәровны күрдегезме?

– Күрдем. Ерактан. 70 метрлап булгандыр ара, шуннан да якынрак килергә рөхсәт итмәделәр.

Үкенгәндәй, ир башын чайкап куйды. «Мулла»ның сюжеты танышмы сезгә, дип сорадым.

– Бу спектакльне үзебезнең Әтнә театрында карадым. Сюжеты шактый катлаулы. Күңелгә үтеп керә. Мин, әлбәттә, кино төшергәнне күреп тордым. Минем өй янында биш тәүлек төшерделәр. Өйләтирәсенә киләләр дә иртән генә кайтып китәләр. Әйтәм ич, күзәтеп тордым, хәтта төнлә дә чыккаладым, – дип сөйләде миңа Радик абый.

Актер булу кыенмы соң, дип кызыксынам. Радик абый мине үзенчә аңлый.

– Җиңел түгел, бик зур сабырлык кирәк. Алар авылда һәркем белән очраша, сөйләшеп тора. Мин менә өем янында Илдус Габдрахмановны очраттым. Ул көнне төшерү эше беткән иде: «Менә мин, атказанган артист, монда басуда чүп утап йөрим, рольдә шулай кушылган», – ди. Фильмда исерекне уйный ул.

Нәлимә ролен башкаручы кызны куып тотам. Әтнә театры актрисасы Гүзәл Гаффарова якыннан

югары сыйныфларда гына укучы нәфис кыз булып күренә. Өстенә ничектер җыйнаксыз кидерелгән кофтасы, башына бәйләнгән яулыгы аның өчен артык зурларча кебек тоела. Нәлимәне уйнау читенме, дип сорыйм.

– Минем өчен иң авыры – Нәлимәнең ни өчен шулкадәр тупас, кырыс булуын аңлау иде. Ә ул асылда үзе тирәсендәге җирәнгеч, дорфа, тәрбиясез ир-атлардан саклана. Аннары мулла пәйда була һәм аның бар дөньясын әйләндереп ташлый. Хәзер инде Нәлимәнең Аллага ышанасы килә һәм ул сабый баладай ялвара башлый: «Бир миңа бер хәбәр, һәм мин ышаначакмын», – дип сөйли Гүзәл.

«Мулла» – Рамил Фазлыев янына киләм. Әле халык театры булган Әтнә театры сәхнәсендә пьеса авторы Туфан Миңнуллин бик ошаткан теге «Мулла»ны 2009 елда нәкъ менә Рамил куя. Бу спектакль белән күрше төбәкләрдә уңышлы гастрольләр узган театрга киләчәктә дәүләт театры статусы бирелә. Хәзер Рамил Фазлыев – әлеге фильмның режиссёры да, бер үк вакытта төп рольне башкаручы да.

Актерларның әзерләнеп бетүен көткән «мулла»ның йөзе кырыс, караңгы. Аңа сүз кату бераз куркытып та тора, тик бераздан, кемнеңдер эш арасында шаяртып алуына җавап биргәндә, йөзенең ачылып, йомшарып китүен күреп алам.

– Кино төшерү өчен ник нәкъ менә Күңгәр белән Шашыны сайладыгыз?

– Без Әтнә районында төшерәчәгебезне алдан ук уйлаган идек. Гомумән, Әтнә, Казан арты – Мәрҗани, Тукай, Сибгат Хәкимнең һәм башка күренекле татарларның туган ягы, мәдәниятебезнең, рухи асылыбызның бик әһәмиятле урыны. Шулай булгач, мондый фильмны тагын кайда төшерәсең инде? – дип аңлата режиссёр.

– Бәшәров белән эш ничегрәк барды?

– Җиңел дә, гади дә, – ди Рамил Фазлыев, ул тагын нәрсәдер өстәргә тели, тик әңгәмәбезне яңа дубль башлануны белдергән шакылдавык бүлә.

ЗАМАНГА БӘЙЛЕ БУЛМАГАН СЮЖЕТ

Эш белән мәшгуль төркемнән кино төшерү белән бәйле нечкәлекләрне сораштыру мөмкинлеге юклыгын төшенеп, авыл буйлап экскурсиягә кузгалам. Берничә тигез, төз урам, зур-зур агачлар, утыргычлар, хуҗалык эшләре белән мәшгуль кешеләр...

Кызыксынучан каз көтүе күзәтүендә койма буяп яткан бер ханым янына киләм. Авылда кино төшерүләренә карата аның фикерен беләсем килә.

– Карап торырга бик кызык, – ди бу ханым. – Бер күренешне әти-әниләр өендә төшерделәр. Аларның ишегалды да, йорты да, үзләре дә кинога эләгү – шундый шәп. Бу бер истәлек ич! Дискны тапсак, һичшиксез, сатып алачакбыз.

Авыл мәчете янында мондагы мулла – Рубис абыйны очратам. «Мулла» әсәренең идеяләре турында аның уй-фикерләре белән кызыксынам.

– Әлбәттә, чын тормыш белән пьеса арасында параллельләр бар. Мин лаеклы ялда инде, пенсия алам, хатыным белән зур булмаган хуҗалыгыбыз бар, көндәлек йөкне тартып барырга тырышабыз. Ә яшь муллага тормышын ничек җайларга? Аның бернәрсәсе дә юк ич, ә гаиләсен ашатырга кирәк. Шул ук вакытта үз вазыйфаларын да намус белән башкарырга тиеш ул. Монда барысы да иманлы, яхшы күңелле кешеләр. Мәчетебез балалар һәм яшүсмерләр өчен дәресләр оештыра, авыл халкы өчен төрле чаралар үткәрә. Аларга халык бик күпләп килә. Тик болар барысы да еллар дәвамында эшләнде, Коръән хакыйкатен һәр иманлы бәндәгә җиткерү өчен бик күп хезмәт кую зарур, – дип бәян итә Рубис абый.

Инде авылдан чыгып барганда, кино төшерү өчен помпалар тапкан Илфат Хәкимов белән очрашам.

– «Мулла» пьесасында канатлы гыйбарәләргә тиң сүзләр бар, без аларны хәтергә салып калдырдык, һәм менә инде сигез ел узгач та, кабатлап йөрибез. Мәкаль кебек алар. Спектакльне беренче тапкыр уйнагач, аның тамашачыга тәэсире без уйлаганнан, без тоемлаганнан да тирәнрәк булып чыкты. Туфан Миңнуллинның драматург буларак никадәр бөек икәнен шунда аңладым, – дип сөйли Илфат Хәкимов. Авыл хуҗалыгы предприятиесе директоры җирле театрда актер булган һәм теге атказанган спектакльдә участковый ролен башкарган.

– Спектакльне гастрольләргә алып чыккач, аны бертөрле генә кабул итмәүләре ачыкланды, – дип дәвам итә Илфат. – Самара

PRESSA.RU

өлкәсенең бер авылында ахыргы баш июдән соң сәхнәгә бер өлкән агай күтәрелде һәм әйтеп салды: «Егетләр, булдырдыгыз, яхшы уйнадыгыз. Тик безнең өчен бу актуаль түгел инде. Бездә мондый хәлләр егерме ел элек булды». Ул пьесаның лейтмотивын – имансыз авылны киләчәктә бары онытылу, бетү көткәнен күз уңында тоткан. Күңгәрдә дә, Югары Шашыда да, Түбәнендә, бөтен районда да алласызлык, денсезлек һәм торгынлык атмосферасы инде күптән онытылган. Мондагы йортларның пөхтәлеген, тәрәзә йөзлекләренең матурлыгын, халыкның хезмәт сөючәнлеген, ягымлы, дустанә мөнәсәбәтен күрегез. Иман безгә туры юлны күрсәтә. Ислам – тынычлык һәм игелек дине ул. Син Аллаһка ышанган, хак мөселман икәнсең, башкача яши дә, башка фикердә була да алмыйсың.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU



«МИН ТАЛАНТ ҺӘМ ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК ЯКЛЫ»

Луиза Янсуар
әзерләде

Җырлый белү – ул табигый. Безнең өйдә барысы да уен коралларында уйный белә һәм җырлый иде. Мин дә искәрмә түгел. Шуңамы икән, ул бездә әллә ни ис китәрдәй сәләт дип исәпләнмәде. Без үскәндә радиодан Илһам Шакировлар, Әлфия Афзаловалар, Флера Сөләймановалар яңгырап тора иде. Алар да – көндәлек тормышның бер атрибутикасы.

Мин 6нчы класска күчкән елны телевизор алдылар. Әллә нинди зур нәрсә бит инде телевизор ул елларда! Һәркемдә дә юк. Шул телевизордан еш кына балет тапшыралар иде. Тәмам гашыйк булдым бит балетка! Сылу балериналарга охшарга тырыша-тырыша биим, өйдә үзем генә калганда. Үскәч, балерина буласым килә…

«Талантым бармы, юкмы – мин каян белим?!» Тора-бара балерина булыр өчен кечкенәдән әзерләнергә кирәк икәнлегенә төшендем дә, ул хыялдан баш тарттым. Әмма биюен барыбер биедем – гомер буена. 9нчы класста укыганда җырчы булам дип хыяллана башладым. Бу хыялымны мәктәптә анкета тутырганда да язып куйдым. Әмма укытучым, мине янына чакырып алды да: «Музыка училищесына керер өчен талант кирәк, Лидия», – диде. Шулай бервакыт концерт белән Апаска бардык. Шунда мин, пластинкадан тыңлап, «Сияй, Ташкент» дигән җыр өйрәнеп башкардым, үзбәк биюе биедем. Концертта утырган мәдәният бүлеге җитәкчесе миңа мәдәният училищесына керергә киңәш итте.

«Берегез баянда уйнарга өйрәнер, берегез – җырларга, икәүләп югалмассыз». Шулай диде әни. Һәм яңа гына армиядән кайткан Гена дәдәм белән мине Алабуга мәдәният-агарту училищесына укырга чыгарып җибәрделәр. Үзебезнең клубка эшләргә кайтам, дип, вәгъдәләр биреп, кереп булмас инде, дип, курка-курка барганым хәтердә. Анда хор бүлегенә кердем. Бер дә авыр булып чыкмады: өлгерәм, хәтта башкаларга да булышам әле. Җырлата башладылар. Яңа ел концертында Фасил Әхмәтовның «Аккошлар» җырын башкардым. Абыйның укытучысы тыңлап торган да әйткән: «Сеңлең бик талантлы синең, нәрсә эшләп йөри ул монда, аңа Казанга укырга керергә кирәк – музыка училищесына», – дигән. Абый мине җилтерәтеп Казанга алып китте.

Әрсез диючеләр дә бар, әмма мин үземне тырыш дип исәплим. Кеше әрсезлек белән генә әллә ни ерак китә алмый ул. Ә менә тырышлык белән таулар күчерә ала. Талант белән тырышлык икесе бергә кушылса, ул зур бәхет инде. Безнең өлкәдә – бигрәк тә.

Җырчы булу теләге бик көчле иде. Беренче урында минем өчен һәрчак уку торды. Күңел ачулар, уен-көлкеләр – берсенә дә исем китмәде, укыдым да укыдым.

«Әйбәт егет, игътибар ит, аның белән синә бик уңайлы булачак». Берзаман укытучым, Клавдия Щербинина, Рөстәмгә ишарәләп, шулай диде. Сүз уңаеннан: ул гаҗәеп укытучы иде, атаклы тавыш куя торган педагог. Аңарда, миннән тыш, Ания Туишева, Венера Ганиевалар укыган… Ә булачак ирем, Рөстәм Клавдия Захаровнаның тормыш иптәше – Геннадий Щербининда укый иде, ул тромбон буенча белгеч. Мин әле – беренче курста гына, Рөстәм инде икенчедә. Йөри бу минем тирәмдә, йә елмаеп басып тора.

Оялчанрак та булгандыр инде, тәртипле, әдәпле, юк бит, сүз башламый. Шулай итеп мин – өченче, ул дүртенче курска җиттек. Менә берзаман ул мине озата кайтырга булды. Шунда кистереп әйтте: «Миңа бүлмә бирәләр, сиңа өйләнергә телим». Җавабым: «Мин бит җырчы булырга җыенам, Рөстәм, җырчыга кем өйләнә инде?» Ә ул миңа беренче курста ук җырлавымны тыңлап торып гашыйк булган икән. Бик ярата хәзер дә җырлаганымны тыңларга, иҗатымны хөрмәт итә. Шунда әйтеп салды: «Син җырчы булмый гына кара, юкса минем сиңа өйләнәсем юк».

Гаилә ул – бик зур стимул. Әлбәттә, сине анда аңлап, хөрмәт итеп, үсәргә ярдәм итеп яшәсәләр. Үзен иҗатка багышлаган хатын-кыз өчен бигрәк тә кирәк бу. Без бит, ничек кенә көчле, булдыклы булсак та, яклауга, таянуга мохтаҗ. Гаиләм булмаса, тормышымның мәгънәсе нәрсәдә булыр иде икән. Рөстәм минем өчен – бик зур таяныч. Каенанам да миңа: «Ял ит, арыгансыңдыр», – дип кенә тора иде. Юкса мин консерваторияне дә тәмамлап,

Фото Лидия Әхмәтова архивыннан

аспирантурада да укып, ике баланы ничек үстергән булыр идек.

Ярату ул – ихтирам. Бер-берең белән тормыш авырлыкларын да, шатлыкларын да күтәрергә, кичәргә әзер булу. Ярату ул – сүз сөйләү түгел, ул – гамәл. Рөстәм белән гашыйклык турында әллә ни сөйләшмәдек тә кебек, ничектер бик сөйләнми иде ул чакларда. Хәзер генә мәхәббәт турында артык күп сөйләшә башладылар.

Безнең гаиләдә беркайчан да «татар-керәшен» темасы кузгатылмады. Икебез тарафыннан гына түгел, ә әти-әниләр, каенана-каената тарафыннан да. Бу аларның культурасына бәйле булгандыр, мөгаен. Киресенчә, керәшен җырларын, мирасын халыкка чыгарырга мөмкинлек ачылгач, Рөстәм миңа костюмнар әзерләп, бизәнү әйберләре ясап бирде, китаплардан карап, архивлардан эзләп өйрәнде. Геннадий Макаров һәм студентларым белән бергә оештырган «Сәлам» ансамбле өчен дә тамакса, беләзекләр, хәситәләр, баш киемнәре хәстәрләп бирде.

Керәшен икәнлегемне Казанга килгәч кенә белдем. Безнең заманда бу мәсьәләне артык күтәрми дә иделәр бит. Ә инде соңрак, 90нчы елларда, ул шактый кискенләште. Әмма безгә үзебезнең сакланып калган йолаларыбызны күрсәтергә, ачылмаган мирасыбызны барларга мөмкинлек тә нәкъ шул елларда бирелде. Әтием белән әнием коммунистлар иде, партия кешеләре. Безнең өйдә беркайчан да тәреләр тормады. Әмма өйдә иман бар иде. Мин дә балаларыма, хәзер инде оныкларыма әнә шул иманны сеңдерергә омтылам.

Ул булмаса, мин үземә бу кадәр ышанмас идем. Рөстәмнең, ә хәзер менә балаларымның да ышанычы, таяныч булуы илһамландыра мине. Улым Илдар белән, менә, юбилей концертына клиплар әзерлибез, ул минем – уң кулым. Кызым миңа багышлап җыр язган… үзе хәзер бәбиләр белән утыра, әмма күңелендә иҗат орлыклары бар аның… Иҗатым белән гаиләм бербөтен булып үрелеп бара, шөкер.

Мин эшенә үлеп гашыйк кеше. Көнемне, төнемне онытып эшләргә дә мөмкинмен. Норма, график кебек төшенчәләр – безнең эштә бик юк та бит инде алар. Кайчан башында иҗади процесс туктый – син аны үзең дә белмисең. Һәм, гомумән, туктый аламы ул?! Юктыр… 24 сәгать буена нидер туып тора башта…

Профессияңне яратмасаң, нинди генә уңышка ирешмә, барыбер эшеңнән ләззәт алмыйсың. Мин бу өлкәдә бик бәхетле кеше. Җырларга да яратам, укытырга да. Шулкадәр теләп, йотлыгып укыдым училищеда да, консерваториядә дә, аспирантурада да. Һәр эшемне яратып башкарам. Юкса гомер буена бер урында эшләмәс идем.

Ирем Деринг оркестрында эшли иде. Ниндидер чыгышым вакытында Деринг мине күреп алган да сораштырган Рөстәмнән. «Бу синең хатыныңмы? Килсен әле миңа…» – дигән. Шулай итеп, мин кайчандыр Лундстрем җитәкләгән легендар оркестрга барып эләктем. Хәзер менә филармониянең джаз-оркестрын җитәклим. Бу – зур җаваплылык та, хезмәт тә, бәхет тә.

Джаз минем тормышымда зур роль уйнады. Бу жанр өчен тавышның да үзенчәлекле көйләнешле булуы зарур, башкару стилистикасының да үзенә бер төрле булуы кирәк, хәрәкәтләр, сәхнә пластикасы да үзгә джазда. Узган сезонда зурдан кубып Зур джаз концерты әзерләгәндә, моңарчы булган бөтен багажымны эшкә җиктем. Джаз минем рухыма туры килә. Мин бу жанрда элегрәк тә җырлый идем, хәзер исә үзем җырлар иҗат итәм.

Халык сәхнәдәге ясалмалыктан гарык булды инде. Мин эстрадаегы гына әйтмим, ул – аерым тема. Ә классика белән джаз – ул тере башкару һәм тере энергетика. Башкару техникасы ягыннан зур әзерлек таләп итәләр алар. Шуңа да бу сәнгатьтән чын ләззәт аласың.

Безгә, татарга, джаз хас түгел, дибез, ә нәрсә, опера хас булганмы? Романслар? Рөстәм Яхинның искиткеч матур, моңлы, аһәңле романслары бар. Мин аларны шулкадәр яратып башкарам. Без яшьрәк чакта Мөнирә Хәбибуллина исемле ханым музыкаль тапшырулар бүлеген җитәкли иде «Татарстан» радиосында. Ул безгә, җырчыларга, шалтырата да, әйтә: «Менә, Рөстәм Яхинның бер дә җырланмаган шундый әсәре бар…», «Фасил Әхмәтов яңа җыр китерде…» Без ноталарны алабыз, өйрәнәбез дә, килеп, язылып китәбез. Шуннан ул әсәрләрне радио аша тапшыралар. Юбилей концертымда да башкарырга җыенам ул романсларны.

Без үзебез татарга яраклаштырмасак, ул яраклашмаячак. Бу сәнгатьнең барлык төрләренә дә карый. Әгәр алар югары сәнгать тудырырга мөмкинлек бирә икән, нишләп кулланмаска ди?! Бу безне баета гына бит. Үзеңнеке янына тагын бер матур бизәк килеп өстәлә. Кешенең күңел дөньясы баерак булган саен матур…

Үз эшеңне җиренә җиткереп башкара белсәң генә, син – чын профессионал. Шуңа бүгенге күпчелек җырчыларның урыны сәхнәдә түгел, дип исәплим. Яшьлек белән аңлап җиткермәскә, кыланырга, чытлыкланырга була. Әмма синең академик белемең, осталыгың, тәҗрибәң, талантың бар икән, син инде, беренче чиратта, үзеңне хөрмәт итәргә тиешсең. Ә үзеңә кадәр тамашачыны да хөрмәт итсәң – икеләтә әйбәт.

Безнең оркестр дөньякүләм танылган джазменнар белән эшли. Анатолий Кролл, Игорь Бутман… Ә бит джаз-оркестр – гомумән сирәк күренеш. Аларны Россия буенча да бармак белән генә санарлык. Һәм әлеге джазменнар филармония оркестры коллективын ярата, югары бәяли. Без хәзер тыгыз гастроль графигы белән яшибез. Бик күп мөмкинлекләр булдырылды оркестр өчен. Ә мөмкинлекләр булган җирдә иҗат кайный.

БЕЛЕШМӘ

Лидия Алексей кызы Әхмәтова – ТРның һәм РФнең атказанган артисты, ТРның халык артисты. 1962 елның 17 октябрендә Кайбыч районы Соравыл авылында туа. Казан музыка училищесын, Казан дәүләт консерваториясен, консерватория каршында аспирантураны, Россиянең Гнесиннар исемендәге Музыка академиясен тәмамлый. Педагогика фәннәре кандидаты, профессор. КФУның Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе мөгаллиме. Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең джаз-оркестрының сәнгать җитәкчесе.

PRESSA.RU

Фото: Ната Смирнова

ЗУР ШӘҺӘРЛӘРНЕҢ **ДИВАРЛАРЫ**

Диварлар һәм коймаларны «Здесь был Вася», «Гуля – дура» яки «Маша+Миша=любовь» кебек темалардагы кыек-мыек хәрефләр һәм шуларга охшаш, кайчакта бик үк әдәпле дә булмаган рәсемнәр бизәп торган заманнар узып китте, дисәк, дөреслеккә бик үк туры килмәс. Зур үзгәреш кичерде, дию хаграк булыр. Хәзер мондый төрдәге хисләр ташкыны сәнгатьчә, хәтта талантлы да итеп сурәтләнә. Һәм алар граффити дип атала.

Казанның граффити-урыннары буйлап фотоаппарат белән сәяхәт иткәндә, «Татарстан» эстетик канәгатьлек алып кына калмыйча, әлеге жанр авторларыннан һәм әйдәп баручы белгечләреннән Казанның граффитичылары өчен ни дәрәҗәдә ачык булуы һәм якын арада шәһәр диварлары тагын нинди «әсәрләр» белән бизәләчәге турында белеште.

Автор:
Ната Смирнова

МАТРИЦАНЫ БОЗУ

– Граффити жанрга әверелде инде, – ди безнең экскурсовод Артём Сильвестров, ә аны җирле һәм тирә-юньдәге граффитичылар урам сәнгате буенча экспертка саный. Ә ул үзен «арт-группа-кеше» дип атый. «Татарстан» игътибар белән тыңлый, ә Артём сүзен дәвам итә:

– Заман сәнгатенең һәр жанрындагы кебек үк, монда да аерым стильләр һәм юнәлешләр барлыкка килде: концептуализм, мюрализм, графика, сынлы сәнгать, перформанс һәм башкалар. Аларның бөтенесен легаль түгел юнәлешләргә мәхәббәт – игътибарны җәлеп итүнең әнә шундый төп ысулы берләштерә. Бу жанр «тусовка» да булып тора әле – граффитиның гомуми бэкграунды белән бөтен дөньядагы урам рәссамнары җәмәгатьчелегенә берләшүе.

Артём Казанда бөтен дөньяда танылган граффитистлар барлыгына ышандыра. Тик безнең шәһәрдә аларның эшләре генә азрак.

– Гомумән, урам рәссамы өчен мәйданны дәүләт чикләренә карап бүлү юк. Шуңа да кайчакта шәһәрдә гомерләре буена бер ноктадан икенчесенә сәяхәт итүче мигрант-рәссамнар да яши.

Менә Дамир Бозик – искиткеч позитив кеше. Аңа язу өчен тулы фасадлар бирергә кирәк, хәер, ул аларны болай да эшли бугай инде.

Кайвакытларда, узып барышлый, Казанда Brad Downey, Abel һ.б. була... Өченче ел бездә ике атналык күргәзмә – «Смена»да воркшоп узды, «Цех» дип аталган бу чарага ачык мәйданда заманча концептуализм контекстында эшли торган әйдәп баручы Россия һәм Украина урам рәссамнары килде.

Әле тагын Aeropop командасының иске граффити мәктәбе һәм Малк, Стобит һәм «күзгә күренмәс фронтның» башка яшь, ялкынлы көрәшчеләре кергән яңа бомбинг мәктәбе дә бар.

Тагын үз эченә рок мәктәбен дә сыйдырган граффити-шоп fameflow бар.

Мин үзем 2016 елда KMmSA проектын (Kazan meta-museum of street art) башладым. Урам сәнгатенең Мета-музееn сәнгать әсәре дип санарга мөмкин, анда иң мөһиме – матрицаның бозылуын булдыру.

PRESSA.RU

КАЗАН ПОЗИТИВ ИҖАТКА ТЫНЫЧ КАРЫЙ

Дамир Бозикны «Татарстан» Кремль яны яр буендагы ресторанда менә шундый фантастик шедеврны иҗат итү вакытында очратты.

– Мин гомерем буе рәсем ясыйм, шул исәптән граффитины да. Башта урамнарда, рэп-команда клипларында рәсемнәр күрдем… Аннары үземнең дә ясап карыйсым, баллоннар белән рәсем ясау техникасын үзләштерәсем килде. Мөгаен, бу ничек граффитичы булырга дигән темага классик схемадыр.

– Дамир, син безгә нинди дә булса яшерен граффити-урыннар турында сөйләп бирә алмассыңмы? Бик сирәк кешеләр генә күргән урыннарны?

– Новаторлар станциясе районында, урманда бер урын бар. Анда Казансу яры буйлап барсаң, төрле-төрле арт-рәсемнәр белән капланган кызыклы объектка килеп чыгасың.

– Казан граффитичылары үзләре теләгән һәр урында рәсем ясый аламы? Әллә нинди дә булса чикләүләр бармы?

– Тыныч кына рәсем ясарга мөмкин булган диварлар һәрвакыт бар иде һәм хәзер дә бар. Гомумән, позитив иҗатка, ачык төсләрдәге кызыклы рәсемнәргә барысы да тыныч карый, классик граффити, шрифтлар турында болай әйтеп булмаса да…

– Моңа кадәр ясалганнарга караганда, тагын да глобальрәк ни дә булса иҗат итәсегез киләме?

– Йорт фасадларына нинди дә булса зур күләмле рәсемнәр төшерер идем. Бу проектларны якын арада тормышка ашырырга телим.

PRESSA.RU

ВАНДЛИЗМ БЕРКАЙДА ДА ХУПЛАНМЫЙ

Sly Dog дигән галәм псевдонимын йөрткән Казан стрит-арт-рәссамы киң җәмәгатьчелеккә «Химград» технополисы бинасы фасадындагы утыз метрлы «агачларга лейкадан су сибүче кыз бала» сурәте белән билгеле.

– Граффити турында мин беренче тапкыр 2000 елда, Мәскәүдә яшәгән чагымда белдем, – дип сөйли Sly Dog. – Әмма үземнең бу стильдәге беренче рәсемемне 2010 елда гына, Казанда ясадым. Гади тэглардан башлап, иң катлаулы персонажларга кадәр, төрле стильләрне кулланып эшлим.

– Синеңчә, граффити туу өчен Казанда иң популяр урыннар кайда?
– Миллениум күпере астында.

– Граффитистлар өчен Казан ни дәрәҗәдә ачык?
– Легаль граффити турында әйтсәң, Казан моңа бик яхшы карый һәм әлеге юнәлеш өчен ачык. Ә инде вандализм рәвешендәге граффитига килгәндә, минемчә, ул дөньяда бер җирдә дә хупланмый.

– Рәссамнарга һәм аларның эшләренә карата нинди дә булса техник таләпләр куеламы?
– Юк, ниндидер аерым күнекмәләр кирәкми. Баллон белән рәсем ясау осталыгына өйрәнеп була. Ә гомумән рәсем ясый белү – монысы башка мәсьәлә. Моңа, әлбәттә, өйрәнергә мөмкин, әгәр инде синең талантың бар икән – бусы зур плюс булачак.

– Якын арада шәһәрне синең нинди рәсемең бизәячәк?
– Башыма да китерә алмыйм. Әмма ни дә булса барлыкка киләчәк, анысын төгәл беләм. Идеяләр һәм планнар күп, әлбәттә. Тормышка ашыру белән – сөйләрмен.

ӘЛМӘТТӘГЕ АЛТЫН-КАРА ТӨСЛӘР ЧАГЫЛЫШЫ

Казан граффитичылары – кем ничек булдыра ала – буш мәйданнарга рәсем төшергән арада, Әлмәт исә Санкт-Петербургның Стрит-артны өйрәнү институты белгечләре көче белән сәнгать объектларын оешкан төстә сәнгать әсәрләренә әверелдерә.

2 сентябрьдә Әлмәтнең прогрессив халкы үз территориясендә «Алтын алмалар турында әкиятләр» дигән эре арт-проектны тормышка ашырды.

Аның нигезенә җиде алма турындагы борынгы татар әкияте салынган. Теләсә нинди матди кыйммәтләргә караганда, кеше тормышындагы иң мөһим шатлык – балаларның булуы турындагы әкият ул.

Дөньяның төрле илләреннән җыелган урам рәссамнары Ленин урамындагы зур бинаны, Нефтьчеләр һәм Гафиятуллин урамнарындагы АПТС җылылык үзәге резервуарларын, Яр Чаллы ягыннан кергәндә шәһәрнең үзенчәлекле капкасы булып торган Бигәш урамындагы 123 нче йортны бизәгәннәр. Хәзер бу «капка»ны шәһәрнең төп символы – кара алтынга тәңгәл рәвештә кара-алтын төсмерләрдә сурәтләнгән тарих бизи. Кураторлар советы барлык объектлар өчен бердәм итеп урбанистик кара-алтын концепцияне эшләгән. Белгечләр Харис Якуповның шушы җирләр һәм татар нефть сәнәгате тарихы юнәлешендәге «Татарстан алтыны» картинасына башка күзлектән караганнар. Рәссамнар Әлмәт шәһәре картасын, архив фотографияләрен һәм башка материалларны файдаланган, һәм шулар нигезендә Әлмәтнең 2000 метрга якын буш урынында – парковка бинасының ике диварында яңа әсәр пәйда булган.

Зур масштаблы урам полотнолары – нефтьчеләр башкаласына оригиналь уйланылган мәдәни йөкләнешнең бер өлеше генә әле. Ноябрь аенда Әлмәтнең үткәненнән бүгенге көненә, кәрзиненә Шүрәлене утыртып, велосипедта Тукай килеп керәчәк. Әмма монысы – башка тарих. Сынлы сәнгатькә кагылышлы. ■



«Мин Казанда бик күп яхшы кешеләрне һәм үз китабымны очраттым. Мин ул китаптан чын-чынлап көнләшәм, чөнки ул татар телен белә, ә мин – юк, хәер, бер сүз беләм: рәхмәт!»
Джанни Родари
Казан, 30.07.1969

ДЖАННИ РОДАРИ
КАЗАНДА НИ ЭЗЛӘГӘН?

Редакциябезгә бик үк гадәти булмаган бер китап килеп эләкте. Джанни Родариның татарчага тәрҗемә ителгән «Зәңгәр ук» басмасы. Аның тиңдәшсезлеге нидән гыйбарәт соң? Китап тышлыгына әдип үзе куйган автографта! «Мөгаен, бу берәр үзенчәлекле – әкияти тарих белән бәйледер», – дип уйладык. Ялгышмаганбыз икән.

Автор:
Ольга Туманская

«Мин Казанда бик күп яхшы кешеләрне һәм үз китабымны очраттым. Мин ул китаптан чын-чынлап көнләшәм, чөнки ул татар телен белә, ә мин – юк, хәер, бер сүз беләм: рәхмәт!» дип, каллиграфик матур почерк белән язып куйган Италия әкиятчесе үз туган телендә һәм имзасын да төшергән: Джанни Родари. Шунда ук көне дә, урыны да күрсәтелгән – 1969 елның 30 июле, Казан. Әнә шул рәвешле без, һич көтмәгәндә, атаклы «Суган малай»ны иҗат иткән әдипнең кайчандыр калабызга килгәнлеге хакында белдек.

Сүз уңаеннан, Татарстан китап нәшрияты китапханәсендә аның генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин әлеге басмага очраклы рәвештә тап булган. Автограф тарихын ачыклау үтенече белән ул аны безгә тапшырды. Китапханә киштәсенә ничек килеп эләккән соң ул? Ни кызганыч, моны һичкем аңлата алмады.

КУНАККА – ШЫПЫРТ КЫНА

Китапханә залында утырганда, иске газеталар исен тоям. Вакыт машинасы кебек, алар мине гүя ярты гасыр әүвәлрәк булган елларга алып китә. Совет балаларының бик яраткан язучысы Казан урамнары буйлап йөргәндә, Татарстан мәркәзе ни белән янып яшәгән икән? Газеталарның алгы битләре авыл хуҗалыгы алдынгылары белән тулган – урак өсте бит! Ә мәдәни алхәбәрләргә килгәндә исә, тугандаш Үзбәкстан сәнгате үнкөнләре бик күп санны колачлап алган. Родари турында ник бер сүз булсын...

Аның артыннан журналистлар көтүе ияреп йөрмәгән. Коммунист булса да, барыбер капиталистик дәүләттән бит, бәлки, сере шундадыр? Бәхеткә, без әлеге кунакның сәфәренә кәгазь дәлилләр түгел, ә җанлы шаһитны таба алдык.

ЭЧКЕРСЕЗ ИТАЛЬЯН

Шуны ачыкладым: совет Татарстаны буйлап сәяхәтендә атаклы итальянны язучы Гариф Ахунов озата йөргән. Кызганыч, аннан сораштырып калырга без инде соңардык.

– Алар Казандагы һәм Ленино-Кокушкинодагы Ленин белән бәйле урыннарга бардылар, Ульяновскига да кагылдылар, – дип сөйли язучының кызы, шагыйрә Наилә Ахунова. – Сәфәр барышында бик дуслашырга да өлгерделәр.

«Исемнәребез охшаган: Җанни һәм Гарифҗан бер тамырдан бит», – дип шаяртып алган ул чакта Гариф ага. Җан сүзенең татарча ни аңлатуын әйтеп үткән. Бу Родариның күңеленә хуш килгән.

«Гарифка һәм аның гаиләсенә – иң җылы хисләрем. Без әле генә таныштык һәм инде чын дусларга да әйләндек», – дип итальянча имзалаган әкиятче үзенең «Һөнәрдән нинди ис килә» китабын. Ул Ахуновларның гаилә китапханәсендә саклана.

Ә ул чакта «Зәңгәр ук» кемгә аталган булган соң?

ЮБИЛЕЙГА БҮЛӘК?

«Аның килүен хәтерлим мин, автографы да исемдә», – ди миңа Разил Вәлиев. 1969 елның июлендә аңа әле егерме яшьләр генә тулып киткән булган. Танылган шагыйрь безнең фикер белән килешә: истәлек язуы, мөгаен, шул көннәрдә ярты гасырлык юбилеен бәйрәм иткән Татарстан китап нәшриятының үзенә адреслангандыр.

– Автограф ТАССРның Язучылар берлегендә язылды, – дип аңлата Разил әфәнде. – 1969 елда бу оешма Бауман урамындагы Матбугат йортында урнашкан иде. Татарстан китап нәшрияты да шунда ук. Родарига аның татарча чыгарылган китабын күрсәткәннәрен хәтерлим, ул аны бик шатланып имзалады.

ЛЕНИНО-КОКУШКИНОДАН РЕПОРТАЖ

Танылган татар язучысы, драматург Рабит Батулла кадерләп саклаган фотосурәтне кулына ала. Аклы-каралы фотографиядә 1969 ел июленең нәкъ менә шул көне. Печән өсте вакыты! Костюм кигән, галстуклы Джанни Родари авыл күренешенең иң уртасында. Уңда – Гариф Ахунов, сулда – «Советская Россия» газетасының махсус корреспонденты Марсель Зарипов. Фотода яшь Батулла үзе дә бар – арткы якта, бераз читтәрәк: Родари янына балалар язучысы буларак комсомолның өлкә комитеты чакыруы буенча элэгә ул. Игътибарлы укучылар фотода хатын-кыз сумкасының бер почмагын һәм аксыл пиджакның арткы ягын да шәйли алыр. Әйе, Джанни Родари Казанга үзе генә түгел, ә хатыны Мария-Тереза һәм унбер яшьлек кызы Паола белән килә.

– Ул кыз миңа бик тере һәм кызыксынучан, ә хатыны яшь һәм матур булып күренде, – дип искә ала Рабит Батулла. – Фәкать сәфәр барышында Родари алар белән бик аз сөйләшә, чөнки аның моңа вакыты калмый иде. Ул башы-аягы белән Ленин тарихына чумган иде.

Родари язучы гына түгел, үз илендә танылган журналист та була. «Иң әүвәл, журналист мин», – дип белдерә ул әлеге «коммунистик» маршрут буйлап сәяхәт вакытында «Ульяновская правда» газетасы корреспонденты Лев Рукавишниковка. Казанга, Ленино-Кокушкинога һәм Ульяновскига аны «Паэзе сера» итальян газетасы өчен кумиры турында мәкаләләр сериясе язу теләге алып килә. Шулай итеп язучы безгә... репортаж ясар өчен килгән булып чыкты.

«Ленино-Кокушкинода экскурсовод сөйләгән һәрнәрсәне ул куен дәфтәренә шулкадәр җентекләп, хәтта бик вакчылланып дип тә әйтер идем, язып бара иде», – дип хатирәләрен яңарта Рабит Батулла.

СӘФӘРНЕҢ ЯШЕРЕН МАКСАТЫ

Өйләгә Казанга кайталар. Урамда Родарины танымыйлар, Татар ашлары йортында да таныган кеше табылмый. Атаклы кунакка хезмәт күрсәтү, йомшак кына әйткәндә, «советчарак» була.

– Моның өчен бик борчылдым, – дип күңелендәгесен ача Рабит Батулла. – Ә Родари, күпне күргәндәй, һәрнәрсәне аңлап кабул итә иде. Бер тапкыр да канәгатьсезлеген сиздермәде. Ул бик күзәтүчән һәм бик җитди булды, елмаймый да иде диярлек. Пөхтә һәм гадилек сөя иде. Килеш-килбәтенә карап, язучы димәссең, чып-чын коммунист! Бертөсле соры костюм, галстук...

Итальян кунакка төшке аш итеп татар ризыклары – өчпочмак белән шулпа китерелә. Ә десертка – Ахунов заказы белән – бераз коньяк. Родари аның белән бик мавыкмый, ләкин шулай да әңгәмә җанланып китә.

– Үзенең мәкаләсен язганмы-юкмы, белмим, тик шунысын төгәл әйтә алам, безгә ул моның өчен генә дип килмәде, – дип сөйли Рабит Батулла. – Төшке аш вакытында ул кинәт серен ачып салды: Родари Казанда әкияти илне күрергә өметләнгән икән!

Ул вакытта Джанни Родари Рабит әфәндегә күренекле итальян драматургы Карло Гоццины бик яратуын сөйли. Билгеле булганча, XVIII гасырда иҗат иткән Гоцци үзенең әкияти сюжетларын фольклор элементлары белән үреп биргән.

– Бар иҗади гомерендә язылган ун әсәренең өчесе татар мотивларына нигезләнгән, – дип аңлата Рабит Батулла. – «Бәхетле фәкыйрьләр», «Зөбәйдә», "Турандот"ларны укып карагыз, моңа үзегез дә ышанырсыз. Әмма Карло Гоцци татарлар турында каян белгән? Татар әкиятләрен, шул исәптән патша кызы Турандык турындагысын тәрҗемәдә укыганмы ул, әллә оригиналдамы? Джанни Родарины бу тема кызыксындыра иде. Ул миңа болай диде: «Мин монда

матур-матур мәчетле әкияти илне күрергә теләгән идем!»

Совет Татарстанында Родари андыйны таба алдымы икән, хәбәрем юк. Шунысын гына беләм: ул хәтта гаҗәеп матур Әҗем мәчетен дә күрми китеп барган.

«Татар балаларына, аларның әти-әниләренә чын күңелемнән сәлам юллыйм. Ул балаларның әти-әниләре мин белгән чагында үзләре дә балалар иде. Шулай ук элеккеге һәм яңа татар дусларыма кайнар сәлам!»

ҺИЧ ОНЫТЫЛМАС!

Бу сәфәрдән соң ун ел узгач, Джанни Родари янә Советлар Союзына килә. Мәскәүгә аның белән очрашуга «Яшь ленинчы» газетасы корреспонденты Дәлфәт Маликов бара. Әлеге күрешүнең нәтиҗәсе буларак, бер интервью дөнья күрә. Безгә берсеннән-берсе матур шигырьләре белән таныш шагыйрь Зөлфәт анда Родари турында: «Джанни Родари Италия гражданины гына түгел, Балачак иленең президенты иде. Балачак иленең якты хыяллы, үткен акыллы, шаян һәм уйчан шагыйре иде», – дип яза. Бу очрашуның соңгысы булачагын һичкем уйламый. Ә тиздән газетада кайгылы хәбәр басыла: «Джанни Родари вафат...»

Ул чакта Джанни Родари Зөлфәткә болай ди:

– Казанны, Татарстанны һәрвакыт хәтерлим. Сагынып, яратып хәтерлим. Ә Ленино-Кокушкинода булган көнебезне без, чыннан да, гомергә онытмабыз. (...)

В.И.Ленинның балачак һәм яшьлек эзләрен саклаучы бу як мине чып-чынлап дулкынландырды. Татарстан кешеләре өчен бу төбәкнең бик кадерле урын булуына аз гына да шикләнмим. (...) Шушы истәлекләрне хөрмәтләп саклый белүче кешеләрне ничек яратмыйсың?

Саубуллашыр алдыннан Родари татарстанлыларга соңгы автографын тапшыра: «Татар балаларына, аларның әти-әниләренә чын күңелемнән сәлам юллыйм. Ул балаларның әти-әниләре мин белгән чагында үзләре дә балалар иде. Шулай ук элеккеге һәм яңа татар дусларыма кайнар сәлам!»

Родари «дөньяны әкият коткарачак» дип әйтә торган булган. Аның үз әкиятләре әле хәзер дә балаларыбызның бар дөньясын саклап яши.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ

«Татарстан» журналының
әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кулъязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кулъязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кулъязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кулъязмалар tatarstan@tatmedia.com
электрон тартмасына «КОНКУРСКА»
тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан
2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

PRESSA.RU

Гөлүсә Закирова Апас районының Кече Болгаер авылында туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт педагогика университетына укырга керә һәм татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучысы белгечлеген үзләштерә. «Сабантуй, «Ялкын», «Татарстан», «Гаилә һәм мәктәп» газета-журналларында, «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә эшли.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Тузганак күзләре» исемле хикәяләр җыентыгы, «Бүгенге заман әдәбияты» дәреслек-хрестоматия, сценарийлар җыентыгы һәм республика авылларына багышланган биш китап авторы.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

Гөлүсә Закирова

ӨЗЕЛЕП ТӨШКӘН АЛМАЛАР

Ул көнне урман аланындагы таныш алмагач урынында тирән чокыр күреп, Шәүкәт белән Әкълимә аһ иттеләр. Гадәти көн иде кебек. Җиләкләрнең өлгереп, сабакларыннан җиргә тәгәрәп төшкән чагы. Олы юлдан колач җитмәслек калын имәннәргә ышкылып сулга таба кырык өч адым үткәч, уч төбе хәтле генә аланлык ачыла. Шул аланлыкның нәкъ уртасында ботаклары алмалардан сыгылып торган алмагач үсә. Кем утырткан аны карурман уртасына? Берәрсе ашап калдырган алма төше бәрәкәтле туфракка очрагангмы – белмәссең.

Шәүкәт белән Әкълимәнең үзләре генә белгән яшерен урыннары иде бу. Берсендә шулай авыл яшьләре белән Дубрау күле янына күңел ачарга дип килгәч юлыктылар алар бу урынга. Тик... алмагачны төбе-тамыры белән казып кем алган? Әкълимә калтыранган тәненә тырысын катырак кысты:

– Ни булган ул, Шәүкәт?

– Белмим...

Белмәгәч, белми инде... Җир йоткан дияр идең, юк, арба тәгәрмәче, кичәге яңгырдан ат тоягы эзе калган.

– Кемнәргә кирәк булды икән ул безнең бәхет алмагачы, – дип үрсәләнде кыз. – Җүнлегә түгел бу.

– Урман аланындагы бу алмагачны авылның бер кешесе дә белми дип йөри идем. Эһ, тәмле иде алмалары, сусыл иде... Сине әнигә килен итеп алып кайткач, алмаларын бергә килеп җыярбыз, дигән идем.

Әкълимәнең йөзенә алсулык йөгерде, сулышы капты. «Килен» диме... Шәүкәт белән туй итәсе көннәрен күзаллап ирен чите белән генә елмаеп куйды. Әмма алмалар җыя алмачаклар – алмагач урынында зур итеп ачылган җир авызы кебек тирән чокыр гына ыржая иде.

Вәһибә абыстай исә күңеле нидер сизенепме, кичә җыеп кайткан җиләкләрен селеккәләде. Кипмәгән. Юеш әле. Тагын бераз җилләтергә кирәк. Ак келәттә җиләк, зәңгәр мәтрүшкә, юкә чәчәге исе кушылып, бал чәе исе аңкый. Агач дивар ярыкларыннан тонык кына сирпелгән яктылыкны ярып, күрше малаеның «Мәчет манарасын кисәчәкләр!» дигән сүзе чагылып үтте. Тәүбә, әстәгъфирулла! Булмаганны! Нәрсә дип башны бутый бу малай актыгы, дип келәттән атылып чыкканда, басудан кайтып атын туарган Шәүкәт улын күреп, уеннан кире кайтты.

Шәүкәтнең нигәдер кәефе юк. Әни йөрәге сизми кала димени? Бәгырьләреннән өзеп үстергән балакае. Тугач та суламады Шәүкәте. Кендек әбисе – Миңнурый абыстай алай да селеккәләде, болай да... Зәңгәрләнеп килгән сабый тавыш бирергә ашыкмады. Мендәргә сузып салган нарасый өстенә ак яулык капладылар. Вәһибәнең тулгак газаплары баласының җансыз гәүдәсен күрүгә ыңгырашуга әйләнде. Берничә минуттан ыңгырашу тавышына бала елавы кушылды. Хак Тәгалә аңа җан бирде! Заһидулла мулла сабыйга Шәүкәт дип исем кушты. Ә менә Вәһибәнең баласы тугандагы куркуы күңеленә мәңгелек җой булып тегелде. Дүрт яшенә кадәр имидән аермады. Абынса да, торгызырга ашыкты. Инде менә үсеп җиткән улына сөеп карап басып тора. Нигә кәефе юк бәгырькәенең?

– Нихәл, улым?

– Ару гына әле. Әни? Авылда бер-бер хәл юктыр бит?

– Ай Аллам, юктыр... – Вәһибә абыстай, күрше малаеннан ишетеп калган сүзләрне әйтеп тормаска булды. Бала-чага ни сөйләмәс.

Урам башында тузан купты. Тарантасына басып, силсәвит Ярми атын куалый икән. Каз бәбкәләре, тавыклар пыр килеп, ян-якка сибелеп калды.

– Яңгыр булыр, ахры. Дубрау өстендә болытлар куера. Урман ягыннан килгән болыт җүнлегә булмый. Хәтәр булырга охшаган... – дип сөйләнгән әнисенә җавап биреп тормады Шәүкәт. Дубрау урманындагы икесе генә белгән алмагачның юкка чыгуы исенә төшеп, эчтән куырылып куйды.

Вәһибә суган сызгыртып аш пешерде бүген. Кыр суганын шулай Дубрау урманыннан җыеп кайта да, мичтә киптереп төя. Шуны туңмайда кыздырып суга салып аш итсәң, катык катып ашарга бик ярата улы. Тәмлүшкә пешергән саен кендек әбисе – Миңнурый абыстайга да өлеш чыгара ул. Элеккедән килгән гадәт. Бер очтан Заһидулла хәзрәтнең дә хәлен белешер.

Мәчет кырыннан үткәндә көндез малайлар әйткән сүзне искә алып, тыны кысылды хатынның. Аллаһ йортына утыз сигезнең көзендә үк йозак элделәр инде. Мулласы – Салих хәзрәтне төрмәгә утырттылар. Азанчы Нургаязны карт анасы, биш баласы белән Себергә сөрделәр. Әмма мәчет манарасындагы ай өмет уты кебек җылытып тора иде әле. Бүген, имеш, кызыл авызлар мәчет манарасын кисәчәк! Булмаганны...

Тыкрыкны борылуга шап итеп туктап калды Вәһибә. Хәзрәт йорты капкасыннан, атылып диярлек, күн курткалы Идрис атылып чыкты.

Капканың эчке ягыннан атасының сүзләре яңгырап ишетелде.

– Чыгып китәсең икән, кайтып кирәсе булма! Бу йортка юлны онытасың, малай актыгы, белеп тор!

Идрис ашыкмый гына кесәсеннән кызыл яулыгын чыгарып, муенына таслап бәйләп куйды. Атасы сүзләрен ул ишетми дә иде шикелле...

– Улым, Аллаһ хакы өчен сорыйм, йөрмә шул шайтан туенда... – Капка каршына чыккан Заһидулланың ак түбәтәе улының аякларына таба иелгән иде. – Йөрмә денсезләр арасында, улым, каһәр җыйма...

Идрис аякларына сарылган атасын этеп, җирдәге арканнарны аркасына асты. Аннан җәлт адымнар белән силсәвиткә таба китеп барды. Өй каршындагы чирәмнәрне йолкып елаган атага карау кызганыч иде. Ахырдан Заһидулла йодрыкларын төйнәде һәм күз яшьләре аша улына кычкырып салды:

– Кайтып кирәсе булма, малай актыгы! Атаң исемен онытт, анаңны күзләрең күрмәсен!

Куркуыннан абынып киткән Вәһибәнең кулыннан кайнар ашы түгелде. Пешкән бармакларын түгел, карт белән карчыкны җәлләп йөрәге әрнеде аның. Йөрәге белән елап, күршеләре – мөгаллим Әхәт рәшәткәсенә сөялде. Койма ярыгыннан күзе төшеп, имәнеп киттеме, әллә кычыткан чактымы – белмәссең: кичә генә чүп үләне үскән бакчада әллә кайдан гына алмагач пәйда булган иде.

PRESSA.RU

***

Дубрау ягыннан килгән болыт авылны каплады. Әмма яңгыр яварга ашыкмады. Җил, әрсезләнеп, тупылларның яшел яфракларын йолкыды, салам түбәләрне туздырды. Такта ярыкларыннан ысылдап, Вәһибә абыстайның кипми интектергән җиләкләрен туздырды. Борын аслары юешләнгән малай-шалай Заһидулла абзары артына тезелешкән. Силсәвит каршына яхшы атларда килгән кешеләр чыкканын көтеп күпме басып торасы булыр? Габдулла кәнсәләр тәрәзәсеннән кунак сүзен ишетеп килгән. «Бүген кич Ромодан урысларын чакыртканнар! Манараны кисәчәкләр!» – диде ул. Инде кояш Шәгаләм бабайлар абзары артына чумды, бернинди хәрәкәт булмаганга малайларның да эче поша башлаган иде. Әнә берсе, Габдулланы үчекли үк башлады:

– Колагыңны әйтер идем инде... Дөрес ишетмәгәнсеңдер. Бибайдагы мәчетнең манарасын кисәбез дип сүләшкәндер ул райком кешеләре.

– Ы-ы, шулайдыр име, – дип үртәлеп, борынын еш-еш тарта-тарта сөйләп китте малай. – Алпардагы мәчетне дә шулай кич кискәннәр, бик беләсең килсә. Кеше кайтып киткәнне, халык тынычланганны көтә алар. Алайса ник Ромодан урыслары силсәвиттә аракы эчеп утыра? Хәзер киләчәкләр дә эһ иткәнче сөйрәп тә төшерәчәкләр манараны.

Бер кавем башларын иеп, тын гына утырдылар. Ә җил тынырга уйламады да. – Малайлар, мин бу хакта бабайга да әйттем, – дип сүз алды Рәүф. – Үз башларына йориләр. Ходай Тәгаләнең күңеле иркен. Әмма ачуы да яман!» – диде.

– Юкка аптыраткансың син аны, бәлкем берәү дә тимәс. Кемнең кулы барсын инде шул йортны җимерергә? – диде Галимҗан.

– Салих бабай белән Нургаяз бабай юкка чыкты бит, сорап тормадылар.

Габдулла бу сүзләрне үзе ишетерлек кенә әйтте ахры... Бала-чаганың борыны тәмам җебегән, мышык-мышык борын тарткан тавыш кына ишетелә. Шулчак Рәүф кычкырып җибәрде:

– Малайлар!!! Килделәр!!! Әнә берәү мәчет манарасына менеп бара.

Малайлар, җилне узып, мәчеткә якынрак йөгерде.

***

Мәчет манарасы да нидер сизенде ахры, калын арканнар белән ураганда авыр гына шыгырдап куйды. Шулчак күкрәгенә кулын куйган Шәгаләм карт халык алдына чыгып басты.

– Авылдашлар, ни эшләвегез бу? – диде ул. – Күрәләтә торып, иман йортыбызны җимерергә ирек бирәбезме?

Шул сүз генә кирәк булган ахры, халык бик шаулаша башлады. Сүнеп барган иман уянамы, әнә мәчет тирәсенә тере дивар булып басучылар саны да арта, авыл активы да дулкынлана башлады. Партия идарәсе каршында ни дип җавап бирәсе? Совет власте чараларына аяк чалган дин калдыкларын юк итә алмаган өчен төрмәдә череп ятасымы? Йөрәк янындагы кәчтүм кесәсенә кызыл тасма такккан Идрис күн итекләре белән җәлт кенә кызыл тарантаска менеп басты.

– Авылдашлар! Совет власте сезне бәхетле итәр өчен барын да эшли. Коммунизмга бергә атлыйк! Анда – муллык, иркенлек һәм дөнья рәхәте! Теге дөньяда вәгъдә ителгән булыр-булмас җәннәтне бу дөньяда күрергә теләгегез юкмыни? Мәчетләр – искелек калдыгы. Алар коммунизм төзү юлында киртә булып тора. Без Аллага сукырларча ышану кебек чеп-чи ялганны юк итеп, дөрес идеаллар белән яшәргә тиеш! Яшәсен Совет власте! Яшәсен иптәш Сталин! Карга авылы коммунизм юлында! Ур-ра!!! Ур-ра!!!

«Ур-ра!» кычкырган саен, совет ялагайлары кызыл әләмнәрне югарырак күтәрде. Кемдер ләхәүләсен укыды. Ярсыган халык алдына мөгаллим Әхәт Туктамышев чыгып басты.

– Авылдашлар! Болар барысы да вакытлыча гына, – дип сүз алды ул.

– Нәрсә, яңа мәчет төзерләр, димәкче буласыңмы әллә? – дип тонык кына сүз ишетелде. Хәлиулла диндар кеше булмаса да, кызма холыклы. Яулык чите белән битен каплаган хатыны терсәге белән төрткәч, ул да тынып калды.

– Булыр, вакыты җиткәч, анысын да төзерләр. Тик үзегез күреп торасыз, муллаларыбызны төрмәгә ябып, сөргенгә җибәргәннән бирле, йорт буш тора. Язын чәчүлек орлыклары салдыларммы? Шулай түгелмени?

Халык шаулашып алды. Мәчет ишегенә йозак эленсә дә, халык аны карауны туктатмаган, ел саен салымнарны капларга һәр хуҗалыктан мәчет хисабына акча да җыела иде. Туктамышев үз сүзен дәвам итте:

– Менә һәркайсыгызның балалары үсеп килә. Аларга укырга кирәк, әлифне таяк дип тә белмәгәннәр берни эшли алмый хәзер.

– Муллаларыбызны нигә юк иттеләр соң? Без укыдык әле үзләрендә, укый торгач, кул куярга өйрәндек, хатын-кызлар абыстайда белем алды. Ник алып киттеләр аларны? – Хәлиулланың бу сүзеннән хатыны гына түгел, шактый кеше куырылып килде. Үз башына кылана бу дип, хатыны аны кеше арасына сөйрәде. Әхәт сүзне янә мәктәп ягына борырга ашыкты:

– Җәмәгать, авылда бу көнгә кадәр мәктәп бинасы юк. Аны төзер өчен кайсыгызның авызыннан ризыгын өзеп бирәсе килә? Менә-менә... берәүнең үзеннән артмый тиеннәре. Ә белемле булу кирәк. Заман шуны таләп итә, иптәш Сталин да бу хакта кисәтә. Без бары укып кына яңа заман төзи алачакбыз! Шуңа күрә бу мәчет бинасында үз балаларыбызны укытыйк!

Халык тагын шаулашып алды. Ул арада сакаллы урыс тәмәке төпчеген мәчет нигезенә атты да түбәгә сикереп менде. Күз ачып йомганчы манараны аркан белән урап алды да әйбәтләп төенләп куйды. Аннары:

– Давай, брать! Начали!!! – дип сузып җибәрде.

Аның сүзләрен көтеп торган бер төркем тавышы кичке эңгер-меңгергә таралды:

– Ха, берем!!! Ха, берем!!! Ха, берем!!!

Мәчет манарасы, авыр шыгырдап, сәвитчеләр каршына егылып төште. Тузан купты, хатын-кызлар акырышып еларга тотынды, мәчет картлары кычкырып бисмилласын укыды. Мәчет түбәсенә Заһидулла хәзрәт улы Идрис кызыл әләм кадаклады. Ә җил елый-елый «Хабирун!», «Хабирун!», «Хабирун!» – дип улады...

***

Ике елдан Әкълимә килен булып төште. Сугыштан кара кәгазе килгән Шәүкәтне сагынып озаклап еларга җай чыкмады – фронтта яраланып демобилизацияләнгән Идрис күн курткасы белән урады да, күтәреп, өенә алып кайтты. Шулай итеп, Әкълимә – мәчет манарасы кискән көнне Заһидулла этисеннән ваз кичкән Идриска кияүгә чыгып, Туктамышева булды да куйды. Язмышына күнде, әмма бакчага чыгып алма өзеп капкан саен, яшьләрен тыя алмады. Өйдәгеләр моны урман алмагачының кыргыйлана баруына юрадылар...



ФОРМАТКА ТУРЫ КИЛМӘГӘН ШӘХЕСЛӘР БЕЛӘН «ФОРМАТТАН ТЫШ» СӨЙЛӘШҮЛӘР

Сентябрь ае, традицион рәвештә, Казан халкын кино дөньясына күмелергә чакыра. Мөселман кинофестивале уздырыла башлаганнан бирле бу шулай. Кызыл келәмнәр, алар буйлап атлаучы дөнья кинематографиясе һәм берән-сәрән үзебезнең йолдызлар, алтын йөгертелгән сыннар, шау-шулы масштаблы тамашалар – барысы да бар. Рәсми булмаса да, «кино ае» буларак кабул ителгән сентябрьнең китап киштәсен шуңа, контрастлы, әмма рухлары охшаш ике режиссерга, дөресрәге, алар турындагы китапларга багышларга булдык.

Автор:
Луиза Янсуар

«Азбука-классика» нәшриятының «Арт-хаус» сериясе XX гасыр сәнгатендә культ дәрәҗәсендә йөргән шәхесләргә, һәм, әйтергә кирәк, нигездә нонконформистларга багышланган. Басмаларның нигезен нәкъ менә режиссерлар тәшкил итә. Кино сәнгатендә үз юнәлешен һәм эстетикасын булдырган һәм, инде исеменнән үк аңлашылганча, Голливуд стандартларына җавап бирмичә, үз стандартларын булдырган режиссерлар. Алар кулланган алымнар, ысуллар, дөньяга карашларын формалаштырган вакыйгалар турында бара китапларда сүз. Джим Джармуш, Вуди Аллен, Дэвид Линч, Ларс фон Триер, Квентин Тарантино, Педро Альмодовар… «Арт-хаус» сериясе китаплары нигездә интервью жанрында эшләнгән, һәм нәкъ менә шул жанр тәкъдим иткән мөмкинлекләре белән кызыклы да алар. Чөнки, интервью тыңлаучының да, сөйләүченең дә телен чишә, гадәти тематик кысалардан чыгарга мөмкинлек тудыра. Китап авторлары режиссерларны камера астына утыртып куйгандай итә. Пленкада – эре планда – алар. Телиләрме, теләмиләрме… Барлык күркәм һәм бик үк күркәм булмаган яклары, фобияләре, «авырткан урыннары» белән…

Бүгенге цивилизациядәге тенденцияләрне төрле ракурстан чагылдырган икаүгә тукталам. Берсе – дин, иман, инану кебек кыйммәтләргә йөз тоткан «идеаль» каһарманнарның пастораль ясалмалыкта кылган гамәлләрен, ул гамәлләрнең җимергеч көчкә китерүен микроскоп аша күрсәтүче Ларс фон Триер. Икенчесе – җимергеч, канкойгыч вакыйгалар эчендә торып та, чистарынуга, иманга килү мөмкинлеген алга сөргән гангстерлар, кеше үтерүчеләр, зимагурлар исеменнән чордашларына сөрән салучы Квентин Тарантино.



«МИН АЛЛА ДА, КҮРӘЗӘЧЕ ДӘ ТҮГЕЛ, УЛ ЕГЕТЛӘРНЕҢ НИ КЫЛАСЫН ҮЗЕМ ДӘ БЕЛМИМ…»

Джеральд Пири. «Квентин Тарантино. Интервью».

Киң катлам тамашачыга аны режиссер, сценарист буларак танытткан «Бешеные псы» фильмы прокатка чыккач, Тарантино бер интервьюсында шулай ди. Ул үзенең кара юморын «висельный юмор» дип тәгаенләүне кулай күрә. Беренче карашка, сүзләре җимергеч энергетикалы булып тоела, сискәндергеч яңгырый, әмма аннары, иҗатчының үз заманы көзгесе икәнлеген искә төшерәсең дә, ваемлап аласың: ә ул безгә бүгенгебезнең каршылыкларын, һәм дә юмор белән фаҗиганең янәшә яшәгәнлеген күрсәтер өчен җибәрелгән зат түгелме икән соң? Менә аның үз аңлатмасы:

«Для меня насилие – чисто эстетическая категория. Я не пытаюсь проповедовать никакой морали или выступать с каким-либо посланием, но, несмотря на всю дикость происходящего в моих фильмах, я думаю, они обычно приводят к определенным нравственным выводам».

Тарантино турында: «Булмаса, аны уйлап чыгарырга кирәк булыр иде», – диләр. 90 нчы еллар кинематографына ул, әйтерсең, Америка боевикларында сурәтләнгән, көн-төн атыш барган урамнардан, ә бәлки, хәтта Американың 30–40 нчы елларын гәүдәләндергән нуар пленкаларыннан атлап кергән. Хәер, атлап керүе, асылда, видеопрокат салоныннан була аның. 1922 елда, «Санденс» кинофестиваленә килгәндә, 29 яшьлек Тарантино Манхэттен-Бичның видеопрокат салонындагы 5 еллык стажы белән чын-чынлап мактана ала. Монда ул – сату эше арасында – Европа шедеврларын да, Голливудның жанрлы картиналарын да, Көнбатыш экзотикасын да бар колачына үзләштереп өлгерә. Парижның 60 нчы еллардагы кино сәнгатенә гашыйклык кичерә. Һәм әңгәмәдәше Джеральд Пири әйтүенчә, Тарантиноның яраткан сүзе дә яшүсмерләр жаргоныннан – «круто» була. «Хәер, кыяфәте буенча да шундый иде ул», – дип ассызыклый Пири. Әйе, үз чорындагы вакыйгаларны пленка аша тамашачыга җиткергәндә

PRESSA.RU

дә әнә шул «кәттәлек» статусын саклый, үсмерлеккә хас максимализм, кайнарлык, җимергеч көчне эшкә җигә ул. Бу – Тарантино алымы. Тарантино мөһере. Монда режиссерның яше дә, тормыш тәҗрибәсе дә беренчел түгел. Өслүбендә бөтен эш.

Аны «камера ярдәмендә төшерүче түгел, ә атучы режиссерлар буынына нигез салучы» дип исәплиләр. Соңыннан бу гыйбарәне Тарантиноның дусты Роберт Родригеска карата куллана башладылар. Әмма биредә сүз, бу «кәттә егетләр» ничек кенә чор эталоны булмасын, «Терминатор» рухындагы киң прокат фильмнары эстетикасы хакында бармый. Тарантино Америка киносына экшн белән бергә фәлсәфә, һәм эстетик тирәнлекне кайтаручы режиссер. Өстәвенә, нуарга хас менә дигән кара юмор белән шул ук нуар романтизмын билгеләүче нечкә-нәфис иронияне дә.

Криминал жанрының шактый коры, стандарт кысаларын киңәйтеп, аны яңа мифология белән баета Тарантино. Һәм, гаҗәеп рәвештә органик, үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган автор киносы белән мейнстрим кушылмасы хасил була. Брутал ганстерлар һәм философлар, романтиклар, ягъни, кушып булмый торган ингредиентлар – болар Тарантиноның фишкасы. Бу коктейльнең үзенә җәлеп итә торган тәмен хасил итүче, Тарантино эстетикасының үзәгендә торучы Джон Траволта, Брюс Уиллис, Самюэль Джексон һ.б. актерларны гына күздән кичерик. Тарантиноның музасы – Ума Турман турында әйтеп тору да артыктыр. Хатын-кыз эталонының Голливуд форматы – Мэрилин Монрога үзенең шәхси эталонын – Марлен Дитрихны каршы куя ул. Ә Марлен Дитрих, беләбез, Өченче рейх башлыклары өчен «фәрештә» исәбендә йөргән, Голливудка Европа киносы минимализмын һәм психологик тыенкылыгын алып килгән каршылыклы персонаж. Уманың героинясы – Невеста да – бүгенге чорның кайдадыр нечкә-нәфис була ала торган, кайдадыр кунг-фу алымнары белән җавап кайтарырга да күп сорамаучы бер өлгесе.

Тарантино хәтердә кала торган диалоглар һәм характерлар режиссеры. Ул моны үзе дә еш ассызыклый: «Чәчләрен, гәүдәләрен, күз төсләрен сценарийда язып утыру кирәкми, диалог башлана һәм шунда һәммәсе дә ачыла», – ди ул. Тагын болай дип кабатлый: «Минем фильмнарымдагы куркыныч хәлләр гадәти тере кешеләр белән булганга, хәвефләндерә. Мин мультфильмнар төшерүче түгел, боевиклар бүлегендә дә таба алмассыз минем фильмнарны. Гәрчә аларны анда еш кына урнаштырсалар да».

Тарантино һәм Пири әңгәмәләре эчке энергетикасы, хәтта ки агрессиясе белән дә, корылышы ягыннан да – гаять үзенчәлекле. Әңгәмәдәш белән аның герое – күпмедер дәрәҗәдә антиподлар, кайсыдыр бер моментларда, көтмәгәндә, криминал дөньясындагы кебек, җинаятьтәшләр дә:

– Я не Бог и не провидец. Я не знаю, что эти парни собираются делать. Я предлагаю обстоятельства, и они начинают говорить друг с другом, а я записываю… Я думаю, что мои персонажи точно так же опускаются до исступленной жестокости, как и поднимаются до истовой человечности.

Күз алдына «Криминальное чтиво» белән «Убить Билла» полотнолары килеп баса. Опералары, дияргә дә мөмкиндер хәтта. Әлбәттә, экранда барган трэшны исәпкә алып. Монда режиссерның җәмгыятьтәге җитлеккән һәм сызланып торган сорауларга җавап эзләве көн кебек ачык. Әмма ул, барыбер дә шул үсмерләрчә образда калып: «Мин «Невеста»ны төшергәндә ләззәт алдым, шул җитә», – диюне кулайрак күрә. Әйе, бу Брюс Ли шәхесенә дан җырлау да, әйе бу Америкага пародия дә, әйе, бу хулиганлык та, әйе, бу Көнбатыш культурасына стилизация дә. Ә мәгънәсе, диярга ашыгабыз. «Кирәкми, мәгънә эзләмәгез», – дияр иде Тарантино үзе. Һәм без, ниһаять, сүзенә колак салып, эзләмибез, бары аның үзенә шәрехләргә мөмкинлек кенә калдырабыз:

«Большие Идеи портят кино. В кино самое главное – сделать хорошее кино. И если в процессе работы тебе в голову придет идея, это отлично. И это не должна быть Большая Идея, это должна быть маленькая идея, из которой каждый вынесет что-то свое».

«КИНО, БОТИНКАГА ЭЛӘККӘН ТАШ КЕБЕК, УҢАЙСЫЗЛЫК ТУДЫРЫРГА ТИЕШ…»

Ларс фон Триер. Интервью: Беседы со Стигом Бьоркманом

Провокатор буларак дан казанган Ларс фон Триер, ни гаҗәп, Стиг Бьоркман белән үзен шактый әдәпле һәм тәртипле тотарга мәҗбүр, дияр идем. Алай гына да түгел, интервьюларында журналистларны мыскыллап, ирония белән җавап бирүдән беркайчан да тайчанмаган Триер биредә балачагы, куркулары, депрессияләре турында да шактый ачылып, дусларча һәм якыннарча сөйләшеп утыра. Моңа, бәлки, Бьоркманның абруе да сәбәпчедер. Чөнки китапның, ягъни интервьюларның башында ук Триер чорыбызның икенче бер культ-режиссеры – Вуди Аллен турында Бьоркман әзерләгән басманы искә ала. Шунда аның үзе турындагы китап идеясенә мөнәсәбәте дә чагылып китә – мин моны төрттерү, ирония маскасы артына яшеренеп бетә алмаган горурлык дияр идем.

Форматка туры килми торган режиссер белән «форматтан тыш» сөйләшү – китапның архитектоникасы шундыйрак. Аның 10 ел дәвамындагы очрашу-әң-

гәмәләр нәтиҗәсе булуын да әйтергә кирәктер. Һәм бу бик яхшы сизелә. Бьоркман куйган сорауларның тирәнлегендә һәм кискенлегендә дә, Триерның җавапларындагы турылыгында һәм каршылыгында да. Нәкъ менә шул каршылыклары белән кызыклы китап. Бьоркман әңгәмәләрнең әлеге каршылыгын махсус калдыргандыр, дип уйлыйм, чөнки, шул рәвешле ул безгә, Триер үз фильмнарында геройларының үсеш-үзгәрешен күрсәткәндәй, режиссерның метаморфозаларын да күрсәтә. Баштарак алар, яхшы танышлардай сөйләшәләр. Һәм темаларның менә мондыйлары өстенлек итә:

– Но почему тебе вообще пришло в голову взять такую аристократическую фамилию? И когда ты так начал подписываться постоянно?
– Году в семьдесят пятом. Хотя можно сказать, что эта история началась много раньше – во времена моего деда Свена Триера. В Германии его всегда величали «герр фон Триер»... В середине семидесятых я начитался Стриндберга, ну и конечно Ницше. Когда со Стриндбергом случилась депрессия в Париже – ее потом назвали «инфернальным кризисом» – он стал подписывать свои письма «Rex», то есть «Король». И мне показалось, что это очень забавно.

Тора-бара алар Триерның «фирма стиле»н тәшкил иткән "яшерен" алымнарны барлап чыгалар, кино сәнгатендә аңа кемнәрнең аеруча зур тәэсир ясаганын «тартып чыгаралар», геннар, нәселдәнлек, гаилә, андагы кыйммәтләр турында сөйләшәләр. Һәм җай гына Триерның үзендәге фобияләр темасына килеп төртеләләр:

– Разумеется, я могу извлечь некоторую пользу из моих фобий. Человек, который боится темноты, скорее всего, сделает более качественный ужастик. Но большинство страхов просто превращает тебя в невротика. В настоящий момент я так зациклен на себе, что воображаю собственную смерть по пять-шесть раз на дню... В страхе заложена такая сила, что с ее помощью можно было бы взобраться на гору или пуститься в путешествие. Но страх ничего не дает взамен, хотя и отнимает у меня массу сил, пота и слез, когда я продираюсь сквозь мучительную бессонную ночь. А когда наступает утро, все исчезает. Не остается никаких видимых доказательств того, что я пережил. Очень жалкое состояние.
– Ты можешь стать бессмертным благодаря своим фильмам...
– Я могу стать бессмертным благодаря моим фильмам... (Смеется.) А сейчас что я с этого буду иметь?

Асылда, теләсә кайсы иҗатчы әнә шул психологик үзенчәлекләре белән кызыклы да. Нәкъ менә шулар фильмнарында тормышның барлык катламнарын ачып күрсәтергә мөмкинлек бирә дә режиссерларга. Без, бәлки, Хичкок гение булмаса, курку турында бүген болай ачылып сөйли дә алмас идек. Триер да чыгарма була алмый бу очракта. Һәм, алай гына да түгел, ул үзендәге невротизмны беркадәр «иркәли» дә кебек тоела вакыт-вакыт. Монысы да аңлашыла. Шул невротизм аңа, үзрефлексия аша, чорының невротизмына тоташырга мөмкинлек бирә, чөнки.

«Я очень горжусь своим статусом персоны нон грата Каннского фестиваля и чувствую, что он полностью мне подходит. Кажется, в истории Канн это единственный случай», – ди иде еш кына журналистларга биргән интервьюларында Ларс фон Триер 2011–2012 елларда. Аның тирәсендә җәнҗаллар була һәм хәл ителә тора, ә кинолары – төшерелә. Соңгы фильмы – «Нимфоманка» – безгә Триерның һаман да бары тик үзенә генә тугры булып калуын исбатлады. Һәм әнә шуның белән ихтирамга лаек та ул – караш, фикерләреннән тайпылмавы, принципларыннан йөз чөермәве һәм, әлбәттә инде, фильмнары аша безнең җәмгыятьнең кая таба йөз тотуын, һич тә курыкмыйча, һәм гаилә, һәм социумда хөкем сөргән авыру күзәнәкләр аша чагылдыра белүе белән. Әйе, ул караңгыдан һәм онкологиядән, иртә үлемнән курка. Әмма ул туры итеп, кистереп, дөресен әйтүдән курыкмый. Бәлки, бу кыйммәтрәктер?

«Политкорректность – худшее, что дала миру Америка. Именно политкорректность убила честную дискуссию, потому что многие люди сегодня предпочитают молчать, боясь быть обвиненными».

Ретроспектива ясап, дөньякүләм һәлакәт куркынычы, дини нигездәге катастрофалар турында бәян иткән «Меланхолия» белән «Антихрист»ларга кадәр үк төшерелгән, инде заман классикасы саналган картиналарына кайтсак... без Триерның әле шул чакта ук дөньяга ни дәрәҗәдә аек бәя биргәнлеген күрә алабыз. «США – страна возможностей» дигән циклның беренче фильмы «Догвилль» үк күтәргән теманың хәл ителеш ракурсы, һәм төшерү алымнары белән дә – моңарчы булмаган яңалык.

Социал-демократ һәм коммунист гаиләсендә тәрбияләнгән Триер өчен бүгенге социумны әнә шул кисемтәдә – Югарыдан торып карау – гаять кызыклы булган, күрәсең. Асылда бит, «Догвилль»да да, «Мандерлей»да да сүз, геройлары XX гасыр башында яшәсә дә, әле һаман колбиләүчелек калдыклары, көчләү, садизм элементлары сакланып калган Америка прерияләрендәге ташландык, вак шәһәрләр турында бармый. Триер Швециядәге олы бер фабрика цехы эчендәге караңгы пространствода кара идәнгә акбур белән йортлар, эскәмия, караватлар, шкафлар сызып, шулай ук сурәте ясалып куелган Моисей кушаматлы этне (аның исеме юкка гына андый түгеллеген һәммәбез дә аңлый, әлбәттә) шәһәр сагына урнаштырып, Америка стандартын өлге итеп алган, һәм, «Титаник» айсбергка томырылгандай, котылгысыз рәвештә үзен һәлакәткә алып барган тулы бер цивилизация турында сүз йөртә.

Без әле һаман да үзебездәге иблисләрне җиңә алмыйбыз, ди ул. Һәм, ахыр чиктә, Грейс гангстер әтисенең ялтырап торган машинасына кереп утырып: «Әйе, дөнья бер шәһәргә кимрәк булса, бернинди дә зыян күрмәячәк. Һәм ул шәһәр – Догвилль», – дигәндә, без, йөрәгебез жу итеп, янәшәбездә генә барган канкойгыч вакыйгаларны, үзебезнең ваемсызлыкны, күз йомучанлыкны... искә төшерәбез дә, «монстр-режиссер»ның герое авызыннан яңгыраган репликада сүзнең асылда җир шары һәм аның барлык кешеләре турында барганлыгын аңлыйбыз.

Ә Триер исә, ваемсыз һәм ярым иронияле, ярым моңсу рәвештә, кайдадыр, диванга сеңеп,тыныч кына интервью бирүен дәвам итә:

«Я был воспитан с мыслью не верить ни в добро, ни в зло. А в то, что все имеет свое объяснение. Не существует асболютных крайностей вроде добра и зла, есть ошибки и недоразумения». ■

PRESSA.RU

Без Татарстан риваятьләрен җыюыбызны дәвам итәбез, ни дисәң дә, безнең якларда алар бик күп таралган. Яшел Үзән районы да бай андыйларга. Һәм менә әлеге матур җирләрдән – матур бер риваять.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: КЫЗЫЛ ЯР КӨТҮЧЕСЕ

Яшел Үзән районында Васильево тимер юл станциясеннән ерак та түгел Красный Яр дигән авыл бар. Кайчандыр моннан каторжаннарны Себергә куа торган олы юл (тракт) узган. Бервакыт зынҗырлы тоткыннарның хәсрәтле делегациясе авыл янында ял итәргә тукталган. Каторжаннарны саклаучы солдатлар, төенчекләрен чишеп, сыйланырга керешкән, ә бичара тоткыннар яшел чирәмгә утырып ял итә алуларына да шат булган. Ерак та түгел авыл баеның көтүен көткән яшь малай шунда бер колагына сыңар алка таккан алҗыган казакның бер сынык икмәк соравын ишетеп алган. Һәм, солдатларга сиздермичә генә, ризыклы төенчеген бөтенләе белән аңа тапшырган. Ә ул каторжан – Пугачёв бунтында катнашкан казак есаулы – малайга кыю атаман гаскәрләре талап җыйган хәзинәнең яшерелгән урынын әйткән. Серне ачканда, есаул аннан бер генә нәрсә әйткән: әгәр каторгадан кача алса, хәзинәнең бер өлешен алыр өчен монда әйләнеп киләчәк.

Тоткыннарны Себер ягына алып киткәннәр, ә көтүче малай Пугачёв есаулы күрсәткән хәзинәне чыннан да эзләп тапкан, байдан үзенә ирек сатып алган һәм сәүдә эшен башлап җибәргән. Һәм ул көтүченең фамилиясе – Атлашкин – шул вакыттан күренекле сәүдәгәрләр исемлегенә кергән.

Бу риваятьтә нинди дә булса дөреслек бардырмы-юктырмы – Зеленодольск халкы моны ант итеп раслый алмый. Әмма, сакланып калган сату-алу документына караганда, Одинцово утарының (Красный Яр элек шулай йөртелгән) 1881 елда отставкадагы полковник Осокиннан Красный Ярдан берничә чакрым ераклыктагы мари авылы Кожласолада яшәүче, икенче гильдия сәүдәгәр Михаил Атлашкин тарафыннан сатып алынганы билгеле. Бәлки, ул сәүдәгәр чыннан да риваятьтә сөйләнгән көтүче малайның буыны булгандыр. Чөнки, ул утарны сатып алганнан соң, биредә эшләр югары үрләп киткән: ике катлы бай йортын яңартып төзегәннәр, аның ярымподвалында сәүдәгәр зур булмаган чыпта фабрикасы ачкан, аннан товарлар ташу өчен каплар һәм капчыклар теккәннәр.

Атлашкинның Идел буйлап ашлык һәм агач ташый торган берничә баржасы да булган. Моннан тыш, Сумка елгасы ярлары буенда печәнлек-болыннары булуы мәгълүм. Аның көтүче нәселеннән чыкканлыгы турында һәрвакыт ярлыларга булышуы, ә җәй көннәрендә болында оста итеп печән чапканлыгы да сөйләп тора. Раифа монастыреның дүрт баскычлы чаң манарасы аның акчаларына төзелгән. Атлашкиннар нәселенең бер вәкиле аның чикләрендә күмелгән.

Җирле крестьяннар үз бариннарын игелекле кеше буларак таныганнар. Шуңа күрә, революциядән соң большевиклар байлыкны реквизицияләүне игълан иткәч, аларның үз бариннарының мөлкәтенә куллары күтәрелмәгән. Моннан тыш, алар сәүдәгәрне әзерләнеп килүче экспроприация турында алдан кисәткәннәр, һәм Николай Атлашкин, үз милкен ике олауга төяп, авылдан Казанга чыгып киткән. Аның йортын Атлашкинны һәм аның игелекле эшләрен бөтенләй белмәгән кешеләр генә талаган.

Реклама 16+

Кис тә бүләк ит

«Татарстан» журналының чәй традицияләре

Җылы кешеләр
белән җылы очрашулар,
җылы теләкләр

96 еллык зирәклек
ТАТАРСТАН
ЖУРНАЛЫ

ТАТАРСТАН

Журнал акыллы, игелекле, мәңгелек кыйммәтләргә ия булган эксклюзив открыткалар сериясе тәкъдим итә

PRESSA.RU

чәй
– Чәй агызыгыз да,
балкып торган
көзне каршылагыз!
Реклама 16+